# ШУРА

№ 22

2018




2000795269987

Татарстан Республикасы Мөселманнарының Диния нәзарәте

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

## ЭЧТӘЛЕК

ВӘГАЗЬЛӘР

Гайбәт зарары . . . 6
Бөтен нәрсә – әманәт . . . 10
Гаилә: әһәмияте һәм проблемалар . . . 17
Бөтенебез Адәм балалары . . . 27
Мөхәммәд пәйгамбәр – галәмнәр өчен рәхмәт . . . 34
Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең кыйммәте . . . 40
Җәннәт – аналарның аяк астында . . . 47
Зина һәм аның җәмгыятькә зарары . . . 52
Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең сөннәтенә иярүнең әһәмияте . 58
Яхшылыкка өндәү һәм тыйганнан тыю . . . 63
Дини гыйлем алуның әһәмияте . . . 68
Җомга көненең фазыйләтләре . . . 77
Тәүбә кылу һәм Аллаһыдан өметне өзмәү . . . 83

ФӘТВАЛАР

Зәкятне нисаб күләменнән артыграк итеп түләргә ярыймы? . . . 89
Башка кешенең бурычын түләү зәкят була аламы? . . . 89
Зәкят бай кешегә бирелсә . . . 90

ҮРНӘК ЗАТЛАР

Өченче тугры хәлифә – Госман радыяллаһу ганһе . . . 92
Зәйнәб бинте Җәхеш . . . 110

ФӘН

Заһир Әр-Ривайә – Надир Әр-Ривайә . . . 120

ТАРИХ

Пәйгамбәрләр тарихы . . . 140
Сигезенче мөфти – Ризаэтдин хәзрәт . . . 146

Иске Задур ишаны Әхмәтсафа Биккулов . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Әш-шәех Зәйнуллаһ хәзрәтнең вафаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168

ТӘРБИЯ
Безне Яратучы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175

МӘҮЛИД ӘН-НӘБИ
Мәүлид укыган өчен акча түләү рөхсәт ителәме?. . . . . . . . . . . . . . 181
Мәүлид кичәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182

НӘСЫЙХӘТ
Никахлар күкләрдә укыла. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Юмартлык һәм саранлыкның Коръән һәм Сөннәттәге хөкемнәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194
Ришвәт зәхмәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 199

ӘДӘБИ СӘХИФӘ
Уңышка ирешү сере . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 205

**«ШУРА» дини альманах, №22**

*октябрь – декабрь 2018*
*сафәр – рабигыль-ахыр 1440*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП:**
Рәмзилә Шафикова
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**ДИЗАЙНЕРЛАР:**
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Раушан Сәйфетдияров

**ӘДӘБИ РЕДАКТОРЛАР:**
Рәмзилә Шафикова
Лилия Хәләфетдинова

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нчы йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«Инфо систем» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420044, Казан ш., Ямашев проспекты, 36 Б*
*Тел./факс: +7 (843) 519-91-10*
*Сайт: http://kpkps.ru/*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 08.10.2018
Чыгу көне: 23.10.2018

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

# Вәгазьләр

*12 нче октябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 3 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Гайбәт зарары

Әлхәмдү лилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн, әммә бәгъд: бу фани дөньяны һәм Ахирәт дөньясын Яратучы, дөньяга барча тере һәм тере булмаган мәхлүкъларны барлыкка китереп тәрбия кылучы, Адәм балаларын барча мәхлүкаттан өстен итеп, акыл нигъмәте һәм башка бик күп нигъмәтләр белән нигъмәтләндереп ризыкландыручы вә хәрәкәтләндерүче һәм: «Әй газиз бәндәләрем! Мин биргән гомерне – бу дөньядагы санаулы көннәрегезне гыйбадәт вә изгелек кылып, гөнаһлы нәрсәләрдән тыелып яшәгез!» – дип безләргә Үзенең тәрбиясен җиткергән, фани дөньяның һәм мәңгелек Ахирәтнең хуҗасы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә иксез-чиксез шөкранәләребез һәм дә сәна-мактауларыбыз вә рәхмәтләребез булсын.

Бу дөньяга рәхмәт буларак җибәрелгән, өммәте өчен бөтен авырлыкларга түзеп, сабыр итеп, өстенә йөкләнгән пәйгамбәрлек вазифасын башкарыр өчен бөтен көчен куйган, Кыямәт көненең бөек расүле – сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләреннән чыккан салават вә догаларыбыз ирешсен.

Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһ, мөхтәрәм дин кардәшләребез! Адәм балаларында бәдәни, ягъни тән белән бәйле булган авырулардан тыш, рухи хасталыклар да булырга мөмкин. Шушы җан белән бәйле булган чирләр кешенең үзенә һәм, гомумән, җәмгыятькә бик зур зыян китерә. Калебебезне каралтып, гөнаһ сазлыгына батырып, кешенең дөнья вә Ахирәт тормышына зарар сала торган шундый рухи чирләрнең берсе – ул гайбәт.

Ислам галимнәре гайбәтне тел афәтләреннән булган гөнаһлы гамәл дип билгелиләр. Шәригать буенча гайбәт ул – кемнең дә булса кимчелеген, нинди дә булса начар, тискәре сыйфатын шул кеше үзе янда булмаганда башкаларга сөйләү.

Кызганыч, әмма бик күп кеше гайбәтне зур гөнаһка санамый, янәсе, нәрсә булган соң, мин бит дөресен әйтәм, дип аклана. Әмма безнең Яратучыбыз Аллаһы Тәгалә бу гамәлне олы гөнаһлар, пычрак, җирәнгеч гамәлләр рәтенә кертә һәм изге Китабы Коръән-Кәримдә гайбәт сөйләүне мәет итен ашау белән чагыштыра (49:12). Кеше кимчелекләрен барлап тел «чайкауны» кайбер галимнәр сасыган, бик начар исле үләксәне ашау белән дә тиңли. Димәк, без бер шикләнмичә-икеләнмичә гайбәтнең бик куркыныч, гөнаһлы һәм җирәнгеч гамәл булуын танырга тиешбез. Әмма... кем әйтмешли, тел тик тормый бит... Көн саен диярлек без берәр кешене (күршебезне, хезмәттәшебезне) начар яктан искә алып сөйлибез. Сөйләгән сүзләребезнең гайбәт булуын каян белергә соң? Бик гади: әгәр син начар итеп искә ала торган кеше янда булмаса һәм син әйткән сүзләрне ишетеп ул үпкәләрлек булса, белеп торыгыз: бу – гайбәт, ә син – гайбәтче, ягъни сасыган үләксә итен ашаучы...

Мәгълүм булганча, бозылган ризык ашаудан тән агулана, гайбәт сөйләүдән исә җан агулана. Ислам галимнәре аңлатканча, гайбәт күңелне каралта һәм яман шеш тәнне үтергән кебек, кешенең иманын юк итә. Яман шешнең тәндә барлыгын күпләр соңарып белү сәбәпле һәлак була. Рухи хасталыклар исә иманга, җанга зур зыян салып, безне һәлак итәргә мөмкин. Шуңа күрә кеше рухи авыруларның яман нәтиҗәләре турында да, һичшиксез, хәбәрдар булырга тиеш. Гайбәт чире белән авырганыңны ничек белергә соң? Әгәр башкаларны начар яктан искә алудан күңелеңә ләззәт алсаң, әгәр гайбәт сөйләү рәхәтлек китерсә, белеп тор: синең калебең авыру...

Шунысын да белү мөһимдер: кемдер турында гайбәт сөйләсәң, гамәл-гыйбадәт, изгелек кылудан сиңа язылган савапларны Кыямәт

көнендә шул кешегә бирәсең була. Савапларың җитмәсә, теге кешенең гөнаһлары синең гамәл дәфтәренә күчәчәк. Хәсән Әл-Басри исемле галим үзе турында гайбәт сөйләгәнен белгәч, гайбәтчеләргә хат һәм бүләк җибәрә, хатында исә болай дип яза: «Минем хакта гайбәт сөйләгәнсез икән. Шулай булгач, савапларыгызның бер өлеше хәзер миңа бирелде, гөнаһларымның бер өлешен дә сез үз өстегезгә алдыгыз. Шуның өчен шушы бүләк-һәдиямне кабул итеп алуыгызны үтенәм».

Имам Шәгърани дигән ислам галиме белдерүенчә, Кыямәт көнендә гамәл дәфтәрләрен кулына алган кайбер кешеләр әйтер: «Йә Раббым! Кайда соң минем укыган намазларым, тоткан уразаларым, биргән садакаларым? Нишләп аларның саваплары язылмыйча калган?» Аллаһы Тәгалә исә аларга: «Сез кылган изге эшләрегезнең барысы да гамәл дәфтәрләрегезгә язылып барды, ләкин сез аларны саклый алмадыгыз – гайбәт сөйләвегез аркасында савапларыгыз сез сөйләгән кешенең гамәл дәфтәренә күчерелде», – дип җавап кайтарыр.

Шулай итеп, гайбәт сөйләүнең нәтиҗәсе бик аяныч. Әле шунысын да белергә кирәк – гайбәт сөйләү генә түгел, аны тыңлау да харам. Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллэллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дигән: «Гайбәт сөйләүче белән аны тыңлаучының гөнаһлары уртактыр».

Шундый катгый кисәтүләргә карамастан, кайберәүләр барыбер: «Мин дөресне сөйлим!» – дип кабат-кабат акланырга маташа. Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләм моңа да төгәл җавап бирә: «Кеше турында ул үзе ишетмәгәндә әйтелгән начар сүзләр дөрес, хак булса, бу – гайбәт, дөреслеккә туры килми икән, бу – бохтан (яла ягу)». Әлеге харам кылынган гамәлнең куркыныч нәтиҗәсен аңлатып, Мөхәммәд галәйһиссәлам бер мөбарәк хәдисендә болай ди: «Дөрестән дә, бик күп кеше тәмуг утына зина кылу һәм гайбәт аркасында эләгер. Ике аяк һәм ике ирен арасындагы әгъзаларыгызны гөнаһтан сакласагыз гына, сезгә җәннәт вәгъдә ителә ала». Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Җәһәннәм

әһелләренең күпчелеген хатын-кызлар тәшкил итәр һәм шуларның зур өлеше нәкъ менә гайбәт гөнаһын кылу сәбәпле тәмуг җәзасына дучар булыр», – дип әйтеп калдыруы да юкка түгелдер…

Көннәрдән бер көнне Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләре белән мәчеттә утырганда, аларга: «Хәзер бирегә килеп керәчәк кеше – җәннәт әһеледер», – дип әйтә. Шуннан соң мәчеткә гади генә бер ир килеп керә. Соңыннан, инде мәчеттән чыккач, сәхабәләр аннан: «Җәннәткә кертердәй нинди гамәлең бар?» – дип сорыйлар. Бераз уйлап торганнан соң, ул болай дип җавап бирә: «Әллә ни зур гамәлләр кылганым юк, әмма шунысын гына әйтә алам: мин башкалар турында беркайчан да начар сөйләмим, алай гына да түгел – хәтта начар уйламыйм да».

Шулай итеп, телебезне «саклау» – мөселманнарга хас булырга тиешле сыйфатларның берседер. «Аллаһыга ышанган кеше йә яхшы, файдалы сүзләр сөйләсен, йә бөтенләй дәшмәсен», – дип кисәтә безне Пәйгамбәребез. Аллаһы Тәгалә исә Аңа тугры булган бәндәләрен өметләндереп, болай ди: «Кем дә кем башка кешенең гаебен белдертмәсә, Ахирәттә аның гаепләрен белдертмәм». Шуңа да уйланыйк, сакланыйк һәм шәйтан вәсвәсәләренә бирешмичә, Аллаһы вәгъдә иткәннәрне өмет итеп, пакь, саф күңел, чиста тел, ихлас иман белән, башкаларны хөрмәтләп, матур итеп яшик, җәмәгать.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә һәркайсыбызга да тәүфыйк вә инсаф биреп, Аллаһының кушканнарын үтәп вә тыйганнарыннан тыелып, изге гамәлләр кылып, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вә сәлләм үрнәгендә күркәм холыклы, әдәп вә әхлаклы, тәкъва, хакыйкый мөэмин-мөселман булып яшәргә язсын, мәңгелек Ахирәт тормышында да Аллаһы Раббыбызның гаҗәеп Җәннәтенә кереп, олуг бәхет-сәгадәткә ирешергә насыйп булсын. Әмин!

*Ришат хәзрәт Курамшин,*

*Кукмара мәдрәсәсе мөдире*

*19 нчы октябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Бөтен нәрсә – әманәт

Барча галәмнәрне бар кылып, аларны тәрбия кылып торучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итеп кылучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Кадерле җәмәгать, бүгенге вәгазебез Исламда зур урын алып торган темага – әманәткә багышланган булыр. Гарәп телендә әманәт сүзе намуслык, тугрылык, ышанычлылык дигәнне аңлата һәм хыянәт сүзенең антонимы булып тора. Ә хыянәт сүзе монафикълык, ялганлау дигәнне аңлата.

Әманәт – вакытлыча нәрсәне дә булса саклап торырга алу дигәнне аңлата. Әгәр дустың сиңа берәр нәрсәне: «Бу әйберне шул көнгә кадәр генә үзеңдә тот әле», – дип әйтсә, син аңа үз әйбереңә караган кебек карарга, вакыты җиткәч, аны кайтарып бирергә тиеш. Диндә дә әманәтне шул яктан карап була һәм анда ул күп төрле була ала.

Беренчедән, иң бөек әманәт ул – Ислам дине. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

إِنَّا عَرَضْنَا الْأَمَانَةَ عَلَى السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَالْجِبَالِ فَأَبَيْنَ أَن يَحْمِلْنَهَا وَأَشْفَقْنَ مِنْهَا وَحَمَلَهَا الْإِنسَانُ ۖ إِنَّهُ كَانَ ظَلُومًا جَهُولًا ﴿٧٢﴾

**«Без әманәт итеп күкләргә, җиргә вә тауларга Ислам шәригатен тәкъдим иттек, ләкин алар кабул итмәделәр, әгәр үти алмасак, газап ирешер, дип курыктылар, бу әманәтне кеше көчсез булган хәлдә өстенә йөкләде. Эшнең ахырын белмичә, наданлык белән зур әманәтне кабул итте дә, үти алмыйча, үзенә золым итүче булды».**

«Саффат / Сафта Торучылар», 37:72

Исламны диндә булмаган кешеләргә җиткерү – шулай ук әманәт. Пәйгамбәрләр аларга иңгән вәхиләрнең сакчылары булып торалар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Мин монда (Аллаһының) вәкиле булып торам, сез дә миңа ышаныгыз. Миңа күкләрдән иртән вә кичен вәхи иңеп тора», – дип әйткән. Пәйгамбәрләрдән соң килгән галимнәр өчен дә динне тарату әманәт санала.

Икенчедән, Аллаһы Тәгалә биргән барлык нигъмәтләр дә әманәт булып тора. Бу нигъмәтләргә дөнья байлыклары да, кешенең тән әгъзалары да, күрү, ишетү, тоемлау сәләтләре дә керә. Шуңа күрә бу әманәтләрне Аллаһы риза булган эшләрдә генә кулланырга кирәк. Шулай ук аларны куллануда соңга калмаска яхшырак. Аллаһы Илчесе галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Сиңа 5 төрле нәрсә килгәнче икенче бишнең кадерен бел: үлемең килгәнче исән булуыңның, авыру килгәнче сәламәтлегеңнең, берәр эш белән мәшгуль булганчы буш вакытыңның, картлыгың килгәнче яшь чагыңның, фәкыйрьлек килгәнче байлыгыңның». Саналып киткән 5 әйбер дә әманәткә керә. Алар белән дөрес файдалана белергә кирәк. Әгәр кеше үзенең көч-куәтен һәм буш вакытын ярамаган эшкә юнәлтсә,сәламәт

булганда изге гамәлләр кылмыйча йөрсә, картайганчы, яшь булганда гыйлем алмаса – болар барысы да әманәткә хыянәт итү булып санала.

Шәригатьнең 5 максаты турында ишеткәнегез бардыр. Моның турында вәгазьләр дә күп булды, китапларда да күп язылды. Шулай да кыскача гына аларны искә төшереп китик. Беренчедән, шәригать динне саклый, икенчедән, кешенең гомерен, җанын, өченчедән, кешенең акылын, дүртенчедән, кешенең малын саклый. Һәм бишенче әйбер итеп кешенең дәрәҗәсен саклый. Ягъни дин шуларны сакларга юнәлтелгән, шуңа да бу әйберләрне саклау – һәр кешенең мөһим бер эше, чөнки болар барысы да безгә әманәт.

Чыннан да, кешенең гомере аңа әманәт итеп бирелгән, шуңа күрә ул аны да юкка сарыф итәргә тиеш түгел. Әле мин яшь, дигән ялгыш фикерләр белән яшәргә ярамый. Кеше берәр әманәт тапшырса, аның вакытын да билгели. Гомер дә билгеле бер вакытка гына бирелә. Кешенең намусы, дәрәҗәсе, акылы – әманәт. Шуңа да хәмер эчеп, акылны капларга, бозык гамәлләр кылып, намусны җуярга һич ярамый.

Өченчедән, Кыямәт көнендә гомере, малы, гыйлеме, тәне турында соралмыйча бер генә кеше дә аягын да атлый алмас. Моның турында Пәйгамбәребез хәдисләре хәбәр итә. Моннан чыгып, гыйлемне алу, аны тарату, аның буенча гамәл кылу – болар барысы да әманәт.

Әйе, кешенең тәне – әманәт. Аллаһы Тәгалә безгә аны да кулланып торырга гына бирде. Вакыты беткәч, аны да кабергә урнаштырабыз. Үз тәнеңә игътибар итмәү – әманәткә каршы бару дигән сүз. Авырса – дәваларга, аңа рәсемнәр ясамаска (татуировка), вакытында ашарга, организмга зыян китерерлек итеп ашамаска, вакытында йокларга кирәк. Бу очракта гына ошбу әманәт әйбәт саклана дип әйтеп була.

Дүртенчедән, кешеләргә йөкләнелгән эш, хезмәт. Эш кушканда, ул эшне башкарып чыга алырлык кешеләргә генә кушу кирәк. Кешегә авыр эш, яки нинди дә булса бер эштә белеме булмаган кешегә йөкләргә яра-

мый. Яки берәр вазифаны шул вазифага лаек булган кешегә генә тапшырырга ярый. Эш йөкләнелгән кеше дә бу эшне җиренә җиткереп башкарырга тиеш. Кешеләрнең үзләренә йөкләнелгән әманәтләрне башкармау – Кыямәт көненең кече билгеләреннән. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Әманәт (саклау) югалса, Сәгатьне көтегез», – дип әйткән. Сәхабәләр: «Ул ничек итеп югала?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез: «Эшләр лаексыз кешеләргә тапшырыла башлагач, Сәгатьне көтегез», – дип җавап кайтарган.

Бишенчедән, кешенең серләре – әманәт. «Әгәр берәр кеше сезгә ни дә булса әйткәннән соң, як-ягына карап алса, бу – әманәт» (хәдис).

Алтынчыдан, сакларга биреп торган әйбер. Әгәр дә берәр кеше үз әйберен икенче бер кешегә сакларга дип биреп торса, аны саклау һәм беренчел халәтендә кайтарып бирү – әманәт.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе болай дип әйтә: «Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам болай дип әйтте: «Бервакыт бер кеше үзенә җир сатып ала һәм анда бер савыт алтын таба. Ул бу алтынны кире хуҗасына кайтарырга тели һәм: «Мин сездән җирне генә сатып алдым», – дип әйтә. Җир хуҗасы исә: «Мин сиңа җирне анда булган бар әйбере белән бергә саттым», – дип әйтә. Шуннан соң алар казый янына баралар. Казый аларның балалары турында сорый. Берсенең улы, икенчесенең кызы барлыгы ачыклана. Казый аларга: «Аларга никах укыгыз һәм акчаны аларга тотыгыз. Шулай ук бу акчадан садакалар да бирегез»,– дип җавап кайтара» (Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан).

Әманәт – саклар өчен билгеле бер вакытка биреп торган әйбер дидек. Шәригать бирелгән әманәтне сакларга һәм аны тиешле рәвештә кире кайтарып бирергә боера:

إِنَّ اللَّهَ يَأْمُرُكُمْ أَن تُؤَدُّوا الْأَمَانَاتِ إِلَىٰ أَهْلِهَا ﴿٥٨﴾

**«Дөреслектә, Аллаһы сезгә әманәтләрен әһелләренә тапшырырга әмер итәдер».**

«Нисә / Хатыннар», 4:58

Бу аятьне тәфсир кылып, Ибне Кәсир болай дип әйтә: «Бу барлык әманәтләргә дә кагыла. Алар ике категориягә бүленә: Аллаһы каршында булган әманәтләр – намаз, ураза һ.б. Һәм Аллаһының колларының әманәтләре, мәсәлән, кемнеңдер сакларга биреп торган әйберләре.

Икенче бер аятьтә Аллаһы Тәгалә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تَخُونُوا اللَّهَ وَالرَّسُولَ وَتَخُونُوا أَمَانَاتِكُمْ وَأَنتُمْ تَعْلَمُونَ ﴿٢٧﴾

**«Ий мөэминнәр! Аллаһыга вә Расүлгә хыянәт итмәгез һәм үзара әманәтләрегезгә дә хыянәт итмәгез, аның хыянәт икәнен үзегез беләсез».**

«Әнфәл / Табыш», 8:27

Шулай ук «Мөэминнәр» сүрәсендә мондый аятьләр бар:

قَدْ أَفْلَحَ الْمُؤْمِنُونَ ﴿١﴾ الَّذِينَ هُمْ فِي صَلَاتِهِمْ خَاشِعُونَ ﴿٢﴾

فَمَنِ ابْتَغَىٰ وَرَاءَ ذَٰلِكَ فَأُولَٰئِكَ هُمُ الْعَادُونَ ﴿٧﴾

**«Тәхкыйк, хак мөэминнәр газаптан котылып мәңгелек сәгадәткә ирештеләр. Алар намазларын хошугъ белән укыйлар, Аллаһыдан куркып, кечерәяләр... Янә алар тапшырылган әманәтләргә вә биргән вәгъдәләргә хыянәт итмәсләр».**

«Мөэминнәр», 23:1-2,7

Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам монафикъ кешеләрне тасвирлап, болай дип әйтә: «Монафикъның билгесе өчтер: әгәр сөйләсә, алдалый;

килешү төзесә, вәгъдәсендә тормас; әгәр әманәткә берәр нәрсә бирсәләр, әманәтенә хыянәт итә».

Әманәткә хыянәт итү – зур гөнаһлар рәтенә керә. Имам Әз-Зәһәби: «Хыянәт – нинди генә эштә булуына карамастан, бик пычрак гамәлдер», – дип әйтә. Имам Әл-Бәйһакый хәдисләр җыентыгында мондый хәдис китерелә: «Әманәткә хыянәт итүченең иманы булмас һәм килешүне сакламаган кешенең дине дә булмас».

Әманәт гаилә тормышында да зур урын биләп тора. Ир-атка аның хатыны, хатын-кызга аның ире әманәт. Ата-ана өчен балалары шулай ук аманәт. Өйдәге серләр, мал, җенси мөнәсәбәт мәсьәләсе – болар да әманәт. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Үзенең хәләл җефете белән якынлык кылганнан соң, кешеләргә аның серләре турында сөйләгән кеше (ир-ат яки хатын-кыз) Кыямәт көнендә иң начар халәттә булучылар санынннандыр».

Гомумән алганда, әманәткә беркайчан да хыянәт итәргә ярамый. Ул куелган вакыт эчендә кире кайтарылырга, ике якның да хакларына зыян салмаска тиеш. Сатып алабызмы, сатабызмы; арендага алганда һәм биргәндә, залог калдырганда, аны саклап торганда да хаклар кайтарылырга тиеш.

Бу шулай ук вәкиллек булган очракка да, кәфаләт булган очракка да кагыла. Шәригатьтә вәкиллек – ул бер шәхеснең икенче шәхескә үзенең мәнфәгатьләрен ышанып тапшыруы һәм йөкләүче төзи алган теләсә нинди килешүне аның вәкиле дә төзи алуы. Кәфаләт – ул бирелгән йөкләмәне ышандырып, үз өстенә алу.

Хакимгә ул идарә иткән ил әманәт. Директорга – аның кул астында эшләгән хезмәткәрләр. Гаилә хуҗасына – аның гаилә әгъзалары. Васыять үтәү – шулай ук әманәт. Кемгәдер сәлам ирештерергә кушсалар, шул сәламне ирештерү – әманәт.

Аллаһы Тәгалә үзебезгә әманәт итеп бирелгән диндә нык торырга, әманәт итеп бирелгән гомерне заяга уздырмаска, әманәт итеп бирелгән сәламәтлекне сакларга, әманәт итеп бирелгән балаларыбызга, хатыннарыбызга яхшы мөгамәләдә булырга вә Үзенең җәннәтләренә керергә насыйп әйләсә иде. Әмин!

*«Хозур» редакциясе*

*26 нчы октябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 17 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Гаилә: әһәмияте һәм проблемалар

وَأَنكِحُوا الْأَيَامَىٰ مِنكُمْ وَالصَّالِحِينَ مِنْ عِبَادِكُمْ وَإِمَائِكُمْ ۚ إِن يَكُونُوا فُقَرَاءَ يُغْنِهِمُ اللَّهُ مِن فَضْلِهِ ۗ وَاللَّهُ وَاسِعٌ عَلِيمٌ ﴿٣٢﴾

**«Үзләрегездән ирсез хатыннарны вә хатынсыз ирләрне, һәм никах хакларын үтәргә яраклы булган яхшы колларыгызны вә җарияләрегезне никахландырыгыз, әгәр никахланучылар фәкыйрь булсалар, Аллаһы аларны Үзенең юмартлыгы белән бай кылыр, шиксез, Аллаһы киңлек иясе вә белеп эш кылучы».**

«Нур», 24:32

Аллаһы Тәгалә атабыз Адәмне балчыктан ярата, аның кабыргасыннан анабыз Хәваны ярата. Аларны гаилә кора, бала таба, нәсел калдыра һәм үлә торган итеп ярата. Бу аятьтән күргәнебезчә, Аллаһы Тәгалә безгә никахлашуны боера. Никахның әһәмияте турында пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Никах минем сөннәтемнән, кем сөннәтемне үтәми, миннән түгел».

Аллаһы Тәгалә кешене Үзенә генә буйсына торган итеп яраткан һәм никах шушы буйсынуларның берсе. Никахлашып кеше үз өстенә күп кенә бурычлар ала һәм шул бурычларны үтәп, Аллаһының мәрхәмәтенә ирешә. Җенси якынлык кылу ихтыяҗларын канәгатьләндерү шулай ук никахлашуның төп максатларыннан булып тора, чөнки җенси якынлык нәсел дәвам итүнең төп чарасыдыр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи

вә сәлләм: «Никахлашыгыз, күп итеп балалар табыгыз, чынлыкта, Кыямәт көнендә мин сезнең күплегегез белән горурланырмын», – ди .

Гаилә корып тормыш итү Аллаһы Тәгаләнең барлык галәмнәргә булган мәхәббәтен тояр өчен йөкләтелә. Ир-хатын арасындагы, туганнар арасындагы, балаларга, ата-аналарга карата булган мәхәббәт – болар барысы да Аллаһы Тәгаләнең Үзенең мәхлүкъларына булган мәрхәмәтенең чагылышлары.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

«Аллаһы Тәгалә Үзенең мәрхәмәтен 100 өлешкә бүлә һәм шуның фәкать 1 өлеше генә җир йөзендәге җан ияләре арасында бүленә. Бу мәрхәмәтлелекнең чагылышын һәрбер җан иясендә, хәтта хайваннарда да күрергә була. Мәсәлән, кыргый хайваннар балаларын имезгәндә бер аякларын күтәрәләр. Шушы инде Аллаһы Тәгаләнең Үзенең мәхлүкъларына биргән мәрхәмәтлелегенең нәтиҗәсе. Шушы мәрхәмәтлелек сәбәпле кыргый хайваннар үзләренең балаларына шәфкатьле, мәрхәмәтле булалар, аларны төрле бәлаләрдән саклыйлар, ашаталар һәм үстерәләр. Әмма Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә шушы 1 өлеш мәрхәмәтлелекне 99 өлеш белән кушачак һәм шулай итеп Үзенең мәрхәмәтен Үзенең колларына ирештерәчәк», – ди.

Бәлигатькә ирешеп кеше үз өстенә Аллаһы Тәгалә каршында Кыямәт көнендә җавап бирү хокукына ия була торган зур вазифа ала, күп төрле бурычларга, хокукларга ия була. Шушы бурычларның берсе булып аның шәригать кануннарына туры китереп никахлы рәвештә гаилә коруы тора. Никахлы тормыш кешенең табигате белән билгеләнгән. Гаилә – ул ир белән хатынның икесе арасында булган мөнәсәбәтләре генә түгел, анда моңарчы чит кеше булганнар, якын туганнар, әти-әнигә әвереләләр. Үзләре белән зур шатлыклар, зур мәшәкатьләр, сынаулар, кайгы-хәсрәтләр алып килеп балалар туа, моңарчы сиңа ярдәм итеп, сине тәрбияләп торган әти-әниләр картаялар, үзләре ярдәмгә мохтаҗ булалар.

Гаилә – ул кечкенә дәүләт. Шушы дәүләттә Аллаһы Тәгаләнең салынган 1 өлеш рәхмәте. Аңа ирешү өчен ир-аттан да, хатын-кыздан да зур тырышлык, сабырлык таләп ителә. Әлбәттә, боларга фәкать Аллаһы Тәгаләдән тиешле дәрәҗәдә куркып, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә өмет итеп, һәр вакытта Аңа тәвәккәл кылып кына, ягъни тәкъвалык белән генә ирешеп була. Гаиләле тормышның зур җаваплылык икәнен аңлаган хәлдә, гаилә коруга зур әһәмият биреп, аеруча игътибарлы булырга кирәк. Гаиләнең ныклы булуында әдәп һәм әхлак аеруча зур әһәмият уйный. Алда әйтеп кителгәнчә, гаилә – ул кечкенә бер дәүләт, зур дәүләтнең, милләтнең бер өлеше һәм төп күрсәткече. Гаилә ныклы, тәртипле булса, ил дә ныклы, тәртипле була, гаиләдә тәртип булмаса, илдә дә тәртип булмый. Шуңа күрә гаилә әгъзалары тырышлыгы белән генә түгел, бәлки дәүләт тарафыннан да тиешле дәрәҗәдә яклауга һәм ярдәмгә мохтаҗ.

Гаилә ныклы, тәртипле булсын өчен ирләргә нинди сыйфатларга карап үзләренә хатын алырга кирәк һәм хатын-кызларга да нинди иргә ризалык бирергә соң? Шәригатьтә барысы да ачык итеп билгеләнгән. Ирләргә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә:

«Хатын-кызга 4 нәрсәгә карап никахлашалар: байлыгына, дәрәҗәсенә, чибәрлегенә һәм динилегенә карап. Сез динилегенә карагыз һәм бәхетле булыгыз».

Хатын-кызларга Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

«Әгәр сезгә дине һәм әхлагы белән сез риза булырдай кеше килсә, аларга үзләрегезнең кызларыгызны бирегез, әгәр дә сез шулай эшләмәсәгез, җир йөзендә фетнәләр һәм зур бозыклыклар таралачак», – ди.

Үзен мөселман санаган егетләр шушы хәдисләргә таянып өйләнергә, кызлар кияүгә чыгарга тиеш һәм гаиләләр бар да бәхетле булырга тиеш. Аллаһыдан курыккан тәкъва мөэминнәр өчен бер проблема да юк кебек. Әмма илдә 82% гаилә таркала. Бу санга «Россия мөселман иле түгел, шуңа

аерылышулар күп», дип карарга кирәк түгел. Аерылышулар мөселманнар арасында да моннан аз түгелдер. Сәбәбе нәрсәдә соң? Бар проблеманың да башы тәкъвалыктан башлана. Үзләрен генә мөселман дип йөрүчеләр күп, әмма аларның үз-үзләрен тотышларына, гамәлләренә карап, күп вакыт болар, гомумән, мөселманмы икән дигән сорау туа. Андыйлар үзләрен үрнәк санап, башкаларның кимчелекләрен эзләү, табу һәм шул кимчелекләргә каршы көрәшүне максат итеп куялар. Һәм бу беренче чиратта гаиләдән башлана. Яңа өйләнгән ир хатынның кимчелекләрен бетерү өстендә эшли башласа, хатын да иренә үзе белгән-белмәгән таләпләрне куя башлый. Яңа никахлашкан гаилә бу проблемага каршы тора алмый, таркала. Яшьләр бер-берсенең яхшылыкларын эзләп, булганына канәгатьләнәсе урында, тормышларын кимчелекләр эзләүдән башлыйлар. Үзләренеке итүне максат итеп куйган егет белән кыз бер-берсенә өйләнешкәнче, әлбәттә, яхшы яктан гына күренергә тырышалар, максатка ирешкәч, мөнәсәбәтләр чынбарлыкка корыла, ясалма кыланулар, тырышулар юкка чыга һәм бар да син теләгәнчә түгел икәнлеге ачыклана. Гаилә алдында нишләргә, дигән сорау туа. Кеше кимчелексез булмый. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَعَاشِرُوهُنَّ بِالْمَعْرُوفِ ۚ فَإِن كَرِهْتُمُوهُنَّ فَعَسَىٰ أَن تَكْرَهُوا شَيْئًا وَيَجْعَلَ اللَّهُ فِيهِ خَيْرًا كَثِيرًا ﴿١٩﴾

> **«Никахыгызда булган хатыннар белән яхшы мөгаләмәдә булыгыз, гәрчә аларны бик яратмасагыз да. Өметледер сез яратмаган нәрсәләрдә Аллаһы Тәгаләдән сезнең өчен күп яхшылыкларның булуы».**

«Нисә / Хатыннар», 4:19

Безнең әби-бабайлар чорында аерылышу юк дәрәҗәсендәге сирәк күренеш иде. Алар да бит шул ук Адәм балалары, алар да кимчелексез

булмаган. Күрәмсең, аларның диннәре, бүгенге яшьләрдән аермалы буларак, телләрендә генә түгел, бәлки гамәлләрендә дә булган. Шул чорга кагылышлы бер кыйсса барыбызга да бер гыйбрәтле вакыйга булып торадыр. Бер кешенең ике кызы була: берсе бик чибәр, икенчесе бик ямьсез. Бу кешегә кыз сорап киләләр. Бу кеше чибәр кызын күрсәтеп, ямьсез кызын кияүгә бирә. Кыз белән егет төн куналар һәм икенче көнне бу хәл фаш ителә. Төн кунылган, кыз белән егет якынлык кылган, егет куенында ямьсез кыз. Шунда атасы: «Улым, бу хәлне үзем дә белмәдем, бу тәкъдирдер, бергә бәхетле торыгыз», – дип улын юата. Егет белән кыз озын гомер кичерәләр, күп балалар табалар, тәрбияләп үстерәләр, әбибабай булалар һәм әби үлә. Бабай әбинең кабере өстендә: «Аннан чибәр кеше юк иде», – дип елый.

Яшьләргә әйтәсе сүз шул: «Бүген сез «мәхәббәт» дип әйтә торган нәрсәгез – ул асылда сезнең нәфесегез, уй-теләкләрегез, дөнья алдавычлары». Мәхәббәт ул 30-40 ел бергә яшәгәч кенә барлыкка килә. Бабайлар: «Әбидән алдан үлсәм иде», – диләр. Чын мәхәббәт шушы инде ул.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хатынны динилегенә карап алыгыз, ди. Әмма яшьләр күп очракта динилегенә түгел, бәлки калган 3 сыйфатына карап никахланалар. Мин мөселман яшьләре турында әйтәм. Алар үзләрен сәләфләр кебек, ягъни беренче мөселманнар кебек дип әйтергә яраталар. Ә беренче мөселманнар ничек булганнар соң? Хәнбәли мәзһәбенә нигез салучы Әхмәд бине Хәнбәл бер вакыт ике кызлары булган бер гаиләгә кыз сорарга бара. Бу ике кызның берсе бик чибәр була, икенчесенең бер күзе сукыр, күрми торган була. Ул гаилә башлыгыннан: «Боларның кайсы акыллырак?» – дип сорый. Аңа: «Бер күзе күрми торганы», – диләр. Шунда бөек имам: «Миңа шунысын бирегез!» – ди. Пәйгамбәргә иярмәү динилекне күрсәтми.

Кызлар да шулай ук. Егетләрнең тормыш алып бара алганнарына карамыйлар, сүзе гамәленә туры киләме-юкмы тикшереп тормыйлар,

кияүгә чыгалар, аннары: «Мин теләгән кеше булмады, безне аерыгыз», – дип казыйга талак сорап киләләр.

Ә асылда кыз белән егетне өйләнештерү ата-ананың бурычы. Элек шулай булган, димләп өйләнешкәннәр, ата-анасы 7 буынга кадәр тикшергән, үзенең баласына тиң парны эзләгәннәр, бүгенге кебек «үзеңә ошаганны үзең тап», дип утырмаганнар.

Гаиләле булу – Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте, гаилә кору – Адәм баласының бурычы. Безнең халык – дәүләтле халык, ил белән, дөнья белән идарә иткән халык. Аның Ислам динендә 1100 еллык тарихы бар. Аның холкы, әдәбе, гаилә кору, гаилә тоту тәртибе Ислам динендә формалашкан. Безнең бөтен бәла – үзебезнең бәяләп бетермәс кыйммәтләребезне ташлап, бетеп баручы, киләчәге булмаган Аурупа кыйммәтләренә ябышырга тырышуыбызда. Дөрес аңлыйк, без Аурупа түгел һәм Аурупа да безгә тиң түгел. Инде үзебезнең нинди затлы халык икәнлегебезне аңларга вакыттыр бит инде.

Без бүген гаилә һәм гаиләнең ничек булырга тиешлеген, гаиләдәге проблемаларны кыскача гына карыйбыз. Гаилә егет белән кызның гыйшкыннан башланырга тиеш түгел, бәлки Аллаһы исеме белән, Аллаһының җәннәтен өмет итеп, шул җәннәткә керердәй, үзе генә түгел, сине дә алып керердәй пар эзләүдән башланырга тиеш. Дөнья ләззәтләре, байлыклары, дәрәҗәләре ана карынында 4 айлык вакытта, сиңа җан өрелгәндә ничек язылган, шулай булачак. Егет белән кызның гыйшкы күп очракта гаилә коруга түгел, бәлки зинага китерә, ә зина балага узуга, аны тудырмас өчен аборт ясатуга, ягъни үз балаңны үзең үтерүгә китерә. Күрәбез, ләззәт белән башланган дөнья ана кешегә үз баласын үтерү белән тәмамлана. Гыйшык, мәхәббәт дигән матур сүзләр белән Аурупа бүген бер җенесле никахларга батты, анда гаилә төшенчәсе гамәлдән генә түгел, сүздән, сөйләмнән дә чыгып бара.

Гаилә, алда әйтеп кителгәнчә, ир белән хатынны гына үз эченә алмый, бәлки ул берничә буынны, бала тәрбиясен, ата-анага ихтирамлылыкны, туганлык җепләрен өзмичә нык тотуны үз эченә ала. Адәм баласының дөньяга булган мәхәббәте аны җәннәт турында түгел, хәтта иртәгәге көн турында да уйламаска мәҗбүр итә. Бүген авылдагы өйләнмәгән ирләр картайдылар, бабай булдылар, алар үлгәч авылда кеше дә калмастыр. Шәһәрдәге хатын-кызлар ялгыз картаюдан куркып, зинадан бала табалар. 82% гаилә таркала дидек. Аерылган гаиләләрдә бала анасы белән кала. Бала өйдә, балалар бакчасында, мәктәптә атасын гына түгел, гомумән ир-ат күрмичә, күпчелек очракта ир-атка нәфрәт белән тәрбияләнеп үсә. Мондый тәрбия алган егетләр дә, кызлар да гаилә корырга сәләтле түгелләр. Бүген гражданский брак дигән исем астында зина кылу модага керде. Әгәр дә сукбай балаларны һәм балалар йортларында тәрбияләнә торган балаларны да исәпкә алсаң, бу халыкның киләчәге юк дигән нәтиҗә генә ясыйсы кала. Диннән язган халыкны бернинди якты киләчәк тә көтми. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

فَمَثَلُهُ كَمَثَلِ الْكَلْبِ إِن تَحْمِلْ عَلَيْهِ يَلْهَثْ أَوْ تَتْرُكْهُ يَلْهَث

**«Аларның мисалы эт кебек, этне орышсаң да телен асылындырыр, орышмасаң да телен асылындырыр».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:176

Аллаһы Тәгалә диннән читләшкән кавемне тиккә генә эт мисалында дими, чөнки этләрдә гаилә дигән нәрсә юк һәм халык та: «Этнең койрыгын кем кисә, шул эткә хуҗа була», ди.

Кеше гаилә кормый, фатир ала, фатирда иптәшкә эт ала. Урамда, өендә, транспортта эт белән сөйләшеп йөри. Хатын кирәк, ир кирәк, дип игълан бирә. Аны ирнең, хатынның нинди яшьтә булуы гына кызыксындыра. Эт кирәк, дип игълан бирә, нәселен сорый. Эт нәселле кирәк, ир, хатын нинди булса да ярый. Ул инде эттән дә түбән дәрәҗәдәдер.

Әгәр дә милләтне бер поезд итеп карасак, гаилә аны тартып бара торган локомотивы. Локомотив туктаса, бөтен поезд туктый. Бу локомотив даими хәрәкәттә булырга тиеш. Гаилә ким дигәндә өч буынны үз эченә ала: әби-бабай, әти-әни, балалар. Әби-бабай үлә тора, әти-әни әби-бабайга әйләнә, балалар үсә, никахлаша, алардан балалар туа. Бу 1000-әр еллар буе формалашкан, үз гореф-гадәтләре белән ныгытылган, милләтне саклап килгән, алга алып барган тотрыклы хәрәкәт. Бүген күпләрне кызыктырган, үзенә караткан ваһһабчылык, сәләфчелек, Исламда милләт юк, гореф-гадәт юк, дип милләтнең локомотивы булган гаиләнең яшәешенә иң зур зыян салучылар булып торалар. Ә инде аларның мәчетләрдә амин кычкырулары, кулларын күтәрүләре кебек башкалардан аерылырга теләүләре, гаиләгә китергән зыяннары янында ачуны китерә торган бик вак мәсьәләләр генә булып торалар.

Без Ауропа түгел, без гарәпләр дә түгел, без төркиләр, без татарлар. Безне милләт буларак саклап тора торган үз гореф-гадәтләребез бар. Мәсәлән, гаиләдә ата-ана үлгәч, мирас малы гадел итеп, шәригатьтә билгеләнгәнчә, балалары, якыннары арасында бүленергә тиеш. Бездә ул гомер-гомергә ата-ананы карап, тәрбияләп торган баласына, шул баланың гаиләсенә кала. Бу, гадәттә, төпчек малайга кала. Бу язылмаган канун белән бөтен туганнар да килешкәннәр, тавыш-гауга чыгармаганнар һәм бу гасырлар буе шулай дәвам иткән. Бу туганнарның төп йортка җыелуларына, туганлык мөнәсәбәтләренең саклануына бер сәбәп булып торган.

Соңгы вакытта, бигрәк тә перестройка чорында, туганнар арасында ата-ананың малына дәгъва белдерүләр башланды һәм бу гаиләләр таркалуга, олы яшькә җиткән ата-аналарның караусыз калуларына, балаларның тәрбиясез үсүләренә, туганлык җепләре өзелүгә һәм ахыр чиктә милләтнең таркаулыгына китерде.

Безнең халыкта 3-ен, 7-сен, 40-ын, елын үткәрү йолалары бар. Динне аз-маз белгән кеше дә бу йолаларның диннән түгел икәнлекләрен белә. Әмма бу йолалар, бигрәк тә бүгенге көндә, халыкны дин белән бәйләп тора торган, туганлык җепләрен саклый торган төп чараларның берсе. Бүген күпләр шушы йолаларны үткәрү, яисә шуларда катнашу сәбәпле генә үзләрен мөселман дип санныйлар. Бу йолалар шулай ук дин таратуда да зур әһәмияткә ия булып торалар. Әгәр дә бу йолаларны алып ташласаң, халык бөтенләй динсез калачак.

Аллаһы Тәгалә кешене мөшкел-мәшәкать белән бар кылган. Гаилә, әлбәттә, үзе белән күп проблемалар алып килә. Әмма кеше шул пробемалар аша Аллаһының рәхмәтенә ирешә, җәннәтле була. Гаилә корудан качып кына, адәм баласы проблемалардан, үзенә килгән кайгы-хәсрәтләрдән котыла алмый. Аллаһы Тәгалә «Гасыр» сүрәсендә болай дип әйтә:

وَالْعَصْرِ ﴿١﴾ إِنَّ الْإِنسَانَ لَفِي خُسْرٍ ﴿٢﴾ إِلَّا الَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ وَتَوَاصَوْا بِالْحَقِّ وَتَوَاصَوْا بِالصَّبْرِ ﴿٣﴾

**«Гасырлар белән ант итәм. Дөреслектә, адәм баласы хәсрәттәдер. Мәгәр Коръән өйрәткәнчә дөрес юл белән чын иман китереп, Ислам динен кабул иткән, һәрвакыт изге гамәлләр кылган, Коръән дәлилләре белән, хактан һич тә аерылмаска бер-берсен өндәгән, һәм тормыш вә дин мәшәкатьләренә, килгән төрле авырлыкларга, бәла-казаларга сабыр итәргә, чыдамлы булырга бер-берсен өндәгән хак мөэминнәр генә зарарланудан, кимчелектә, хәсрәттә булмаслар».**

«Гасыр», 103

Бер җомга вәгазендә генә гаилә мәшәкатьләренең барысын да ачып һәм аңлатып бетереп булмый. Бөтен кешелек өчен гаиләнең ныклы булуы зур әһәмияткә ия булу сәбәпле, аны таркату шәйтанның иң дәрәҗәле,

мактаулы гамәле булып тора. Ә шәйтан вәсвәсәсеннән фәкать тәкъвалык белән генә сакланып була.

Аллаһы Тәгалә һәммәләребезнең дә бәхетле гаиләләр булып яшәвебезне, Үзенең рәхмәтләренә ирешеп, җәннәтле булуыбызны насыйп кылсын!

*Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев,*

*Яр Чаллы шәһәренең «Ак мәчет» мәдрәсәсе директоры*

*2 нче ноябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 24 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Бөтенебез Адәм балалары

Бүгенге көндә кайбер кыйммәтләр югала, ә алар урынына икенчеләре туа. Кеше үзенә бәяне нәрсә ашаганы, нәрсә кигәне, нинди машинада йөргәне һәм кем белән аралашканыннан чыгып бирә башлады. Аллаһыга шөкер, барысы да түгел. Шулай да, гомумкешелек кыйммәтләре кими бару, янәшәндәге кешеләргә кыек карау, яки үзеңә файда китерә алучы кешеләр белән генә дус булу – бүгенге көннең бер тенденциясенә кайтып кала башлады бугай. Бүген бу контрастны төрле сыйныфларда күреп була: бай-ярлы, галим-надан, тулы гаиләле-ятим, танылган-гади кеше һ.б.

Әмма Кыямәт көнен искә төшерик. Кыяміттә берәр кеше үзенең дәрәҗәсенә, байлыгына карап алдарак торачакмы? Юк, нибары өч төркем булачак. «Вакыйга» сүрәсеннән «алда торучылар», «уң як әһелләре» һәм «сул яң әһелләре» булачагын гына беләбез. Бу, кадерле җәмәгать, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә каршында без барыбыз да тигез дигәнне аңлата. Без – Адәм балалары. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُم مِّن نَّفْسٍ وَاحِدَةٍ وَخَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالًا كَثِيرًا وَنِسَاءً ۚ وَاتَّقُوا اللَّهَ الَّذِي تَسَاءَلُونَ بِهِ وَالْأَرْحَامَ ۚ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلَيْكُمْ رَقِيبًا ﴿١﴾

**«Ий кешеләр! Сезне бер ата-анадан яратучы Аллаһыга каршылык күрсәтүдән сакланыгыз, Ул Адәмнең үзеннән хатын яратты вә икесеннән күп ирләрне һәм күп хатыннарны дөньяга чәчте. Янә Аллаһыга тәкъвалык кылыгыз, Ул – Аллаһы исеме белән бер-берегездән сорыйсыз, шулай булгач, Аллаһыны зурлагыз**

**вә якын кардәшләр хакыннан сакланыгыз! Аллаһы сезнең барча эшләрегезне тикшерүче, күзәтүче».**

«Нисә / Хатыннар», 4:1

Аллаһы Тәгалә бу аятьне Аңа каршылык китерүдән сакланырга боерып башлый. «Иттакуллаһ», ягъни Аллаһы каршында тәкъвалы булыгыз дип әйтә, чөнки Аллаһыдан курыккан кеше, калганнар хакына керүдән дә куркачак. Шулай итеп, кешелекнең барлыкка килү башы – бер, ә аның башлангычы – Адәм галәйһиссәлам. Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламне туфрактан бар итте, моның турында Коръәннән бик күп аятьләр китерергә була.

Аллаһы Тәгалә хәлифә итеп Адәмне Җиргә иңдерә. Менә шуннан соң Аллаһы Тәгалә кешелек дөньясын арттырып, бар дөньяга чәчә:

وَمِنْ آيَاتِهِ أَنْ خَلَقَكُم مِّن تُرَابٍ ثُمَّ إِذَا أَنتُم بَشَرٌ تَنتَشِرُونَ ﴿٢٠﴾

**«Дәхи, Аллаһының кодрәтенә дәлаләт иткән нәрсәләрнең берсе – асылыгыз Адәмне туфрактан бар кылды, соңрак сез кеше булып җир йөзенә таралдыгыз».**

«Рум», 30:20

Аллаһы Тәгалә кешеләрне төрле төстә, төрле кыяфәттә бар кылды, аларны дөнья буенча чәчте һәм, әлбәттә, вакытлары җиткәч, һәрберсе дә Аллаһыга кире әйләнеп кайтачаклар.

Аллаһы Тәгаләнең: **«Янә Аллаһыга тәкъвалык кылыгыз, Ул Аллаһы исеме белән бер-берегездән сорыйсыз, шулай булгач, Аллаһыны зурлагыз вә якын кардәшләр хакыннан сакланыгыз!»** – сүзләрен Әд-Дәххак: «Аллаһы исеме белән бер-берләрегез арасында килешүләр төзисез. Шуңа күрә Аллаһыдан куркыгыз. Туганнар арасын өзүдән дә куркыгыз. Аларга шәфкатьлелек белән карагыз һәм аларга һәрдаим ярдәм итегез», – дип тәфсир кыла.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам безгә җаһилият, наданлык вакытындагы тәкәбберлекне һәм нәсел белән мактануны тыйды. Кешеләрне ике төрлегә бүлеп: «Бер төрлеләренә тәкъвалык хас, алар мәрхәмәтле, яхшы кешеләр. Аларга капма-каршы – явыз, гөнаһлы, начар кешеләр бар. Бар кешеләр Адәмнән барлыкка килгән. Адәм исә балчыктан яратылган», – дип мөрәҗәгать итә. Расүлуллаһның бу хәдисендә безнең өчен бик әһәмиятле хәбәр бар. Бу сүзләрне ул Коръәндәге «Хүҗүрат / Бүлмәләр» сүрәсенең 13 нче аятен үзенең сәхабәләренә тәфсир кылганда әйткән булган. Аллаһы Тәгалә ул аятьтә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَىٰ وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا ۚ إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ ﴿١٣﴾

**«Әй, кешеләр, чынлыкта, Без сезне бер ир затыннан һәм бер хатыннан яраттык һәм бер-берегезне танып белсеннәр дип, халык һәм кабиләләргә бүлдек. Һәм Аллаһы хозурында хөрмәткә иң лаек булганыгыз – ул иң тәкъваларыгыз. Дөреслектә, Аллаһы белүче вә һәр эшегездән хәбәрдар».**

«Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:13

Аллаһы Аның хозурында хөрмәткә иң лаек, дип санарга мөмкин булган кешенең сыйфатларын билгели. Бу иң тәкъва, Аллаһы җәзасыннан иң нык курыккан, Аллаһыны башкалардан ныграк олылаган кеше. Аллаһы хозурында кеше иманы, тәкъвалыгы, хөрмәт итә белүе белән кыйммәтле була. Димәк, кешенең чыгышы, милләте, билгеле бер нәселгә яки ыруга каравы бу очракта әһәмиятле түгел.

Кешеләр җир йөзендә тарала бару белән, бүтән төрле уйлый, сөйләшә башладылар. Бу исә тора-бара төрле солыхларга, яки, киресенчә, низагларга китерде. Аларны бер фикергә кайтарыр өчен, Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләр җибәргән. Җир йөзенә килеп киткән һәрбер пәйгамбәр

дә кешеләр арасындагы мөгамәләне җайга салырга тырышкан, аларны бер-берләренә карата йомшак, гадел булырга өндәгән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам кешеләрнең тигез булуларына бик күп тапкырлар басым ясаган. Мәсәлән, ул: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә Адәмне Үзенең җиреннән куш уч балчык алып ясады. Һәм җирдән ясалган кешеләр җиргә охшаш та булдылар: кызыл, кара ак һәм сары. Һәм алар арасында йомшак, моңсу, яхшы һәм начар кешеләр бар», – дип әйткән.[1] Шуңа күрә кеше кайда гына тормасын, нинди ризык ашамасын – ул инде барлык булган мәхлүкъლардан өстен булып, «кеше» булып яратылган. Хайваннар, җәнлекләр, сулар – барысы да кешегә буйсындырылган. Кеше бу дөньяның хәлифәсе.

Шулай ук Пәйгамбәребез галәйһиссәлам дә үзенең соңгы хөтбәсендә: «Әй, кешеләр! Бу васыятемне монда булган кешеләр бирелдә була алмаучыларга да җиткерсеннәр. Раббыгыз бердер. Атагыз да бердер, сез барыгыз да Адәм балалары. Аллаһы каршында иң кадерлеләрегез – Аңа бөек хөрмәт күрсәтүчеләрегездер. Гарәпнең гарәп булмаганнардан Аллаһыны хөрмәтләүдән башка бернинди өстенлеге дә юк. Ий, Аллаһы! Сүзләреңне халкыма җиткерүгә Үзең шаһит бул!» – дип әйтә.

Онытма: Синең ярлы күршеңә дә яшәр өчен һава кирәк, сиңа да! Синең ярлы дустыңа да яшәр өчен ризык кирәк, сиңа да! Синең танышларың да бер ата белән бер анадан туганнар, син дә. Ягъни барлык табигый ихтыяҗларны кеше бертөрле үти: ашый, йоклый, ял итә, юына, бәдрәфкә бара.

Чын мөэмин-мөселман үзенең дәрәҗәсе, байлыгы белән масаймас, чөнки аңа Аллаһы Тәгалә байлыкны шул байлыктан өлеш чыгарыр микән, дип бирә. Ярлы кеше бай кешене күргәч, аның байлыгына кызыкмас. Әмма ул: «Байлыгым булса, мин дә күп итеп садака бирә алыр идем», – дип, үзенә байлык сорый ала.

[1] Сахих Ибне Хиббән хәдисләр җыентыгыннан

Аллаһы Тәгалә безнең тышкы кыяфәтебезгә һәм малыбызга карамый. Ул безнең йөрәгебезгә һәм кылган гамәлләребезгә карый. Бу – хәдис. Югарыдагы сүзләрдән Пәйгамбәребезнең дә бу мәсьәләгә карашын белеп була. Ул беркайчан да кешеләрнең бер-берсен мыскыл итүләрен, рәнҗетүләрен кабул итмәгән. Кешеләрне золым кылудан саклаган, аның бик зур гөнаһ икәнен гел искәртеп торган.

Бу дөнья кешеләрнең гел янәшә яшәүләренә корылган. Беркем дә: «Миңа монда ошамый әле», – дип, аскет тормышы белән яшәргә чүлгә, далага китми. Шулай ук башка бер планетага да китеп, шунда гомер кичергән кешеләр турында ишеткәнегез юктыр. Кечкенә генә авыл да, зур мегаполислар да кешеләрнең бер-берләре белән элемтәдә яшәүләренә корыла. Кечерәк авылларда кешеләр, гомумән, урамның бер башыннан икенче башына кадәр бер-берләренә туган да була алалар. Ничек кенә булмасын, кеше һәр көн кем белән булса да элемтәгә керә: эштәге хезмәттәшләр, җитәкчеләр, автобуста кондукторлар, янәшә утырып баручы пассажирлар, кафелардагы хезмәткәрләр, кибеттәге сатучылар һ.б. Һәм хәтта ки гаилә мөнәсәбәтләрен дә моңа кертеп карап булыр иде. Һәм без бер-берләребездән башка яши дә алмас идек. Һәр кеше үз урынында кирәкле һәм үз вазифасын башкара. Әмма бөтен кеше җитәкче була алмый – эшчеләр калмас; авыл җирлекләрендә фермаларны бетереп, бөтен кеше шәһәрдә офиста эшли башласа – ашарга ризык та булмас. Без исә шушы дәрәҗәләрәгә карамастан, бер-берләребез белән татулыкта яшәргә өйрәнергә тиеш. Бер мөселман икенчесен күрсә, сәлам әйтергә тиеш; кунакка чакырса, кабул итеп килергә; киңәш сораса, ихластан киңәш бирергә; авырса, хәлен белергә барырга, үлсә, җеназасына барырга тиеш. Менә бу – алтын кагыйдәләрнең кайберләре генә.

Кадерле мөселманнар! Җомгага дип мәчетләргә җыелдык. Бер сафта намаз укыган мөселманнар, урамда бер-берләренә сәлам дә бирмәскә мөмкин. «Мин Коръәнне яттан беләм, ә ул хәреф тә танымый». «Ми-

нем машинам аның фатирыннан кыйбатрак». Мөэмин-мөселманның башына мондый фикерләр ничек килә ала соң? Сәхабәләр заманында мөселманнар дин мәсьәләсендә кызып-кызып бәхәсләшә алганнар. Әмма дөньяви эшләргә килгәндә, алар бер-берләренә бармак та күтәрмәгәннәр. Киресенчә, утырып, бергә чәй эчкәннәр. Менә бу күрсәткеч түгелме?

Сәхабәләр тормышыннан моңа тагын бер мисал булып түбәндәге вакыйга тора ала. Бервакыт сәхабәләр җыелышында Пәйгамбәребез галәйһиссәлам була алмады. Әмма анда бик күркәм сәхабәләр: Хәлид бине Вәлид, Габдрахман бине Гавеф, Билал бине Рабәхә һәм Әбү Зәрр Әл-Гыйфари кебекләр җыелган иде. Табигате ягыннан Әбү Зәрр бик тиз кызып китүчән кеше була. Кешеләр бер-бер артлы үзләренең фикерләрен әйтә башлыйлар. Әбү Зәрр үзенең сөйләмендә хата ясагач, Билал аны төзәтеп куя. Әбү Зәрр кызып китеп: «Син дә, кара тәнле ана баласы, мине гаеплисең?!» – дип әйтә. Билал радыяллаһу ганһе моны Пәйгамбәребезгә әйтәм дип, чыгып китә. Һәм бу сүзләр Мөхәммәд пәйгамбәргә ирешкәч, аның йөзе бик үзгәрә. Моны ишеткән Әбү Зәрр да мәчеткә ашыга һәм анда кергәч: «Әссәләмү галәйкүм, Аллаһының Илчесе», – дип әйтә. Һәм Әбү Зәрр бу вакыйганы сөйләгәндә: «Ул миңа җавап кайтардымы, юкмы, анысын хәтерләмим», – дип өсти.

Пәйгамбәребез аңа карап: «Әй, Әбү Зәрр, син аңа анасы аркасында шелтә белдергәнсең. Дөреслектә, синең күңелеңнән җаһилият чоры чыгып бетмәгән әле», – дип нәсыйхәт бирә. Әбү Зәрр елый-елый мәчеттән чыгып, Билалны эзли башлый. Аны базарда очрата, каршына килеп тезләнә, бер битен җиргә куя һәм: «Син минем битемә аягың белән басмыйча, мин моннан кузгалмыйм. Дөреслектә, син намуслы, ә мин түбән кеше», – дип әйтә. Билал аны торгызып, битеннән үбеп ала һәм: «Аллаһыга сәҗдә кылган маңгайга аяк баса алмый», – дип җавап кайтара.

Кадерле мөэмин-мөселманнар! Дин – ул барлык мөселманнарга карата эчкерсезлек. Ул – үзеңә теләгәнне калганнарга да чын күңелдән

теләү, үзең тыелганнардан калганнарны да саклау, үзеңә ярлыкау сорагандa, калган мөселманнар өчен дә сорау һ.б. Аллаһы Тәгалә безнең белеп һәм белми кылган гөнаһларыбызны ярлыкасын иде. Аллаһыдан үзебезгә йомшак калеб, яхшы зиһен сорыйк. Бер-берләребезгә игътибарлы булып, ярдәмләшеп, Коръәндәгечә кардәшләр булып яшәргә насыйп булса иде. Әмин!

*ТҖ МДН Дәгъват бүлеге*

*9 нчы ноябрь вәгазе,*

*Рабигыль-әүвәл аенының 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Мөхәммәд пәйгамбәр – галәмнәр өчен рәхмәт

Барча галәмнәрне бар кылып, аларны тәрбия кылып торучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итеп кылучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде!

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا رَحْمَةً لِّلْعَالَمِينَ ﴿١٠٧﴾

**«Ий Мөхәммәд, Без сине галәмнәргә рәхмәт өчен генә җибәрдек».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:107

Аллаһы Тәгалә кешелеккә Коръән китабы буенча яшәргә өйрәткән Пәйгамбәрен шушы рәвешле мактый. Пәйгамбәрлек вазифасы – Аллаһының рәхмәте булып тора. Пәйгамбәр Аллаһының рәхмәте белән кешеләрне бер Аллаһыга гыйбадәт кылырга чакырды, аларны ялгыш юлдан туры юлга, караңгылыктан яктылыкка, нурга чыгарды. Бу рәхмәтне кабул иткән кешегә ике дөнья бәхете биреләчәк. Кабул итмәүче кеше исә бу дөньяда да, Ахирәттә дә бәхетле булмаячак, чөнки Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَن يُطِعِ اللَّهَ وَرَسُولَهُ وَيَخْشَ اللَّهَ وَيَتَّقْهِ فَأُولَٰئِكَ هُمُ الْفَائِزُونَ ﴿٥٢﴾

**«Берәү Аллаһыга вә Расүлгә итагать итсә вә Аллаһыдан курыкса һәм гөнаһлы булудан сакланса, алар бөек дәрәҗәгә ирешүчеләрдер».**

«Нур», 24:52

Пәйгамбәребезнең бу дөньяга рәхмәт булуы бик күп аять-хәдисләр белән дәлилләнә. Аңа иярү – җәннәт юлы, аңа иярү – бөек дәрәҗәләргә илтә. Иң яхшы юл – пәйгамбәрләр юлы:

انظُرْ كَيْفَ كَذَبُوا عَلَىٰ أَنفُسِهِمْ ۚ وَضَلَّ عَنْهُم مَّا كَانُوا يَفْتَرُونَ ﴿٢٤﴾

**«Расүлләрне җәннәт белән шатландыручы вә җәһәннәм газабы белән куркытучы итеп кенә иңдерәбез. Иман китереп, Коръән юлы белән тәрбияләнеп төзәлгән мөэминнәргә Ахирәттә курку һәм кайгы булмас».**

«Әнгәм / Терлек», 6:24

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам Коръәнне 23 ел буена тәфсир кылды. Һәрвакыт үзенең өммәте өчен тырышты. Мигъраҗ вакытында да өммәте өчен җәннәткә керә торган гамәл сорады. Кешеләр аны кире каккан вакытта да, ул үзенең рәхимле кеше икәнен исбатлап торды.

Пәйгамбәребезнең Таиф шәһәренә барып, андагы кешеләрне дингә чакыруы исегездәме? Балаларга хәтле аңа ташлар атып, аны куа башладылар. Пәйгамбәребезнең тәне тулы җәрәһәт иде һәм аккан каннан аның аяк киеме дә кызыл төскә манылды. Юлда ул Аллаһы Тәгаләгә болай дип дога кылды: «Ий, Аллаһым, мин үземнең көчсезлегемнән һәм калганнар тарафыннан җәберләнүдән Сиңа сыенам. Ий, рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе, Син зәгыйфьләрнең Раббысы. Мине кемнәр кулына тапшырасың? Мине күргәч, куркып, җебеп калганнар, әллә көчле дошманнар кулынамы? Ий,

Аллаһым, Син миңа ачулы булмасаң, калганы минем өчен бик мөһим түгел. Миңа Синең яклавың һәм саклавың җитә. Мин Синең ачуыңнан һәм газабыңнан Синдә генә сыену эзлим. Ий, Аллаһым, Син Үзеңнең нурың белән караңгылыктан яктылык ясыйсың, миңа Синең разый булуың гына кирәк. Дөреслектә, Син генә камил Көч иясе һәм Патшасың».

Җәбраил галәйһиссәлам килеп, аны сәламли һәм: «Аллаһы Тәгалә бу шәһәр кешеләренең сине ни рәвешле кабул иткәннәрен күреп, таулар белән идарә итә торган фәрештәгә сиңа буйсынырга кушты», – дип әйтә. Шул фәрештә килеп: «Мин сезнең әмерегезне үтәргә әзер. Теләсәгез, мин ике тауны урыннарыннан күчереп куям. Ә ул шәһәр халкы шул тау астында калачаклар. Яки бүтән бер әмер бирә аласыз, анысын да үтәрмен», – дип әйтә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам бу фәрештәләргә: «Бу буын Ислам динен кабул итмәсә дә, бу буын артыннан килгән кешеләр Ислам динен кабул итеп, Аллаһыны үзләренең илаһе итеп таныйрлар, дип өметләнәм», – дип җавап кайтара.

Бу Пәйгамбәребезнең никадәр рәхим-шәфкатьле булганы турында сөйләмиме? Үлемнән калды һәм аның үч алырга мөмкинчелеге дә бар. Шәһәрдә яшәүче халыкның динне кабул итүләре дә шикле («киләчәк буын кабул итәр, дип ышанам») – шушы вакытта да ул сабыр булып, үзенең галәмнәргә рәхмәт буларак иңдерелгәнен исбатлады. Әгәр дә гафу итә белүне бер кечкенә елга белән чагыштырып булса, Пәйгамбәребез бу сыйфаты белән диңгез, яки океанга охшар иде. Без дә Пәйгамбәребез сөннәтенә иярергә тырышабыз, әмма берәр кеше белән низаг килеп чыкса, ул кеше белән нигәдер 3 кенә көн түгел, айлар, еллар буе сөйләшмичә тора алабыз.

Пәйгамбәребезнең рәхмәт буларак җибәрелүе турында түбәндәге аять тә сөйли ала. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَإِنَّكَ لَعَلَىٰ خُلُقٍ عَظِيمٍ ﴿٤﴾

**«Тәхкыйк, син күркәм холык әһеле».**

«Нун», 68:4

Бу аятьтә Пәйгамбәребез иң югары, гүзәл әхлак иясе, дип әйтелә. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә аңа камиллекне, югары дәрәҗәне бирде. Пәйгамбәребезгә бирелгән дәрәҗәләр, башка бернинди пәйгамбәргә дә, бернириди кешегә дә бирелмәде һәм бирелмәс тә. Аллаһы Тәгалә аның турында: «Тәхкыйк, син күркәм холык әһеле», – дип әйтә. Шуңа күрә дә Пәйгамбәребез зур гыйлемле, сабыр, түземле, оялчан булган. Ул Аллаһы Тәгаләгә бик күп гыйбадәт, калганнарга караганда күбрәк дога кылган. Кешеләрне гафу итә белгән, һәрвакытта да яхшылыкка гына өнди торган булган. Ул һәрвакытта да гадел булырга, мохтаҗларга, ятимнәргә ярдәм итәргә, олыларны хөрмәт итәргә, туганнар арасындагы мөнәсәбәтне сакларга кушкан. Пәйгамбәребез бәхәсләшмәгән, сөйләшкәндә тавышын күтәрмәгән. Ул дингә карамаган очракларда ачуланмаган, беркайчан да ялганламаган, хакны гына сөйләгән. Гайбәт, алдалау, начар сүзләрдән бик ерак булган. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا كَافَّةً لِّلنَّاسِ بَشِيرًا وَنَذِيرًا وَلَـٰكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَعْلَمُونَ ﴿٢٨﴾

**«Ий Мөхәммәд, Аллаһыга итагать иткәннәрне җәннәт белән шатландырыр өчен вә итагать итмәгән кешеләрне җәһәннәм газабы белән куркытыр өчен Без сине барча дөнья кешеләренә пәйгамбәр итеп җибәрдек, ләкин күп кешеләр шуны белмиләр».**

«Сәба», 34:28

Аллаһы Тәгалә башка пәйгамбәрләрне аерым бер кавемгә, билгеле бер вакытка гына җибәргән. Пәйгамбәребез исә барча мәхлүкат өчен, ягъни кешеләргә дә җеннәргә дә, җансыз әйберләргә дә пәйгамбәр булып тора. Мөслим тапшырган хәдистә болай дип әйтелә: «Мин бар-

лык мәхлүкъларга да пәйгамбәр итеп җибәрелдем». Җеннәрнең Пәйгамбәребездән Коръәнне ишеткәннән соң әйткән сүзләре исегездәме?

قُلْ أُوحِيَ إِلَيَّ أَنَّهُ اسْتَمَعَ نَفَرٌ مِّنَ الْجِنِّ فَقَالُوا إِنَّا سَمِعْنَا قُرْآنًا عَجَبًا ﴿١﴾
يَهْدِي إِلَى الرُّشْدِ فَآمَنَّا بِهِ ۖ وَلَن نُّشْرِكَ بِرَبِّنَا أَحَدًا ﴿٢﴾

**«Әйт: «Миңа вәхи кылынды, Аллаһыдан хәбәр бирелде, тәхкыйк, миннән җеннәрдән бер таифә Коръәнне тыңлады, ул җеннәр кавемнәренә барып сөйләделәр: «Тәхкыйк, без гаҗәеп Коръәнне ишеттек! Ул Коръән туры юлга күндерәдер. Без ул Коръәнгә иман китердек, әлбәттә, Раббыбызга һичкемне тиңдәш кылмабыз».**

«Җиннун / Җен», 72:1-2

Әйе, Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам галәмнәргә җибәрелгән. Кешелек дөньясы да, җеннәр дөньясы да аның пәйгамбәр булуын таныганнар. Бүгенге көндә дә Пәйгамбәребез тырышлыгы аркасында безнең динебез, алга барыр максатыбыз бар.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّا أَعْطَيْنَاكَ الْكَوْثَرَ ﴿١﴾

**«Күркәм холык һәм Ахирәттә Кәүсәр елгасын бирдек, ул елга сиңа һәм өммәтеңә хастыр».**

«Кәүсәр», 108:1

Кәүсәр – пәйгамбәрлек вазифасының бөеклеге, ике дөнья бәхете. Кәүсәр – җәннәттәге елга. Аның суы балдан баллырак, сөттән аграк. Аның ярлары энҗе-якутлардан ясалган. Ә Кыямәт көнендә бөтен кешенең дә бик каты эчәсе килер. Аның суын бер тапкыр эчкән кеше бүтән беркайчан да сусамас. Шуңа да Пәйгамбәребез өммәтеннән булган кешеләр бу

елгага килерләр. Монафикъларны куган вакытта да, Пәйгамбәребез: «Йә, Раббым, бу бит минем өммәтем», – дип борчылыр.

Кыямәт көнендә Пәйгамбәребез кайбер кешеләр өчен җәннәттә зуррак дәрәҗә сорап; кайбер кешеләрне уттан чыгарыр өчен; кайбер кешеләр өчен утта җиңелрәк җәза булуын сорап, шәфәгать кылыр. Ә шәфәгатьне Адәм дә, Нух та, Гайсә һ.б. пәйгамбәрләр дә кыла алмас. Кешеләр Мөхәммәд галәйһиссәлам янына барырлар. Һәм ул Аллаһыга ялварырга керешер! Кадерле җәмәгать, менә хәзер Пәйгамбәребезнең нинди зур дәрәҗәле кеше икәнен аңладыгызмы инде? Иң яхшы әти, иң яхшы ир, иң яхшы күрше, иң яхшы дус, иң яхшы кеше! Пәйгамбәребез чиста күңелле, якыннары, дуслары турында кайгыртучан, изге ниятле кеше булган. Ул еш елмайган, ләкин беркайчан да кычкырып көлмәгән. Үзе генә калганда, бик моңсу һәм уйчан булган.

Пәйгамбәребез бик юмарт, тыйнак һәм тәкәбберлектән ерак кеше булган. Җыелышларда аерым бер урынга утырмаган, буш урын эзләгән. Күп очракта кыйблага карап, аякларын тездән бөгеп утырган. Аның сөйләме кыска, шул ук вакытта күп мәгънә сыйдыра торган булган. Ул оста, ачык һәм матур итеп сөйләгән, ләкин озак дәшмичә дә торган.

Шуңа күрә аңа күбрәк салаватлар әйтеп, Аллаһы Тәгаләдән аны безгә дә шәфәгатьче итеп кылуын сорарга кирәк.

*Илнар хәзрәт Фәхретдинов,*

*Мамадыш районы Тубән Ушма авылы мәчете имам-хатыйбы*

*16 нчы ноябрь вәгазе,*

*Рабигыль-әүвәл аеның 8 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең кыйммәте

Барча галәмнәрне барлыкка китергән, безне Үз рәхмәтеннән ташламаган: пәйгамбәрләр, китаплар җибәреп, хак юл бүләк иткән Аллаһы Тәгаләгә хәмед сәналәребез булса иде. Шулай ук Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән сөендергән вә газабы турында кисәткән пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә дә күңелләребезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Мөхтәрәм мөселман кардәшләр! Бүгенге вәгазьдә сезгә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең холкы турында сөйләргә телим.

Иман кәлимәсенең беренче өлеше «Ләә иләһә илләл-Лааһ» – «Аллаһыдан башка гыйбадәт кылырга лаеклы бер зат та юк» булса, икенче өлеше – «Мүхәммәдүн расүлүл-Лааһ» – «Мөхәммәд Аллаһының Илчесе». Бу сүзләрнең мәгънәсен аңлаган кеше Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм җиткергән бөтен хәбәргә ышанырга һәм аны үз тормышының һәр өлкәсендә үрнәк итеп сайларга тиеш була.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хакында:

وَإِنَّكَ لَعَلَىٰ خُلُقٍ عَظِيمٍ ﴿٤﴾

**«Дөреслектә, син бөек холыклы»,** – дип әйтә.

«Нун», 68:4

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм кешеләргә Аллаһы Тәгаләнең бердәнбер гыйбадәткә лаеклы Зат икәнлеген аңлату һәм алар-

га күркәм холыкны өйрәтүче буларак җибәрелде. Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе үк: «Дөреслектә, мин күркәм холыкларны төгәлләү өчен генә пәйгамбәр итеп җибәрелдем», – дип әйтә.[1]

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе аның турында: «Аллаһы Илчесе кешеләрнең иң күркәм холыклысы иде», – дип әйтә.[2]

Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хатыны Сафия бинтү Хүйәй: «Мин Аллаһының Илчесеннән дә күркәмрәк холыклы кешене күрмәдем», – дип әйткән.[3]

Бервакытны Сәгъд бине Һишәм Гайшә радыяллаһу ганһәдән: «Миңа Аллаһының Илчесенең холкы турында сөйлә әле», – дип сораган. Ул: «Аның холкы Коръән иде», – дип җавап биргән.[4]

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һәр кылган гамәле Коръән аятьләре белән туры килде. Ул Аллаһы Тәгалә Коръәндә әмер иткән бөтен нәрсәне үтәде һәм Ул тыйган бөтен нәрсәдән тыелды. Ягъни Коръән белән гамәл кылу аның холкына әверелде. Ул Коръән белән ничек гамәл кылырга кирәклеген үзенең үрнәгендә күрсәтте. Коръәндә әйтелгән сүзләр белән аның кылган гамәлләре аз гына да аерылмады. Шуңа күрә Коръәнне дөрес аңлау өчен Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормыш юлын бөтен нечкәлегенә хәтле өйрәнергә кирәк.

Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күркәм холкын без аның хатыннарына карата яхшы мөнәсәбәтендә дә күрәбез. Ул: «Сезнең иң хәерлегез – хатынына иң яхшы мөнәсәбәттә булганы. Ә мин сезнең арада хатынга иң яхшы мөнәсәбәттә булучы», – дип әйтә.[5]

Ул хатыннарына өй эшләрендә ярдәм итә иде. Әл-Әсвәд бине Йәзид: «Бервакытны мин Гайшә радыяллаһу ганһәдән: «Мөхәммәд

1 Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан, № 9187
2 Имам Бохари һәм Мөслим хәдис җыентыкларыннан
3 Имам Табарани хәдисләр җыентыгыннан
4 Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан
5 Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

галәйһиссәлам өйгә кайткач нәрсә эшли иде?» – дип сорадым. Ул: «Ул хатынына булыша иде. Әгәр дә намаз вакыты җитсә, торып намаз укый торган булды», – дип җавап кайтарды», – дип сөйләгән.[1]

Башка бер хәдистә Гайшә радыяллаһу ганһә: «Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм аяк киемен үзе төзәтә, киемен үзе тегә һәм башка ирләр кебек өйдә эшли иде», – дип әйтән.[2]

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм вакыт-вакыт хатыннары белән спорт белән дә шөгыльләнгән. Гайшә радыяллаһу ганһәдән риваять ителә: «Бервакытны мин Аллаһының Илчесе белән сәфәргә чыктым. Ул чакта мин гәүдәгә бик үк таза булмаган яшь кыз идем». Мөхәммәд галәйһиссәлам кешеләргә: «Монда килегез», – дип әйтте һәм алар килделәр. Соңыннан ул миңа: «Йөгерү өчен бирегә кил», – диде. Шуннан соң мин аның белән йөгердем һәм алдан килдем. Ул миңа бернәрсә дә әйтмәде. Бераз үсеп гәүдәгә тазаргач, мин аның белән тагын сәфәргә чыктым. Бу юлы да Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм кешеләргә: «Монда килегез», – дип әйтте һәм алар килделәр. Соңыннан ул миңа: «Йөгерү өчен бирегә кил», – диде. Бу юлы йөгергән вакытта ул мине узды. Шуннан соң ул: «Бу теге юлы узганың өчен», – диде һәм көлде».[3]

Ул бервакытта да хатыннарына һәм хезмәтчеләренә тавыш күтәрмәде, мыскыл итмәде. Гайшә радыяллаһу ганһә: «Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм бервакытта да хезмәтчесенә һәм хатынына кул күтәрмәде. Шулай ук ул кулы белән бернәрсәгә сукмый иде, бары тик Аллаһы юлында көрәшсә генә дошманнарга кырыслык күрсәтте. Әгәр дә ул ике нәрсәнең берсен сайларга тиеш булса, гөнаһ булмаган очракта, ул аларның иң җиңелен сайлый иде һәм ул нәрсә аның өчен иң сөеклесе булды. Әгәр дә ул гамәл гөнаһ булса, ул гөнаһтан иң ерак булучы кеше иде. Ул үзенә карата эшләнелгән начар гамәл өчен үч алмый иде. Иллә дә

[1] Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

[2] Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан

[3] Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан

мәгәр, Аллаһы тыйган нәрсәне бозган очракта гына ул Аллаһы өчен үч ала торган булды», – дип әйткән.[1]

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе болай дип әйтә: «Мин Аллаһы Илчесенең кулы шикелле йомшак атлас һәм ефәк бер тукыма да тотмадым. Шулай ук мин Аллаһы Илчесеннән килә торган кебек башка бер хуш исне дә тоймадым. Мин Аллаһының Илчесенә ун ел хезмәт иттем. Шушы вакыт эчендә ул миңа бер тапкыр да «уф» дип, берәр эшне эшләгәннән соң, «ни өчен аны эшләдең?» йә булмаса,  эшләмәгән берәр эш өчен «ни өчен аны эшләмәдең?» дип әйтмәде».[2]

Бервакытны Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хатыны Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә (икенче риваятьтә Зәйнәб бинте Җәхеш) Аллаһының Илчесенә бер кеше аркылы савыт белән ризык җибәрде. Шул вакытта Гайшә радыяллаһу ганһә таш тотып килеп керде һәм аның белән савытны ватты. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сезнең әниегез бераз көнләште», – дип ватылган савытны җыя башлады. Соңыннан ул Өмме Сәләмәнең савытын Гайшәгә бирде, ә Гайшәнең савытын Өмме Сәләмәгә илтеп бирергә кушты».[3]

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам гади тормыш рәвеше алып барды. Ул кешеләр белән дөнья кууда ярышмады. Аллаһы Тәгалә аңа кулында патшалык булган пәйгамбәрлек белән Аллаһыга күп гыйбадәт кылучы пәйгамбәрлек арасында сайлау хокукын бирде һәм ул икенчесен сайлады.

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһедән риваять ителә: «Бервакытны мин Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына кердем. Ул бу вакытта пальма ботакларыннан ясалган матраста ята һәм аның баш астында пальма сүсләре тутырылган тиредән ясалган мендәр иде. Шул вакытны аның янына бер төркем сәхабәләр һәм Гомәр бине Әл-Хаттаб

1 Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан

2 Имам Бохари һәм Мөслим хәдис җыентыкларыннан

3 Имам Нәсәи хәдисләр җыентыгыннан

радыяллаһу ганһе керде. Мөхәммәд пәйгамбәр алар кергәч торып утырды. Шул вакыт Гомәр радыяллаһу ганһе аның аркасында матрастан калган эзләрне күреп, елап җибәрде. Мөхәммәд пәйгамбәр аңа: «Әй, Гомәр, син нишләп елыйсың?» – диде. Ул: «Аллаһы белән ант итәмен ки, мин синең Аллаһы Тәгалә каршында Фарсы һәм Рум патшасына караганда да хөрмәтлерәк кеше булуыңны белгәнгә күрә елыйм. Алар дөнья ләззәтенә чумып яшиләр, ә син, йә Аллаһының Илчесе, мин күргән хәлдә яшисең» – ди. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Әллә син аларга бу дөнья, ә безгә Ахирәт булуына риза түгелме?» – ди. Гомәр: «Әйе, риза», – дип җавап кайтарды».[1]

Ул үзен чиктән тыш югары күтәрүдән тыйды. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Насаралар Мәрьям улы Гайсәне чиктән тыш зурлаган (алар аны Аллаһының үзе яки улы, дип әйткән) кебек мине зурламагыз. Мин бары тик Аллаһының гади бер колы гына. Шуңа күрә минем турында: «Аллаһының колы һәм илчесе генә дип әйтегез», – дигән.[2]

**Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең балаларга мөнәсәбәте.**

Әнәс бине Мәлик: «Мөхәммәд пәйгамбәр балалар яныннан узса, аларга сәлам бирә иде», – дип әйтә.[3]

Кайбер вакытта аналар мәчеткә яшь балалары белән киләләр иде. Әгәр дә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм намаз укытканда сабый баланың елаган тавышын ишетсә, анасын авыр хәлдә калдырмас өчен, намазын тизрәк укый торган булды. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Дөреслектә, мин намаз укырга баскач, аны озаграк укырга телим, ләкин сабый баланың тавышын ишеткәч, әнисенә авырлык тудырырга куркып, аны кыскарак укытам».[4]

1 Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан
2 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан
3 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан
4 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

**Мөхәммәд пәйгамбәрнең йомшаклыгы.**

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе: «Бервакытны без мәчеттә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән бергә утыра идек. Шул вакытны бер чүл гарәбе (бәдәви) килеп керде һәм мәчеттә кече хаҗәтен үти башлады. Бу хәлне сәхабәләр күргәч: «Тукта, тукта, син нишлисең», – дип аны әрли башладылар. Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларга: «Бүлмәгез аны, калдырыгыз», – диде. Хаҗәтен үтәп бетергәнчегә хәтле сәхабәләр аңа тимәде. Шуннан соң Мөхәммәд пәйгамбәр аны үзе янына чакырды һәм: «Дөреслектә, мәчеттә хаҗәтне үтәргә ярамый. Ул бары тик Аллаһыны искә төшерү, намаз үтәү һәм Коръән уку өчен генә кулланыла», – диде. Шуннан соң ул бер кешегә чиләк белән су алып килеп, шул урынга түгәргә кушты».[1]

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күркәм әхлагы сөйләмендә дә күренә. Сира галимнәре хәбәр итүенчә, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм матур сөйләшүче һәм зиһенле кеше иде. Әгәр дә ул сөйләшсә, ашыкмыйча, аңлаешлы сүзләр кулланып сөйләде. Шуңа күрә тыңлаучы аның әйткән сүзләрен бик җиңел истә калдыра иде. Гайшә радыяллаһу ганһә: «Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм сезнең кебек ашыгып сөйләшмәде. Ул янында утыручы кеше истә калдырырлык итеп, сүзләрне бер-берсеннән аерып сөйли иде», – дип әйтә.[2]

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм күп сөйләшмәгән. Әгәр дә ихтыяҗ булмаса, ул эндәшмәгән. Сөйләгән вакытта ул кыска җөмлә белән тирән мәгънәне кешеләргә җиткерә торган булган. Бу Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең башка пәйгамбәрләргә бирелмәгән сөйләм белән бәйле могҗизасы булды. Ул аны үзе «җәвәмигуль-кәлим» дип атады. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә:

---

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

2 Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

«Мин бик күп мәгънәне үз эченә җыйган кыска сөйләм рәвеше (җәвәмигуль-кәлим) белән пәйгамбәр итеп җибәрелдем һәм миңа дошманнарның күңеленә курку хисе салыну белән ярдәм ителде. Йоклаган вакытта миңа җирнең бөтен байлыгын алып килделәр һәм кулыма куйдылар».[1]

Әгәр дә Мөхәммәд пәйгамбәр көләргә теләсә, елмая гына иде. Бу вакытта аның урта тешләре күренә торган булды.

Аллаһы Тәгалә барчабызга да Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне үрнәк итеп алырга, аңа һәр көнне салават әйтергә ярдәм итсен һәм җәннәттә дә безне аның белән бергә кылсын. Әмин! Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтү – ул Аллаһы Тәгаләдән аны мактауны, дәрәҗәсен күтәрүне һәм аңа рәхимле булуны сорауны аңлата. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

«Кем дә кем иртә һәм кич миңа ун тапкыр салават әйтсә, Кыямәт көнендә ул минем шәфәгатемә лаек була», – дип әйткән.[2]

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*

*«Галиев» мәчете имам-хатыйбы*

---

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

[2] Имам Табарани хәдисләр җыентыгыннан

*23 нче ноябрь вәгазе,*

*Рабигыль-әүвәл аеның 15 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Җәннәт – аналарның аяк астында

Безне юктан бар кылган, ризыкландырган, киендергән, парыбызны, балаларыбызны биргән Аллаһы Тәгаләгә барча мактауларыбыз ирешсен, Аның илчесе, расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифәләребез барып ирешсен.

Ата-ана хакы турында Аллаһы Тәгалә Изге Китабында болай дип әйтә:

وَقَضَىٰ رَبُّكَ أَلَّا تَعْبُدُوا إِلَّا إِيَّاهُ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا ۚ إِمَّا يَبْلُغَنَّ عِندَكَ الْكِبَرَ أَحَدُهُمَا أَوْ كِلَاهُمَا فَلَا تَقُل لَّهُمَا أُفٍّ وَلَا تَنْهَرْهُمَا وَقُل لَّهُمَا قَوْلًا كَرِيمًا ﴿٢٣﴾

**«Аллаһы фәкать Аллаһыга гына гыйбадәт кылырга һәм ата-анага изгелек итәргә хөкем итте, әмер бирде. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга «уф» та димә вә каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә, бәлки аларга һәрвакыт йомшак вә мөлаем сүзләр сөйлә!»**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:23

Сөекле Пәйгамбәребез ата-аналарга карата итагатьле булу кирәклеген һәрвакыт ассызыклап, сәхабәләренә аңлатып торган. Бервакыт сәхабәләр аннан: «Иң яхшы гамәл булып нәрсә тора?» – дип сорыйлар. Расүлуллаһ галәйһиссәлам: «Вакытында укылган намаз», – ди. Аннан янә: «Ә аннан соң?» – дип кызыксыналар. Моңа ул: «Ата-анаңа карата мәрхәмәтле булу», – дип җавап кайтара. Бу хәдистән күрәбез ки,

шәһадәт китергәннән соң иң зур, иң яхшы һәм саваплы гамәл булып вакытында укылган намаз тора. Ә намазның нинди мөһим гыйбадәт икәне һәркайсыбызга мәгълүм. Намаздан соң иң яхшы гамәл дип Пәйгамбәребез әти-әниебезгә итагать итү, мәрхәмәтле булуны билгели. Димәк, динебездә ата-анабызны олылау, хөрмәтләү шундый дәрәҗәгә куелган.

«Нисә» сүрәсенең 36 нчы аятендә Аллаһы Раббыбыз безгә саваплы, хәерле гамәлләрне санап китә. Шуның бер өзеген генә китерәсем килә:

وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا ﴿٣٦﴾

**«Аллаһының Үзенә генә ихлас гыйбадәт кылыгыз, Аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылмагыз, аннары: ата-анага изгелек итегез ...»**

«Нисә / Хатыннар», 4:36

Янә күрәбез, Раббыбыз безгә ата-анага изгелек кылырга боера. Ә аларны рәнҗетү, авырлык китерү, борчуга салу, ярдәм күрсәтмәү – зур гөнаһ.

Ислам динендә әни кешенең дәрәҗәсе һәм урыны аеруча югары. Ана 9 ай дәвамында безне карынында – йөрәге астында йөрткән, көчле авыртулар кичереп бу дөньяга тудырган, аннан имезгән, ашаткан, караган, тәрбияләгән, көннәрен-төннәрен безгә багышлаган. Ана кеше балаларының тәрбиясенә иң күп вакыт сарыф иткән кеше, ул баласын иманлы, тәрбияле кеше итеп үстерим дип зур тырышлык куя. Шул сәбәпле, әниеңне рәнҗетү, үпкәләтү – хәтта әтиеңне рәнҗетүгә караганда да зуррак гөнаһ.

Күбебезгә мәгълүм хәдис: бервакыт сәхабәләрнең берсе Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән: «Мин кемгә күбрәк итагать итәргә тиешмен?» – дип сорый. Сөекле Пәйгамбәребез ни ди? «Әниеңә», – дип җавап кайтара. Сәхабә янә: «Ә аннан соң кемгә?» – дип сорый. Расүлуллаһ: «Әниеңә», – ди. Сәхабә тагын бер тапкыр: «Ә аннан соң, йә Расүлуллаһ?»

– дип сорый. Җавабы – әниеңә. Инде сәхабә дүртенче мәртәбә соравын кабатлагач, Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Әтиеңә», – дип әйтә. Ягъни өч тапкыр рәттән Пәйгамбәребез һәркайсыбыз өчен иң кадерле, хөрмәткә һәм игътибарга иң лаек кешенең әниебез булуын ассызыклый. Безгә билгеле, Коръәндә һәм хәдисләрдә өч тапкыр кабатлау – ул безаеруча игътибар итәргә, һичшиксез үтәргә тиешле әйбернең күрсәткече.

Ир-ат һәм кияүдә булмаган кызлар өчен әниләре башка кешеләргә караганда күбрәк хакка ия. Имам Әл-Хәким «Әл-Мүстәдрак» дип аталган җыентыгында Гайшә анабыздан мондый хәдис тапшыра: «Хатынга карата иң зур хакка ире ия булса, ир-атка карата иң зур хакка аның әнисе ия».

Хөрмәтле мөселманнар! Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алырга теләгән, Кыямәт көнендә котылуга һәм җәннәтнең югары дәрәҗәсенә ирешүгә өмет иткән һәркем Аллаһыга итагатьле булсын. Гамәл дәфтәрләрегезне изге гамәлләр белән тутыру өчен зур әҗер-саваплар алырга омтылыгыз. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм күрсәткән туры юлдан барырга тырышыгыз, чөнки ул безне игелеккә, шул исәптән, әнигә карата да игелекле булырга өнди.

Күренекле табигыйн Гали бине Хөсәен Зәйн Әл-Габидин әнисенә карата шул дәрәҗәдә итагатьле булган ки, ул ашаган вакытта әнисенә ошаган кисәкне ашаудан да курыккан, шуңа күрә әнисе белән бер тәлинкәдән ашамаган.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе әнисенең өеннән чыкканда, һәрвакыт ишек янында тукталып, түбәндәге доганы кыла торган булган: «Әнием, сиңа иминлек телим! Сиңа Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һәм мәрхәмәте булсын!» Әнисе улына: «Сиңа да, улым, иминлек, Аллаһының рәхмәте һәм мәрхәмәте булсын!» – дип җавап кайтарган. Улы әнисенә: «Мине кечкенә чагымда тәрбияләгәнең өчен Аллаһыдан сиңа рәхимлелек сорыймын», – дип әйткән. Әнисе аңа: «Үсеп җиткәч тә мине куандырганың

өчен Аллаһыдан сиңа рәхимлелек сорыймын», – дип җавап кайтарган. Һәрвакыт әнисе янына килгәндә ул шул ук сүзләрне әйткән.

Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

وَاخْفِضْ لَهُمَا جَنَاحَ الذُّلِّ مِنَ الرَّحْمَةِ وَقُل رَّبِّ ارْحَمْهُمَا كَمَا رَبَّيَانِي صَغِيرًا ﴿٢٤﴾

**«Вә аларга шәфкать итеп, рәхимлелек канатларыңны җәй! Вә әйт: «Ий Раббым, алар мине кечкенә чагымда мәрхәмәт белән үстергәннәре кебек, Син дә аларга дөньяда һәм Ахирәттә шәфкать кыл!»**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:24

Хөрмәтле дин кардәшләр! Ана догасының көче турында бер вакыйганы җиткерәсем килә сезгә. Бервакыт гөнаһлы бер кеше яшәгән. Аның әнисе бик иманлы булган. Ул улын шәригать хөкемнәрен үтәргә чакырган, гөнаһлы эшләрдән тыелып, тәүбә кылырга өндәгән. Ләкин улы әнисенең сүзләренә колак салмаган, элеккечә яшәвен дәвам иткән. Көннәрдән берендә ул бик нык авырый башлый һәм урын өстенә ава. Үлем сәгате якынлашканын сизеп, ул әнисеннән: «Әнием! Мин үлгәннән соң мине каберемә кадәр озата бар. Мине ләхеткә төшергәндә, син дә анда төш. Минем муенныма аягыңны куеп әйт: «Йә, Аллаһы! Мин аның гаепләрен кичердем! Син дә аның гөнаһларын гафу ит!» – дип үтенгән.

Улы үлгәннән соң кайгыга баткан ана улын күмәргә кеше дә тапмаган. Улын үзе юып, кәфенлеккә төргән. Җеназа намазы укыр өчен акча түләп дүрт кеше яллаган. Зиратка аны озатып баручылар да шушы дүрт кеше һәм әнисе булган. Мәетне озату күренешен галим, табигыйн Абән бине Әбү Гайәш күргән. Мәетне озатучыларның бик аз булуы гаҗәпләндергән аны. Ул аларны куып тотып, табутны алып барырга ярдәм итешкән. Зиратка килеп җиткәч, мәетне кабергә төшерәләр. Әнисе

улы кушканча эшли, кабергә төшеп, улының муенына аягын куеп: «Йә, Аллаһы! Мин аның гаепләрен кичердем! Син дә аның гөнаһларын гафу ит!» – дип әйтә. Әнисе күтәрелгәч, каберне җир белән күмәләр. Шушы галимнән кала, барысы да таралыша. Галим үзе генә калгач, кабердән бер тавыш ишетә: «Дөреслектә, әнисе аның гаепләрен кичергәнгә күрә, Аллаһы Тәгалә дә аның гөнаһларын кичерде».

*ТҖ МДН Дәгъват бүлеге*

*30 нчы ноябрь вәгазе,*

*Рабигыль-әүвәл аеның 22 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Зина һәм аның җәмгыяткә зарары

Барча галәмнәрне бар кылып, аларны тәрбия кылып торучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итеп кылучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде!

Пәйгабәребез галәйһиссәлам бер хәдисендә болай дип әйткән: «Әгәр бер халыкта фәхешлек барлыкка килсә һәм ул киң җәмгыятьчелеккә таралса, ул халыкта элек булмаган чума һәм башка төрле авырулар пәйда булачак». Пәйгамбәребез бу сүзләрен безнең заманга төбәп әйткәнмени. Әлбәттә, зина кылу элек тә киң таралыш алган, әмма андый хәлне кайбер халыкларда гына күреп булган. Бүгенге көндә исә зина кылу барлык халыкларда да бар дияргә була. Ә иң кызганычы – аны халык үзенә яшәү рәвешенә кертеп бара, аны гади бер күренеш кебек кабул итә. Фәхешлек бик күп юллар аша пропагандалана: реклама, кино, фотолар һ.б.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам зина таралу белән элек булмаган авырулар да таралачак дигән. Бүгенге көндә табиблар СПИДны шундый авырулар рәтенә кертеп карыйлар һәм аны «ак чума» дип атыйлар. Медицина ничек кенә алга китмәсен, бу авыруны дәвалау юллары әле дә күренми. Һәм кешелек бу гөнаһтан ерагаймаса, мондый төр авырулар тагын пәйда булмас, дип әйтеп булмый.

Безне әйләндереп алган мохит безнең иманыбызга зур сынау булып тора. Пәйгамбәребез юкка гына: «Кем миңа үзенең теле һәм женси әгъзасы өчен вәгъдә бирә (теленең начар, бозык сүзләр сөйләмәячәгенә һәм никахсыз якынлык кылмаска вәгъдә итсә) мин ул кешегә җәннәт вәгъдә бирәм» – дип әйтмәгән. Шулай ук сәхабәләр дә Пәйгамбәребездән: «Нәрсә аркасында кешенең җәһәннәм әһеле булу куркынычы күбрәк?» – дип сорадылар. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Аның теле һәм женси әгъзасы аркасында», – дип җавап кайтарды.

Зина кылу – зур зыян сала торган бозыклык. Ә ул җәмгыятьнең бозыклыгына китерә. Шуңа күрә дә Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримнең кайбер аятьләрендә бу гөнаһны кеше үтерү гөнаһы белән бергә искә ала.

وَالَّذِينَ لَا يَدْعُونَ مَعَ اللَّهِ إِلَٰهًا آخَرَ وَلَا يَقْتُلُونَ النَّفْسَ الَّتِي حَرَّمَ اللَّهُ إِلَّا
بِالْحَقِّ وَلَا يَزْنُونَ ۚ وَمَن يَفْعَلْ ذَٰلِكَ يَلْقَ أَثَامًا ﴿٦٨﴾ يُضَاعَفْ لَهُ الْعَذَابُ
يَوْمَ الْقِيَامَةِ وَيَخْلُدْ فِيهِ مُهَانًا ﴿٦٩﴾ إِلَّا مَن تَابَ وَآمَنَ وَعَمِلَ عَمَلًا صَالِحًا
فَأُولَٰئِكَ يُبَدِّلُ اللَّهُ سَيِّئَاتِهِمْ حَسَنَاتٍ ۗ وَكَانَ اللَّهُ غَفُورًا رَّحِيمًا ﴿٧٠﴾

**«Вә алар Аллаһыдан башкага гыйбадәт кылмаслар һәм Ахирәт өчен Аллаһыдан башкадан ярдәм сорамаслар, Аллаһы үтерүне тыйган кешене нахакка үтермәсләр, вә зина да кылмаслар, әйтелгән шул ярамаган эшләрне берәү эшләсә, гөнаһының җәзасына ирешер. Кыямәт көнендә аңа газап ике өлеш бирерләр, вә хур ителгән хәлдә анда мәңге калыр. Мәгәр берәү тәүбә итеп иман китерсә һәм Коръән юлы белән изге гамәлләр кылса, әнә шундый кешеләрнең начарлыкларын яхшылыкка алмаштырыр, Аллаһы андыйларга Ярлыкаучы вә Рәхмәт кылучы булды».**

«Фуркан / Аеручы», 25:68-70

Шулай итеп, зина кылу ширек, үтерү белән бергә искә алынды һәм аятьнең ахырында Аллаһы Тәгалә андый гөнаһ кылучы кешеләрне тәүбә кылырга ашыктыра. Аллаһы Тәгалә «тәүүәбин», ягъни тәүбә кылучыларны ярата, андый кешеләргә «Ярлыкаучы вә Рәхмәт кылучы булды». Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай диде:

وَلَا تَقْرَبُوا الزِّنَىٰٓ ۖ إِنَّهُۥ كَانَ فَٰحِشَةً وَسَآءَ سَبِيلًا ﴿٣٢﴾

**«Зинага якын да бармагыз, аның сәбәпләреннән дә ерак булыгыз, чөнки ул пычрак эш вә бик яман кабахәт юлдыр».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:32

Ягъни зинаның үзенә һәм аңа илтә ала торган һәрбер гамәлгә: караш, кагылу һ.б.ларга якын бармаска кирәк. Аллаһы Тәгалә бу гамәлне җирәнгеч, кабахәт юл дип әйтте. Шуңа да ул күп кешеләрнең акылларында шул рәвешле кереп калды һәм безнең татар әдипләре дә бу проблеманы бер генә күтәрмиләр («Зур гөнаһлар» әсәрен генә дә искә алсак җитәдер).

Риваятьләрдә болай дип әйтелә: «Иблис үзенең хезмәтчеләрен җир буйлап таратыр алдыннан: «Кем мөэмин-мөселманны туры юлдан адаштырса, аңа мин матур таҗ кидерермен. Ә кем шәһвәткә батыруда хәйләкәррәк була, аны үземә якыннардан кылармын», – дип әйтә икән. Беренче җен кайтып: «Мин ир кешене хатыныннан аердым», – дип әйткән. Иблис (аңа Аллаһының ләгънәте булсын): «Аз эшләгәнсең, ул бит икенче хатынга өйләнә ала», – дип әйткән. Икенчесе кайтып: «Мин бер мөселманны үзенең якын дусты белән аердым», – дип, шатлана-шатлана сөйли ди. Аңа да иблис: «Артык берни дә эшләмәгәнсең, алар кабат дуслаша ала», – дип әйткән. Шуннан соң өченче җен кайтыр һәм: «Мин бер кешене зина кылдырдым», – диган. Иблис аны үзенең якыннарыннан кылган, аңа таҗ кидергән һәм: «Син нинди гүзәл эш кылгансың», – дип әйткән.

Иблис өчен һәр матур эш, кешелек өчен начар, бозык эш булыр. Шәйтан кешегә хәмерне, азартлы уеннарны, фәхешне матур итеп күрсәтә, ә Пәйгамбәребез һәм Аллаһы Тәгалә аларны бозык эш дип әйтә. Мондый эшләр өчен, әлбәттә, Аллаһы Тәгалә хозурында зур газаплар көтелә. Ә газаптан котылучыларны Аллаһы Тәгалә түбәндәге аятьләр белән сыйфатлый:

قَدْ أَفْلَحَ الْمُؤْمِنُونَ ﴿١﴾ الَّذِينَ هُمْ فِي صَلَاتِهِمْ خَاشِعُونَ ﴿٢﴾ وَالَّذِينَ هُمْ عَنِ اللَّغْوِ مُعْرِضُونَ ﴿٣﴾ وَالَّذِينَ هُمْ لِلزَّكَاةِ فَاعِلُونَ ﴿٤﴾ وَالَّذِينَ هُمْ لِفُرُوجِهِمْ حَافِظُونَ ﴿٥﴾ إِلَّا عَلَىٰ أَزْوَاجِهِمْ أَوْ مَا مَلَكَتْ أَيْمَانُهُمْ فَإِنَّهُمْ غَيْرُ مَلُومِينَ ﴿٦﴾ فَمَنِ ابْتَغَىٰ وَرَاءَ ذَٰلِكَ فَأُولَٰئِكَ هُمُ الْعَادُونَ ﴿٧﴾

**«Тәхкыйк, хак мөэминнәр газаптан котылып, мәңгелек сәгадәткә ирештеләр. Алар намазларын хошугълык белән укыйлар, Аллаһыдан куркып, кечерәяләр. Янә алар буш сүзләрдән, файдасыз эшләрдән баш тарталар. Вә малларының зәкятен бирәләр. Вә алар гаурәт әгъзаларын саклarлар, ягъни зинадан сакланырлар. Мәгәр үз хатыннарына вә хуҗа булган җария хатыннарга гына якынаерлар, моның өчен алар шелтә ителмәсләр. Берәү үз хатыныннан вә җариясеннән башканы эстәсә, ягъни зина кылса, ул кешеләр хәләлдән харамга үтүчеләрдер».**

«Әл-Мөэминүн / Мөэминнәр», 23:1-7

Беренчедән, зина кылучы кеше котылучылар рәтеннән чыга, икенчедән, газапка дучар була, өченчедән, андый кешеләргә шелтә белдерелә.

Аллаһы Тәгалә Үзенең Илчесе галәйһиссәламгә мөэминнәргә чит хатыннар янында күз карашларын аска төшерергә, җенси әгъзаларын са-

кларга боерырга куша. Һәм Үзенең һәр кешенең кылган гамәлләрен күреп торуын искәртә:

يَعْلَمُ خَائِنَةَ الْأَعْيُنِ وَمَا تُخْفِي الصُّدُورُ ﴿١٩﴾

**«Ул – Аллаһы кайсы күзләрнең хыянәт белән караганын белер һәм күңелдәге яшерен сакланган нәрсәләрне дә белер».**

«Мөэмин», 40:19

Зур учак та кечкенә ялкыннан башлана. Башта караш, аннары фикер, аннары бер адым һәм гөнаһ. Зинага юл караштан башланганга күрә, карашка карата хөкем әгъзаларны саклауга караганда иртәрәк китерелә. Дүрт төрле әйберсен кулда тота алган кеше үзенең динен дә саклый ала: күз карашларын, фикерләрен,сүзләрен һәм адымнарын.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Бер караштан соң икенче караш булмасын. Беренче караш – хәләл (чөнки ялгыш иде), икенчесе – юк (чөнки кеше үзе теләп карый)», – дип әйткән.

Икенче бер хәдистә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Юл кырыенда утырмагыз», – дип әйтә. Кешеләр: «Ә безнең җыелышлар шунда үтә бит. Безгә алар бик кирәк», – дип җавап кайтаралар. Пәйгамбәребез: «Бу җыелышлар сезгә шулкадәр кирәк булса, юл кагыйдәләрен саклагыз», – дип әйткән. «Кешеләр юл кагыйдәләренең ни икәнен сорагач. Пәйгамбәребез: «Күз карашларны аска төшерү, юлдан үтеп баручыларга комачауламаска, сәлам бирүчеләргә җавап кайтару», – дип әйткән.

Зина кылу – зур гөнаһлар рәтенә керә. Аны кылган кешегә шәригатьтә тиешле җәзасы да билгеләнгән. Зина кылучыга күп итеп тәүбә кылырга, зина кылуга әйләнеп кайтмаска тиеш.

Зина кылуның икенче бер начар ягы – зина кылган вакытта кеше имансыз кала, чөнки аның иманы бу вакытта чыгып тора. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Зиначы иманлы хәлендә зина кылмас; хәмер эчүче иманлы килеш хәмер эчмәс; угры иманлы килеш урламас. Әмма

аларның һәрвакыт тәүбә кылырга мөмкинлекләре бар», – дип әйткән. Пәйгамбәребез икенче бер хәдисендә болай дип әйтә: «Әгәр бер кеше зина кылырга тотынса, аның иманы чыгып, кечкенә генә болыт кебек баш очында торачак. Зина кылуыннан туктагач та, иманы кире кайтачак». Мөхәммәд Әбү Җәгъфәрдән бу хәдис турында сорагач, ул: «Бу гамәлләр Исламнан чыгармый. Исламнан Аллаһы Тәгаләгә ширек кату гына чыгара», – дип әйткән.

Кыямәт көнендә кешеләр үзләренә хисап җиткәнен көтеп торачаклар. Бу көндә кояш кешеләргә бик якын киләчәк, шуңа да кешеләр үзләренең тирләрендә бата башлаячаклар. Әмма Пәйгамбәребез 7 төрле кешегә кояш төшмәячәген әйтә. Аларның берсе – «Матур һәм бай булган кеше белән зина кылырга мөмкинчелек булып та: «Мин галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыдан куркам», – дип, зинадан баш тарткан кеше».

Аллаһы Тәгалә мондый фәхеш эшләрдән ерак торырга, җәмгыятебезгә мондый гамәлләрдән арынырга ярдәмен бирсә иде. Әмин!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районы Хәсәншәех авылы мәчете имам-хатыйбы*

*7 нче декабрь вәгазе,*

*Рабигыль-әүвәл аеның 29 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең сөннәтенә иярүнең әһәмияте

Барлык мактау, хәмде-сәналәр дөньяларны барлыкка китерүче, барчабызны да һәрдаим нигъмәтләндереп торучы, һәр гамәлебезне белүче вә аның өчен гадел рәвештә хөкем итәчәк, Үз рәхмәтенә ирешүчеләрне мәңгелек җәннәткә һәм адашканнарны җәһәннәмгә кертәчәк Бөек зат – Аллаһыга булсын!

Соңгы пәйгамбәр итеп иңдерелгән, дөньяга Раббыбызның сүзләрен вә шәригатен тараткан, җәннәт ишеген беренче булып ачачак вә үзенең өммәтен – безләрне беренчеләрдән булып анда алып керәчәк Мөхәммәд галәйһиссәламгә салаватлар булсын! Шулай ук барчаларыбызга да Аллаһы Тәгаләнең сәламе, рәхмәте вә бәрәкәте булсын!

Безләрне җан вә тән белән бүләкләп, яшәргә мөмкинлек бирүче Зат – Бер булган Аллаһтыр. Ләкин бу бүләкләр юкка гына түгел, бәлки бик зур максат белән – гыйбадәт кылыр өчен. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**«Кеше илә җенне Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә халык кылдым».**

«Зарият / Таратучы», 51:56

Галимнәр гыйбадәт төшенчәсенә Раббыбыз риза булган һәм яраткан барлык гамәлләрне кертәләр. Икенче төрле әйткәндә, тормышыбызда

үтәлә торган барлык хәләл эшләр изге ният белән башкарылса, саваплы булып исәпләнә.

Галимнәр фикеренчә, гыйбадәт дөрес булсын өчен ике шарт үтәлергә тиеш: ихласлык белән үтәү һәм Пәйгамбәребез сөннәтенә туры китерү. Әгәр дә икесенең берсе төшеп калса, гамәл кабул ителмәс, ә кайбер очракларда гөнаһлы булырга да мөмкин. Шуңа күрә, һәр мөселманга бу ике нигезне бик яхшы итеп белергә фарыз! Әмма моның өчен Коръәнне генә белү җитми. Мөхәммәд галәйһиссәламнең тормыш юлын өйрәнү вә аның буенча яшәү дә кирәк. Аллаһы Тәгаләнең түбәндәге аятьләре моңа ачык дәлил:

قُلْ إِن كُنتُمْ تُحِبُّونَ اللَّهَ فَاتَّبِعُونِي يُحْبِبْكُمُ اللَّهُ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ ۗ وَاللَّهُ غَفُورٌ رَّحِيمٌ ﴿٣١﴾

**«Ий, Мөхәммәд әйт: «Әгәр Аллаһыны сөйсәгез, миңа иярегез, миңа иярсәгез, Аллаһы сезне сөяр һәм гөнаһларыгызны ярлыкар. Тәүбә итеп, Аллаһы юлына керсәгез, Ул, әлбәттә, Ярлыкаучы һәм Рәхимле».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:31

Шулай ук:

لَّقَدْ كَانَ لَكُمْ فِي رَسُولِ اللَّهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ لِّمَن كَانَ يَرْجُو اللَّهَ وَالْيَوْمَ الْآخِرَ وَذَكَرَ اللَّهَ كَثِيرًا ﴿٢١﴾

**«Тәхкыйк, Аллаһыдан савапны һәм Ахирәттә җәннәтне өмет иткән хәлдә Аллаһыны күп зекер итүче мөэминнәр өчен Аллаһы Расүлендә сезгә иярергә тиешле булган күркәм холык вә яхшы сыйфатлар бардыр».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:21

Мөфәссирләрнең берсе Ибне Кәсир әлеге аятькә түбәндәге аңлатманы бирә: «Бу аять пәйгамбәребез артыннан иярергә тиеш икәнлегебезгә көчле нигездер. Аңа нәрсәдә иярергә соң? Сүзләренә, гамәлләренә, кыяфәтенәдер. Болар барысы бергә алынганда Сөннәт диеп атала».

«Рух әл-бәян» тәфсирендә дә бу хакта: «Аллаһы Тәгаләнең Илчесе артыннан ияpү һәр иманлы кешенең бурычыдыр», – дип әйтелә.

Икенче төрле әйткәндә, Мөхәммәд галәйһиссәламгә ияpү кешене бу дөньяда да вә Ахирәттә дә бәхетле итә. Аның яшәү рәвешенә мөселманнар гына түгел, хәтта чит дин әһелләре дә, галимнәр вә фәлсәфәчеләр дә, шагыйрьләр вә язучылар да соклана. Ул иң дөрес, камил һәм матур тормышны үз үрнәгендә яшәп күрсәтте.

Мәсәлән, күренекле тарихчыларның берсе Джейк Харб болай ди: «Мин дөньяда булган һәр күренекле кешенең мәгълүматларын тупладым вә махсус программа рәвешендәге мизанга куйдым. Үзем христиан буларак, Гайсә галәйһиссәламнең беренчеләрдән булуын теләгән идем. Әмма Мөхәммәд, аңа Аллаһының салаваты вә сәламе булсын, ким дигәндә аңардан 6 мәсьәләдә алда булып калды. Һичшиксез, Мөхәммәд галәйһиссәлам сокландыргыч шәхестер».

Кардәшләрем! Пәйгамбәребез һәм әхлагы, һәм гыйлеме, һәм кешелеклелеге белән күркәм үрнәк булып торган зат. Юкка гына ул ахыргы пәйгамбәр итеп, бар дөньяларның пәйгамбәре итеп индерелмәгән. Шуңа күрә аның дәверендә яшәп калу безнең өчен зур дәрәҗә.

Кызганыч, мөселманнар арасында пәйгамбәребез сөннәтен үтәү бик сүлпән мәсьәлә булып кала. Тормышларында килеп чыккан кыенлыкларның сәбәбен дә шуннан эзләргә кирәк, чөнки Сөннәт буенча яшәгәндә, кешенең тормышы камил, ә үзе гүзәл булыр иде. Мөхәммәд галәйһиссәлам гыйбадәт кылу ысулларын гына өйрәтмәде, ул кешеләрне дөрес итеп гомер итәргә, бер-беребез белән нинди мөгамәләдә булырга кирәклеген дә өйрәтте. Шуңа күрә галимнәр: «Ни өчен пәйгамбәр итеп

фәрештә иңдерелмәде икән?» – дигән сорауга түбәндәге җавапны кайтаралар: «Фәрештәләр кеше шикелле яшәп күрсәтә алмаслар иде. Шуңа сәбәпле бик күп каршылыклар туарга мөмкин иде. Пәйгамбәр – үзе дә асылда кеше буларак, үз үрнәгендә һәркемгә туры килерлек итеп яшәп күрсәтә белде». Бу Раббыбыздан иңдерелгән бик зур хикмәт! Тик күп мөселман бу нигъмәтнең кадерен генә белми!

Мөхәммәд галәйһиссәлам яшәешнең югалган тәртибен дөнья күләмендә яңадан торгызды. Инде юкка чыгып бетәргә әзер булган кешелек җөмләсе янәдән яңарып, көчәеп китте. Бозыклык кимеде, миһербанлык артты.

Пәйгамбәребезнең әмерләре дә искиткеч тәртипкә салынган иде. Мәсәлән, һәркемгә иң беренче бурыч – Аллаһыга буйсыну, аннан соң әти-әнине зурлау, моннан кала туганнарны берләштерү, шуннан соң мохтаҗларны вә фәкыйрьләрне кайгырту. Ул һәрвакыт: «Сезнең арагыздан Аллаһыга иң сөеклегез – кешеләргә иң күп файда китерүчегездер», – дип әйтеп килде.

Димәк, җәмгыятебезне җимерелүдән коткару өчен, гаиләләребездә өлфәт мәхәббәт урнаштыру өчен, мәңгелеккә киткәч, бәхеткә ирешер өчен без Мөхәммәд галәйһиссәламнең сөннәтен ныклап өйрәнергә вә тормышыбызда аны нык итеп кулланырга тиешбез. Югыйсә, ике дөньябызны да югалтуыбыз ихтималы бик көчле.

Азакта, имам Газалинең сүзләрен китерәсем килә: «Сөннәткә үтәмәскә дә мөмкин булган гамәл дип карамагыз! Сөннәткә шәфәгатькә ирештерә торган гамәл итеп карагыз!» Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең сөннәтен үтәгән кеше өчен ул Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә каршында шәфәгать кылачак. Кем белә, бәлки шул сәбәпле җәннәтле булырбыз?.. Бу мәсьәләне йөрәге белән аңлаган кеше тормышын тулаем Сөннәткә корыр иде.

Югарыдагыларны йомгаклап әйткәндә, гомерен дә, малын да, мөлкәтен дә дин таралсын өчен фида кылган пәйгамбәребезгә без ничек иярмик инде?! Ничек аның сөннәтен өйрәнеп, аны тормышка ашырмыйк инде?!

*ТҖ МДН Дәгъват бүлеге*

*14 нче декабрь вәгазе,*

*Рабигыль-ахыр аеның 7 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Яхшылыкка өндәү һәм тыйганнан тыю

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ اللَّهَ لَا يُغَيِّرُ مَا بِقَوْمٍ حَتَّىٰ يُغَيِّرُوا مَا بِأَنفُسِهِمْ ﴿١١﴾

**«Тәхкыйк, үзләре үзгәрмәгәнче (үзгәрергә тырышмаганчы), Аллаһы бер генә кавемнең дә халәтен үзгәртмәс».**

«Рәгыйд / Күк Күкрәү», 13: 11

Ислам динендә савап-гөнаһ, изгелек-начарлык, җәннәт-җәһәннәм кебек капма-каршы булган сүзләрне еш очратырга була. Һәм, гадәттә, әгәр дә берсе турында яхшы яктан сөйләнелсә, икенчесе турында кисәтү рәвешендә сөйләнелә. Әгәр кеше изгелек кылса, савап була, әгәр яман гамәл кылса – гөнаһ. Шуңа күрә, саваплы җәннәткә илтә торган изге гамәлләрне кылырга, ә җәһәннәмгә илтә торган яман эшләрдән тыела белергә кирәк. Асылда, Аллаһы Тәгалә йөкләгән һәр гыйбадәт кешене бозыклыктан, пычраклыктан ерагайта һәм Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә, мәгъфирәтенә якынайта. Аны намаз укый, ураза тота башлаган кеше үзе дә сизә. Андый кешенең күңеле йомшара, чистара башлый. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَالْمُؤْمِنُونَ وَالْمُؤْمِنَاتُ بَعْضُهُمْ أَوْلِيَاءُ بَعْضٍ ۚ يَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَيَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ وَيُقِيمُونَ الصَّلَاةَ وَيُؤْتُونَ الزَّكَاةَ وَيُطِيعُونَ اللَّهَ وَرَسُولَهُ ۚ أُولَٰئِكَ سَيَرْحَمُهُمُ اللَّهُ ۗ إِنَّ اللَّهَ عَزِيزٌ حَكِيمٌ ﴿٧١﴾

**«Мөэмин ирләр вә мөэминә хатыннар бер-берсенә дуслар вә ярдәмчеләр: алар кешеләрне иманга, дингә вә яхшылыкка өндәрләр һәм начарлыклардан тыярлар, намазларын вакытында үтәп, зәкятләрен бирерләр вә һәр эштә Аллаһыга һәм Аның Расүленә итагать итәрләр, андый кешеләргә Аллаһы тиз арада рәхмәт кылыр, тәхкыйк Аллаһы – Газиз вә Хәким».**

«Тәүбә», 9:71

Аятьтән хәерле, яхшы эшкә чакыру һәм начарлыклардан тыю мөэмин-мөселманнарның төп сыйфатларыннан икәнен белә алабыз. Икенче төп сыйфат – алар намазларын вакытында үтәп, зәкятләрен вакытында бирәләр. Бер яктан, мөселман кеше яхшылыкка чакырырга тиеш. Бу аңлашыла да: әгәр дә начарлыкка чакырса, ул кешенең мөселманлыгында шик туар иде. Нинди ата-ана баласына начарлыкны теләп, аны начарлыкка чакыра? Бу да шуңа охшаш хәл бит. Аятьне икенче төрле: «Бер-берсен яхшылыкка чакырган һәм начарлыктан тыйган кешеләр мөэмин-мөселман була», – дип әйтеп булыр иде. Шуңа күрә берәр мөселман үзенең кардәшенең хатасын күреп, аны төзәтергә җыена икән, (мәсәлән, Коръән укыганда берәр кеше ялгышлык җибәреп, аны ихластан килеп төзәтү) яки аңа күркәм, изге гамәлләр турында сөйләп, аларны кылырга өнди икән (садакалар бирү, әти-әниләргә карата яхшы мөгамәләдә булу, өлкәннәрне хөрмәт итү һ.б.) – бу алар арасында дошманлык хисләре тудырырга тиеш түгел. Киресенчә, андый кешеләрнең сүзләренә колак салырга, үзеңдә булган хатаны төзәтү өстендә эшләргә, изге гамәлләр санын арттырырга тырышырга кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Мөэмин – мөэминнең көзгесе», – дип әйткән. Димәк, кем дә булса килеп бездә булган берәр хатаны әйтсә, без аны кабул итәргә, аны бетерү өстендә эшләргә тиеш. Шулай ук үзебез дә берәр кардәшебездә нинди дә булса кимчелек күрсәк, аны аңа күркәм итеп җиткерергә тиешбез. Аятьтән күренгәнчә, бу

гамәл – яхшылыкка чакыру һәм начарлыктан тыю – ирләр арасында да, хатын кызлар арасында да булырга тиеш.

Кабаттан «Күк күкрәү» сүрәсендәге аятькә әйләнеп кайтыйк. Аллаһы Тәгалә кешеләрнең халәтен алар үзләре үзгәрергә теләгәч кенә үзгәртәчәк. Бүгенге көндә без кешегә 5 минут кына карап торып та, аның 100 төрле хатасын күреп ала алабыз. Һәм безгә шул җитә дә: аның янына киләбез дә: «Кардәш, син дөрес эшләмәдең бит, сиңа болай эшләргә кирәк», – дигән сүзләр белән аны өйрәтә башлыйбыз. Ягъни, без үзебезнең яшәгән җирлегебезне начарлыктан, хаталанудан сакларга тырышкан булабыз. Әмма, булабыз гына шул, чөнки үзеңнекен күргәнче, кеше гаебен күрү җиңелрәк. Үзеңнең хатаңны төзәткәнче, кешенекен төзәттерү җиңелрәк. Ә үзең төзәлми торып, ничек итеп калганнарны төзәтеп булсын. Бәлки, гомумән, хата да синдә генәдер. Үзеңне дөрес дип санап йөрсәң, әлбәттә, калганнарда бары тик хата гына күрәсең. Халыкта мондый гыйбарә йөри: «Кешегә бармак төртеп күрсәткәндә, калган 3 бармакның үзеңә төбәлгәненә игътибар ит». Чыннан да, кешегә төртеп күрсәткәндә, аңа нибары 1 генә бармак юнәлә, ә 3 бармак – үзеңә таба. Һәм үзеңдәге хаталарны күреп, аларны төзәтә башлагач, калганнарның хаталары юклыгы ачыклана башлый. Шуңа күрә, монда бик нык итеп үз өстеңдә эшләү сорала. Һәм күз алдыгызга китерегез, әгәр дә шушы җомгада утырган һәр кеше үз өстендә эш алып бара башласа, калганнарны тәнкыйтьләү дә кирәк булмас иде, чөнки һәр кеше үз-үзен тәрбияли булып чыга. Һәм шул вакытта җәмгыять тә яхшыга үзгәрәчәк, чөнки Аллаһы Тәгалә җәмгыятьне, шул җәмгыять үзе үзгәрә башлагач кына үзгәртә!

Үзеңнән башларга кирәк дип әйттек. Ничек була соң ул?

Бервакыт бер мөселман үзенең яшь кенә улын имам кешегә алып килә дә: «Хәзрәт, минем балам бик тә баллыны ашарга ярата, өшкереп алыгыз әле, туктамасмы икән?» – дип әйтә. Имам аларга 3 атнадан килергә куша. 3 атнадан имам бу баланы кабул итә һәм 1 минуттан чыгарып та

җибәрә. Әти кеше аптырап, баласыннан: «Улым, бик кыска булды бит бу. Нинди сүрәләр белән генә өшкерде ул сине?» – дип кызыксына. Малай исә: «Бернинди сүрә дә укымады, бары тик: «Бүтән баллы ашама», – дип кенә әйтте һәм чыгарып җибәрде», – дип әйтә. Ачуы чыккан әти имам янына ашыга һәм: «Сез безгә 3 атна буе көтәргә куштыгыз. Ә хәзер балама бер сүрә дә укымыйча, бары тик баллы ашамаска гына кушасыз. Моны ничек аңларга соң?» – дип зарлана. Имам: «Сез минем яныма өшкертергә дип килгәндә, мин үзем дә бик каты баллы ярата идем. Әмма үзем эшли торган эшне башкалардан эшләмәүне таләп итә алмыйм. 3 атна үткәч, мин баллы ашауны ташлый алдым һәм чын күңелдән балагызга баллы ашамаска куштым», – дип җавап кайтарган. Әти кеше үз хатасын аңлап ала – бала әти-әнисенең гамәлләрен күреп, шуларны кабатлап үсә икән. Шулай булгач, әгәр үзең берәр начар гамәл кылсаң, калганнарга аны үтәмәскә кушу – ахмаклык. Шулай ук үзең бер изге гамәл дә кылмыйча, калганнарны аңа чакыру – шулай ук ахмаклыктыр.

Үз гаиләңдә син балаңа тел белән дә, кул белән дә әйтә аласың. Мәсәлән, улың тәмәке тартса, кул белән әйтеп, кул белән тәмәкеләрен алып куя аласың. Әмма мөселманның кулы һәм теле белән шелтәләргә көче җитмәсә (синең гаиләң әһелләре булмаса, ул кешеләргә тел белән дә, кул белән дә кагылырга ярамый), йөрәге белән шелтәләү аның өстеннән бурычны төшерә.

Әмма урамда барганда бер малайны кыйнаганнарын күрдегез, ди. Әлбәттә, бу очракта тиз генә янәшәңдә булганнарны да дәшеп, ул малайга ярдәмгә килергә кирәк. «Бу минем эшем түгел», – дип, тыныч күңел белән үтеп китү ярамый.

Шулай итеп, яхшылыкка чакырганда синең гамәлеңнең файда китерәчәген белергә һәм киресенчә зуррак зыян салырга сәләтле түгелме икәнен уйларга кирәк. Шул ук урам мисалында гына карасак та: әгәр дә кемдер бер кешене кыерсытса, туктата алсаң, туктату тиешле. Әмма ул

кешенең сине дә җиңәчәген белсәң, бу очракта, читкә китеп, бүтәннәрне ярдәмгә чакырсаң, файдалырак булачак.

## Начарлыктан тыюның әһәмияте

Изгелек эшләргә җиңелрәкме, әллә берәр гөнаһтан тыелып калумы? Әгәр кеше садака бирергә уйласа, аңа мәчет ящигына садака салу бернинди дә авырлык тудырмаячак. Әмма кеше тәмәкесен ташларга җыенса, аңа бу гамәл тиз генә бирелмәячәк. Аның өчен күп тырышлыклар кую кирәк булачак. Шуңа күрә кеше үзен тәрбияләгәндә изге гамәлләрне кылу белән беррәттән, начар гадәтләрен дә калдыру өстендә эшләргә тиешле.

Кадерле җәмәгать! Яхшылыкка өндәү һәм начарлыктан тыю берничә шартка да бәйле. Беренчедән, гыйльми нигез булу. Икенчедән, чакырган вакытта да, тыйган вакытта да йомшак булу. Өченчедән, сабыр булу. Бу өч компонент бик кирәк. Әгәр кеше үзе нәрсәгә чакырганын белмәсә (гөнаһлы әйбергә чакырадыр бәлки), аның үзенә дә гөнаһ булуы бар. Шулай ук ул йомшак булмаса, кешеләр аны гомумән тыңламаслар иде. Аллаһы Тәгалә дә Коръәни Кәримдә Пәйгамбәребезгә йомшак булырга өнди. Шулай ук, иң авыр әйберләрнең берсе – сабыр булу. Әмма кемгә дә булса берәр нәрсәне тыйганнан соң, ул кеше аны шунда ук ташлар дип өмет итәргә ярамый. Һәм яхшылыкка өндәгәннән соң да, ул кеше аны шунда ук эшли башлар дип тә уйларга ярамый. Ничәдер көн, бәлки айлар, бәлки еллар үтүе дә бар, шуңа күрә, әлбәттә, сабырлыкның запасы күп булырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә барыбызга да Аның динендә нык торырга, дусларыбызга, туганнарыбызга, ата-аналарыбызга диннең матурлыгын, күркәмлеген җиткерергә, аларны бозык гамәлләрдән кисәтергә, саклап калырга көч, ярдәм вә җиңеллек бирсә иде. Әмин!

*«Хозур» редакциясе*

*21 нче декабрь вәгазе,*

*Рабигыль-ахыр аеның 14 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Дини гыйлем алуның әһәмияте

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак илчесе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәлам хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган, мөхтәрәм дин кардәшләрем, Әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәәтүһ!

Бүгенге вәгазебез, ин шә Аллаһ, гыйлем һәм аның фазыйләтләре турында булыр. Ислам динендә гыйлем бик зур урын алып тора. Әбү Дәрда исемле сәхабә (Аллаһы аннан разый булсын): «Гыйлем иясе яки гыйлем алучы яки гыйлемне тыңлаучы бул. Ләкин дүртенчесе булма – һәлак булырсың», – дип әйткән. Моннан аңлашылганча, һәркайсыбызга гыйлемле, белемле булып, шул гыйлемне башкаларга да өйрәтү тиешле. Мөселман кешегә бишектән алып ләхеткә кадәр гыйлем алу фарыз. Белем алмый икән, димәк, Аллаһы Тәгалә каршысындагы бурычын үтәми. Мөселман дөньяви гыйлемме, дини гыйлемме – икесен дә тигез күреп, икесен дә өйрәнергә тиеш. Гомере буе. Дөньяви гыйлем белән дини гыйлем бер-берсенә бәйләнгән, бер-берсен тулыландырып торалар. Аларны аерып карау һич дөрес түгел. Дин әһелләре дә, дөньяви гыйлем бирүчеләр дә моны аңларга тиеш, чөнки дөньяви фәннәрдә дә Аллаһы Тәгалә куй-

ган кануннарны өйрәнәләр. Физика, химия, биология, математика яки бүтән фәннәр – алар барысы да Аллаһының Җир йөзенә урнаштырган кагыйдәләрен өйрәнәләр. Кеше нихәтле галимрәк булса, гыйлемне нихәтле күбрәк өйрәнсә, тирәнрәк белсә, ул Аллаһы Тәгаләгә шуның хәтле якынрак була, чөнки ул Аллаһы Тәгаләнең бу дөньяны нинди камил сурәттә яраткан икәнен аңлый: бөтен нәрсә кануннарга буйсынган, тәртипсез хәрәкәтләнә торган бер генә нәрсә дә юк. Бөтенесенең эчендә бертөрле нигез ята. Бөтенесенең төзелеше охшаш, бер-берсенә бәйләнгән һәм бер-берсеннән башка була алмый.

Мөхтәрәм җәмәгать! Гыйлем сүзе Коръәндә 70 тән артык урында кабатланып килә. Аллаһы Тәгалә изге Коръәндә болай дип әйтә:

قُلْ هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ ﴿٩﴾

**«Әйт син аларга: «Белгән белән белмәгән бер булырмы?»**

«Зүмәра / Халык Төркеме», 39:9

Шулай ук:

يَرْفَعِ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا مِنكُمْ وَالَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ دَرَجَاتٍ ۚ وَاللَّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ خَبِيرٌ ﴿١١﴾

**«Аллаһы Тәгалә сезнең арадан иманлыларның һәм гыйлем ияләренең дәрәҗәсен арттырыр. Аллаһы бөтен кылган гамәлләрегезне белеп тора».**

«Мүҗадәлә / Бәхәсләшү», 58:11

Хөрмәтле мөселманнар, игътибар итегез! Аллаһы Раббыбыз Коръәннең иң беренче аяте белән безне белем алырга чакыра. Ул:

اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ ﴿١﴾

**«Сине барлыкка китергән Раббың исеме белән укы!»** – дип боера.

«Галәк», 96:1

Мөфәссирләр аңлатуынча, бу аятьтәге «укы!» дигән сүз җирдәге һәм күктәге гаҗәеп матурлыкка, төрле мәхлүкъларга карап, фикерләүне, уйлануны, белем алуны аңлата.

Кешенең өйрәтеп калдырган гыйлем өчен савабы үзе үлгәч тә гамәл дәфтәренә язылып барачак. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Кеше вафат булганнан соң, ул барлык гамәләреннән өзелә, ләкин аның өч төрле гамәле файда китерәчәк: 1) сәдәкатул-җәрия, ягъни кеше үлгәннән соң да файда китерә торган сәдәка; 2) башкаларга биреп калдырылган белем; 3) дога кылучы бала», – дип әйткән (Мөслим).

Башка бер хәдистә Аллаһының Расүле галәйһиссәлам: «Кем гыйлем алу юлына басса, Аллаһы аңа җәннәткә алып бара торган юлны җиңеләйтә. Фәрештәләр гыйлем алучы кешегә кылган гамәленә ризалык белдереп, канатларын җәяләр. Гыйлем иясенә күктәге һәм җирдәге җан ияләре һәм хәтта балыклар да аның гөнаһларын гафу итүне сорыйлар. Галимнең (белемсез) гыйбадәт кылучы кешедән өстенлеге – айның бөтен йолдызлардан өстенлеге кебек. Галимнәр – пәйгамбәрләрнең варислары. Пәйгамбәрләр мирас итеп динар да, дирһәм дә калдырмадылар, алар бары тик гыйлемне генә калдырдылар. Кем дә кем аны алса, үзенә җитәрлек дәрәҗәдә алган булыр», – дип әйткән (Тирмизи).

Икенче хәдис-шәрифтә болай дип әйтелгән: «Галимнең (белемсез) гыйбадәт кылучы кешедән өстенлеге минем сәхабәләремнең иң түбәненнән өстен булганы кебектер» (Тирмизи). Бу хәдис гыйлем алуның нәфел намазларга караганда да өстенрәк һәм саваплырак икәнлеген күрсәтә.

Тәфсир галиме Габдуллаһ бине Габбас радыяллаһу ганһе гыйлемнең фазыйләте турында: «Минем өчен гыйлемне кабатлау төнне намаз укып чыгуга караганда яхшырак», – дип әйткән.

Гали бине Әбү Талиб (кәррамәлләһу вәҗһәһу): «Гыйлем акчадан хәерлерәк, чөнки ул сине саклый, ә син акчаны саклыйсың. Гыйлем ул хөкемдар, ә акча хөкемгә дучар булучы, акчаны сарыф итү аны азайта, ә гыйлем – тарату белән арта», – дип әйткән.

Әбү Зәрр һәм Әбү Һөрайра исемле сәхабәләр (Аллаһы алардан разый булсын): «Гыйлемнән бер нәрсә өйрәнү безнең өчен 1000 рәкагәть нәфел намазына караганда яхшырак. Ә берәр гыйлемне кешегә өйрәтү, аны гамәлдә куллануына һәм кулланмавына карамастан, безнең өчен 100 рәкагәтьтән дә хәерлерәк», – дип белдергәннәр.

Хәсән Әл-Басри (Аллаһы аны үз рәхмәтеннән аермасын) галимнәр турында: «Гыйлем ияләренең язуда кулланыла торган кара буяулары шәһитләрнең каннары белән бергә үлчәнелә һәм гыйлем ияләренең кара буяулары үлчәүдә авыррак булачак», – дип әйткән.

Бервакыт мәшһүр галим Ибне Мөбәрактән: «Әгәр дә сиңа Аллаһы Тәгалә кичкә үләсең, дип әйтсә, нишләр идең?» – дип сорадылар. Ул: «Гыйлем алыр идем», – дип җавап кайтарган.

Имам Нәвәви (Аллаһы аны Үз рәхмәтеннән аермасын) гыйлем алуның нәфел намазын укуга караганда өстенрәк булуын: «Бөтен галимнәр дә гыйлем алу – нәфел уразасын тоту, нәфел намазын уку, тәсбих әйтү кебек тән гыйбадәтләренә караганда яхшырак, дип әйттеләр. Моның дәлиле: гыйлемнең файдасы кешенең үзенә генә булмыйча башка кешеләргә дә булганы өчен. Ә нәфел гыйбадәтләр кешенең үзенә генә файда китерә. Шулай ук бөтен гыйбадәтләр дә гыйлемгә мохтаҗ, ә киресе түгел. Галимнәр – пәйгамбәрләрнең варислары, ә гыйбадәт кылучылар турында андый сүзләр әйтелмәгән. Гыйлем – ул Аллаһының сыйфаты», – дигән сүзләр белән аңлаткан.

Галимнәрнең гыйлемгә карата әйтеп калдырган шушы сүзләре гыйлемнең мөселман тормышында бик зур урын алып торганын күрсәтәләр.

## Гыйлем алуның Ислам динендәге хөкеме нинди?

Гыйлем алу хөкеме буенча кайбер вакытта фарыз гайн, ә кайбер вакытта фарыз кифәя булырга мөмкин. Гыйлемнең фарыз гайны ул – фарыз гамәлне дөрес үтәү өчен кирәк булган гыйлем. Бу төргә көндәлек дини гамәлләрне, гыйбадәтләрне кылырга ярдәм итә торган гыйлем керә: шәһадәт кәлимәсе, аның мәгънәсен аңлау, тәһарәт, намаз, ураза, зәкят, хаҗ, сәүдә, никах, талак кебек гыйлемнәрне аның белән шөгыльләнүче һәр кеше өйрәнергә тиеш.

Фарыз кифәя булган гыйлем – ул фарыз гайн гыйлеменнән тыш булган шәригать белемнәре яки дөньяви эшләрне алып барыр өчен ярдәм итә торган гыйлемнәр.

Кеше Аллаһыга дога кылганда һәрвакыт гыйлемен арттыруны сорарга тиеш. Аллаһы Тәгалә моны үзе куша:

وَقُل رَّبِّ زِدْنِي عِلْمًا ﴿١١٤﴾

**«Син әйт: «Әй Раббым! Миңа гыйлемне арттыр».**

«Та Һа», 20:114

## Гыйлем иясенең һәм гыйлем алучының әдәпләре:

Бу турыда кыскача имам Нәвәвинең «Тибйән» («Ачыклау») исемле китабында аңлатыла:

1. Гыйлем алуда һәм гыйлем бирүдә максат (ният) ачыкланырга тиеш.

Мөгаллим һәм укучы дини гыйлем алуда максат итеп Аллаһының ризалыгына ирешүне, дөрес иман нигезләрен өйрәнүне куярга тиешләр.

Әгәр дә кеше дини гыйлем алганда дөньяви байлыкка ирешүне яки дан казануны максат итеп куйса, бу ихласлы ният булмый. Гыйлемнең ахыргы нәтиҗәсе Аллаһыдан курку булырга тиешле.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Кыямәт көнендә җәһәннәм уты гыйлем алып, аны кешеләргә өйрәткән һәм Коръән укыган кеше белән яндырылып җибәреләчәк. Аны Аллаһы каршына алып киләләр. Аллаһы аңа үзенең нигъмәтләрен искә төшерә башлый, бу кеше ул нигъмәтләрне таный. Аллаһы аңа: «Син нинди гамәл кылдың?» – дип сорар. Бу кеше: «Гыйлем алдым һәм аны башкаларга өйрәттем һәм Синең ризалыгың өчен Коръән укыдым», – дип әйтер. Аллаһы аңа: «Син ялганлыйсың. Син гыйлемне галим, дип әйтсеннәр өчен, ә Коръәнне матур укый, дип әйтсеннәр өчен генә укыдың», – дип әйтер. Соңыннан аны башы җиргә тигән килеш җәһәннәмгә сөйрәп барырлар һәм шунда атырлар», – дип әйтеп калдырган (Мөслим).

2. Укытучы дини гыйлем бирүдә акча, дәрәҗә, бүләк кебек дөньяви максатларны куярга тиеш түгел. Хәдис-шәрифтә: «Кем дә кем Аллаһы ризалыгына омтылып алынырга тиешле гыйлемне дөньядагы бер максатка ирешү өчен өйрәнсә, Кыямәт көнендә ул җәннәтнең исен дә тоймыячак», – дип әйтелгән (Әбү Давыд).

Имам Шәфигый (Аллаһы аны рәхмәтеннән ташламасын): «Мин халыкның язган китапларымны укып, хәтта бер хәрефен дә минеке дип әйтмәүләрен теләр идем», – дип әйткән.

3. Укытучы балаларның санын арттыруны беренче максат итеп куймаска тиеш.

4. Белем бирүче кеше һәрвакыт күркәм холыклы, ачык йөзле, сабыр, йомшак күңелле, күп көлмәүче кеше булырга тиеш.

5. Белем бирүче кеше гыйлем алучыга киңәш бирергә, авыр чакта ярдәм итәргә һәм аңа карата йомшак мөгамәләдә булырга тиеш. Әд-Дәрими исемле галим: «Гыйлем алучыга һәм гыйлем бирүчегә карата йомшак мөгамәләдә булыгыз», – дигән.

6. Гыйлем бирүче кеше беркайчан да белмим дип әйтергә оялмасын.

Бервакыт Гыйракның фикһ белгече Шәгъбигә ниндидер сорау бирәләр. Ул белмим дип җавап биргәч, аңа кешеләр: «Әллә син Гыйракның фикһ белгече була торып, белмим дип әйтергә оялмыйсыңмы?» – дип әйттеләр. Ул: «Хәтта фәрештәләр дә Аллаһы Тәгалә алардан сорагач: «Син бөтен кимчелекләрдән пакь! Безнең гыйлемебез юк», – дип әйтергә оялмадылар», – дип әйткән.

7. Гыйлем алучы кеше һәрвакыт укытучыны хөрмәт итәргә тиеш.

Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Олыларны хәрмәт итмәгән, кечеләргә миһербанлы булмаган һәм галимнәребезгә ихтирамлы булмаган кеше минем өммәтемнән булмас», – дип әйткән (Әхмәд бине Хәнбәл: Мөснәд; имам Табарани).

Гали бине Әбү Талиб (кәррамәллаһу вәҗһәһу) болай дип әйткән: «Укытучының хакларыннан аңа күп сорау бирмәү, аны җавап бирә алмаслык авыр хәлдә калдырмау; арганын сизсәң, үҗәтлек күрсәтмәү; торырга теләсә киеменнән тартмау; серен таратмау; аның янында бер кемне дә яманламау; ялгышуын теләмәү; әгәр дә ялгышса, гафу итү; аны Аллаһының әмерен саклаганчыга хәтле хөрмәт итү; аның алдына утыру; әгәр дә берәр ярдәмгә мохтаҗ булса, иң беренче булып ярдәм итү һәм аны: «Башка кеше синеңчә әйтмәде», – дип авыр хәлдә калдырмау». Суфьян Әс-Сәүри (Аллаһы аны Үз рәхмәтеннән аермасын): «Гыйлем алган вакытта иң беренче эш – ул дәшмәү. Икенчесе, гыйлем бирүчене игътибар белән тыңлау; өченчесе, гыйлемне истә калдыру; дүртенчесе, алган гыйлем нигезендә гамәл кылу һәм бишенчесе, ул гыйлемне башка кешеләргә өйрәтү. Әгәр берәү шушы биш шартны үтәсә, камил гыйлем иясенә әверелер», – дигән.

Дүрт мәзһәб галимнәренең гыйлем алу рәвешләре белән танышыйк:

1. Имам Әбү Хәнифә (Аллаһы аны Үз рәхмәтеннән аермасын).

Бу галим Аллаһыдан куркучы, күп гыйбәдәт кылучы, гыйлеме белән Аллаһының ризалыгына омтылучы кеше була. Ул күп вакытта төне буе намаз укып чыга торган була.

Әбү Хәнифә укытучысы Хәммәд бине Сөләйманга карата бик ихтирамлы булган. Шуңа күрә ул өендә утырган вакытта аягын укытучысы өенә таба сузмый торган булган. Ул һәр намаз саен әти-әнисе белән беррәттән, укытучысы өчен дә Аллаһыдан гөнаһларын гафу итүне сорый торган була.

2. Имам Мәлик (Аллаһы аны Үз рәхмәтеннән аермасын).

Ул кечкенә чагында Ибне Зәһра исемле галимнең ишек төбендә эссе вакытта да, бик салкын вакытта да юлда гыйлем алу өчен көтеп тора торган була. Бу галим сукырайгач, ул аны 7 ел буе өеннән мәчеткә алып бара.

Имам Мәлик хәдис сөйләргә утырса, һәрвакыт тәһарәт ала, сакалын тәртипли, ислемай сибә торган була. Ул җитди кыяфәт алганнан соң гына хәдис сөйли башлый. Аның шулай эшләвен бер кеше күреп: «Ни өчен син шулай эшлисең?» – дип сорый. Имам Мәлик радыяллаһу ганһе: «Мин шушы рәвешле Аллаһының Илчесенең сүзләрен зурларга телим», – дип җавап биргән.

Шулай ук, Имам Мәлик: «Гыйлем – ул нур, Аллаһы аны Үзе теләгән кешегә бирә, шуңа күрә гыйлем ул күп хәдисләр белү түгел», – дип әйтә торган булган.

Ул күп сорауларга «Белмим», – дип җавап кайтарган. Җитәкчеләрдән килгән бүләкләрне ул садака итеп бирә торган була.

3. Имам Шәфигый (Аллаһы аны Үз рәхмәтеннән аермасын).

Ул укытучысы Имам Мәлик каршында китап битен укытучысы ишетмәсен дип, акрын гына ача торган була.

Имам Шәфигый төнне өч өлешкә бүлә торган була: бер өлешен – гыйлемгә, икенче өлешен – гыйбадәткә, ә өченче өлешен йокыга калдырган.

Рамазан аенда намаз эчендә Коръәнне 60 тапкыр укып чыга торган була. Ул: «Уналты яшьтән бирле туйганчы ашаганым булмады», – дип әйтә торган була, – «чөнки туйганчы ашау ул тәнне авырайта һәм йөрәкне катыландыра, зирәклекне юкка чыгара, йокыны китерә һәм кешене гыйбадәттән читләштерә. Мин Аллаһы белән беркайчан да ант итмәдем», дип әйткән.

Имам Әш-Шәфигыйнең укучысы Әр-Рабигъ: «Мин имам Шәфигыйгә хөрмәт күрсәтү йөзеннән, аның каршында су эчмәдем», – дип әйткән.

4. Имам Әхмәд (Аллаһы аны үз рәхмәтеннән аермасын).

Имам Әхмәд әти-әнисе һәм укытучысы Шәфигый өчен 40 ел буена дога кылган, дип хәбәр ителә. Әбү Губәйдә исемле галим: «Бервакыт мин Имам Әхмәднең хәлен белү өчен төрмәгә кердем, шулвакыт миннән бер кеше дини мәсьәлә хакында сорады, ләкин мин Имам Әхмәдкә ихтирам йөзеннән аңа җавап бирмәдем», – дип әйткән. Имам Әхмәд китапларның нөсхәсен язып акча эшли торган була. Әбү Давыд Имам Әхмәд турында: «Ул беркайчан да дөньяны искә алмый иде. Ул 40 ел буе фәкыйрьлеккә сабыр итте. Әгәр дә ул үзенә бирелгән бүләкләрнең бер өлешен генә алган булса, иң бай кеше булыр иде. Моңа карамастан ул юмарт кеше булды, өч тапкыр җәяү хаҗ кылды», – дип әйткән.

Аллаһы Тәгалә барыбызга да бары тик файдалы белемнәр алырга насыйп итсә иде. Әмин!

*ТҖ МДН Дәгъват бүлеге*

*28 нче декабрь вәгазе,*

*Рабигыль-ахыр аеның 21 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Җомга көненең фазыйләтләре

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا نُودِيَ لِلصَّلَاةِ مِن يَوْمِ الْجُمُعَةِ فَاسْعَوْا إِلَىٰ ذِكْرِ اللَّهِ وَذَرُوا الْبَيْعَ ۚ ذَٰلِكُمْ خَيْرٌ لَّكُمْ إِن كُنتُمْ تَعْلَمُونَ ﴿٩﴾ فَإِذَا قُضِيَتِ الصَّلَاةُ فَانتَشِرُوا فِي الْأَرْضِ وَابْتَغُوا مِن فَضْلِ اللَّهِ وَاذْكُرُوا اللَّهَ كَثِيرًا لَّعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ ﴿١٠﴾

**«Әй, Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә иман китергән бәндәләр! Җомга көнне намазга чакырган азан тавышын ишетү белән, бөтен эшне, сату-алу, дөнья мәшәкатьләрен калдырып, Аллаһыны зикер итәргә ашыгыгыз. Бу, әгәр белсәгез икән, сезнең өчен хәерлерәк. Намазларыгызны укып бетергәч, таралып Аллаһы фазылыннан ризык эзләвегезне дәвам итегез (эшләп), шулай гына морадларыгызга ирешерсез».**

«Җомга», 62:9-10

«Җомга» дигән сүз гарәп теленнән тәрҗемә итсәк, җыелган дигән мәгънәне бирә, ягъни Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә җир шарын, җир йөзендәге булган һәрнәрсәне, тауларны, яссылыкларны, җиде кат күкне, күктәге җем-җем иткән йолдызларны, айны, җылылык чыганагын – кояшны, барын да алты көндә юктан бар итеп яратты һәм җомга көнендә халикъ кылуны тәмам итте.

Көннәрнең иң бөеге һәм иң олысы – һичшиксез, җомга көнедер. Җомга көненең Аллаһы Тәгалә каршысындагы бөеклеге Корбан һәм Ураза гаетләреннән дә олырак. Бу көннең биш фазыйләте бар: «Бу көнне Адәм галәйһиссәлам яратылды, шул ук көнне ул җиргә төшерелде һәм шулай ук җомга көнендә вафат та булды. Бу көндә барлык догаларның кабул ителү сәгате бар. Кыямәт көне дә җомга көнендә булачак. Һавада, җирдә яки суда нинди генә җан иясе булмасын – һәрбересе җомга көненең олылыгыннан тетрәп калтырар». Бу вакыйгалар Ибне Мәҗәһ җыентыгындагы хәдистә риваять ителә.

Җомга көн Аллаһы Тәгалә тарафыннан мөэминнәрнең бәйрәме буларак кабул ителгән һәм ул көннәрнең патшасы. Шул сәбәпле җомга намазын уку өчен һәрбер мәхәлләдә – шәһәр һәм авылда булган кешеләр мәчеткә җыелып имамның хөтбәсен, вәгазен тыңлыйлар, мөселманнар үз араларында бер-берсе белән танышып, хәлләрен сорашалар, ике җомга арасында булган вакыйгаларга бәйле вәгазьләрне ишетеп, тәэсир алалар һәм бергә Аллаһы Тәгаләгә сәҗдә кылып, ислам кардәшлеген яңарталар. Җомга намазы гаять әһәмиятле һәм файдалы. Моны игътибарга алмау һәм гозер булмый торып җомга көнне мәчеткә бармый калу – күңел каралудан башка нәрсә түгел. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр бер кеше гозерсез өч җомганы калдырса, Аллаһы Тәгалә аның күңелен мөһерләп куя», – дип әйткән. Һәм икенче бер хәдистә: «Кем бернинди сәбәпсез өч җомга намазын калдырса, шул безнең өмммәттән түгел», – дип әйтелә.

Ә менә мәчеткә алдан беренче булып килүнең бик зур савабы бар. Бу хакта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Җомга көнне фәрештәләр мәчетнең ишек төпләрендә кешеләрне көтеп торырлар һәм беренче, икенче, өченче килгәннәрне язып барырлар. Шулай итеп, җомгага иртәрәк, беренче килүчеләр бер дөя чалган әҗер-савапка ирешерләр. Аннан соң килүчеләр бер сарык чалып, аны садака

итеп өләшкән әҗер-савапка ирешерләр. Моннан соңрак килүчеләр – бер тавыклык әҗер-савапка, моннан соң килүчеләр тавык йомыркасын өләшкән әҗер-савапка ирешерләр».

Кем җомганың иртәнге сәгатьләрендә тәһарәт алып, мәчеткә җәяүләп килсә, аннары бер сүз дәшмичә вәгазь тыңлап, намаз укыса, аңа мәчеткә атлап килгән һәр адымы өчен бер еллык ураза әҗере (икенче бер хәдистә килә – һәр адымы өчен 20 еллык савап) язылыр. Һәм атлап килгәндә кешенең аяклары Аллаһы юлында тузанлану сәбәпле, Кыяматтә бу аякларны Аллаһы Тәгалә җәһәннәм утында яндыруны харам кылыр. Бу хәдисне Тирмизи җыентыгында укый алабыз.

Икенче бер хәдис имам Бохарида китерелә: «Кем җомга көнне госелләнеп, яхшы киемнәрен киеп һәм исле майлар сөртеп, этешмичә мәчеткә җомга вәгазен тыңларга килсә, имам минбәргә менеп, намазыннан аерылганчыга хәтле эндәшмичә хөтбәсен тыңлап, намазын укыса, аның ике җомга арасындагы гөнаһлары гафу ителер».

Динебездә намаз гыйбадәтен беренче сафларда башкару бик саваплы эшләрдән санала. Ләкин мәчеткә соң килүчеләргә намаз уку өчен урынны беренче сафларда табу һәрвакытта да мөмкин булмый. Шуңа күрә дә мәчеткә иртәрәк килү хупланган эш булып санала, мәчеткә соң килеп, алгы сафка барам дип, башкаларга кыенлыклар тудыру – тыелган эшләрдән булып санала. Моның турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәдисендә әйтә: «Җомга хөтбәсенә соң килеп, кеше өстеннән атлап, аларга кыенлык тудыручылар үзләренә җәһәннәмгә илтә торган күпер салалар. Әгәр инде кеше намазга соңарып килсә, мәчет намазын һәм алдагы 4 рәкәгать сөннәт намазын укымыйча, тыныч кына имамның вәгазен тыңларга тиеш. Җомга көнне мәчетнең һәр ишеге алдына ике фәрештә килеп, җомгага килүчеләрне гамәлләр дәфтәренә чиратлап яза башлыйлар. Имам минбәргә чыгып, хөтбәсен укый башлагач, фәрештәләр дә дәфтәрләрен ябып, имамның хөтбәсен тыңлый башлар-

лар. Инде мәчеткә килеп, диккать белән җомга вәгазен тыңлаган кешенең шушы җомга көннән алып, 10 көн эчендә эшләнгән кечкенә гөнаһлары кичерелер. Әгәр кеше башкаларга вәгазьне тыңларга комачаулап, сөйләшеп утырса, бу кешенең барча изгелекләре, намазлары бушка булыр. Моның хакында имам Мөслимнән хәдис китерелә: «Җомга хөтбәсе укыган вакытта яныңдагыңа «сөйләшмә» дип әйтсәң дә, гөнаһлы буш сүз сөйләгән булырсың».

Җомга көне эчендә бөтен догалар кабул булган бер сәгать бар, әмма бу вакытның кайсы сәгатьтә икәнен беркем белми, бу хакта галимнәр төрле фикердә. Чөнки бу хакта сигез сахих хәдис китерелә: «Җомга көне эчендә бер сәгать бардыр ки, бу сәгатьтә намаз укып, дога кылган һәрбер колның догалары Аллаһы Тәгалә тарафында һичшиксез кабул ителер».

Икенче бер хәдистә болай диелә: «Аллаһы Тәгалә «Бәйт Әл-мәгьмур» урыны янында көмештән ап-ак манара бар кыла. Ул манараның биеклеге 500 еллык юл кадәрдер. Җомга көнендә Җәбраил галәйһиссәлам ул манарага чыгып азан әйтер. Исрафил галәйһиссәлам минбәрдән хөтбә-вәгазь сөйләр. Микаил галәйһиссәлам бөтен фәрештәләргә имам булыр. Намаз беткәч, Җәбраил галәйһиссәлам: «Мин азан укып алган савабымны дөньядагы азан укыган мөэминнәргә тапшырдым», – дип әйтер. Исрафил галәйһиссәлам: «Мин сөйләгән вәгаземнең савабын дөньядагы вәгазь сөйләүче мөэминнәргә тапшырдым», – дип әйтер. Микаил галәйһиссәлам: «Мин имам булып, намаз укытуымның савабын дөньядагы барча имамнарга тапшырдым», – дияр. Шуннан соң барча фәрештәләр: «Җәмәгать булып укыган намазның савабын дөньядагы җәмәгать булып намаз кылган барча мөэминнәргә тапшырдык», – дип әйтәләр. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә фәрештәләрдән: «Сез Миннән дә юмартракмы?» – дип сорап, Үзенең бу соравына җавап итеп дөньяда җомга намазын кылган мөэминнәрнең барча гөнаһларын кичереп, фәрештәләрдән күпкә юмарт булуын күрсәтә.

Пәйгамбәребезнең шундый сүзе бар: «Җомга көненең 24 сәгате эчендә Аллаһы Тәгалә 600 мең кешене җәһәннәм утыннан коткарып кала торган вакытны билгеләде. Бу пәнҗешәмбе көнне ахшам намазыннан башлап, җомга көненең соңгы намазына кадәр вакыт арасы». Кем белә, бәлки күп хәер догалар кылып, гөнаһларыбызны Аллаһы Тәгаләдән кичерүен сорап тәүбә итсәк, бәлки яшерелгән кичерелү вакытына туры килербез, һәм мәгъфурлардан, мәңгелегебез кичерелгән кешеләрдән булырбыз, ин шә Аллаһ! Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

يَوْمَ يُكْشَفُ عَن سَاقٍ وَيُدْعَوْنَ إِلَى السُّجُودِ فَلَا يَسْتَطِيعُونَ ﴿٤٢﴾ خَاشِعَةً أَبْصَارُهُمْ تَرْهَقُهُمْ ذِلَّةٌ ۖ وَقَدْ كَانُوا يُدْعَوْنَ إِلَى السُّجُودِ وَهُمْ سَالِمُونَ ﴿٤٣﴾

**«Ахирәттә эшләрнең пәрдәләре ачылыр, хак ялганнан аерылыр һәм сәҗдәгә чакырылырлар. Ләкин кяферләрнең һәм монафикъларның сәҗдә кылырга көчләре җитмәс. Куркудан күзләре түбән караган булыр һәм аларны хурлык каплар. Хакыйкатьтә аларга дөньяда сәҗдә кылырга, ягъни намаз укырга боерылган иде. Ләкин укымадылар, үзләре сәламәт иде. Намаз укымаска һич гозерләре юк иде».**

«Нун», 68:42-43

Хәзерге заман кешеләре Аллаһы Тәгалә юлыннан тайпылып, мал туплау белән мәшгуль. Ләкин моның зур бәла икәнен адәм баласы, әлбәттә, аңламый, яки аңларга да теләми. Мәңгелеккә ризык әзерләргә кирәк. Никадәр алдаучан дөнья артыннан кусаң, шулкадәр Аллаһыдан ерагаюыңны аңлату – безнең бурыч. Элеккеге заманаларда безнең бабаларыбыз ач-ялангач булсалар да, гыйбадәтләрен калдырмаганнар, малга, җиргә кызыгып диннәрен ташламаганнар. Дин кысрыкланган еллар-

да җомга намазларын яшерен урыннарда качып укыганнар, алар шулай сынмыйча динне безгә җиткергәннәр.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Без Аллаһы Тәгаләнең Китабын, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтен, безгә гасырлар буе буыннан-буынга мирас булып килгән бөек Ислам динебезне үзебездән соң киләчәк яңа буын бала-оныкларыбызга тапшырыйк. Йә, Раббыбыз Аллаһы! Безгә исәнлек-саулык, хәерле озын гомер бир һәм үзебездән соң нәселне дәвам итүче, тәкъва, галим балалар калдырырга насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Хәйбуллин,*

*Буа районы «Мәлик» мәчете имам-хатыйбы*

*4 нче гыйнвар вәгазе,*

*Рабигыль-ахыр аеның 28 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Тәүбә кылу һәм Аллаһыдан өметне өзмәү

Аллаһы каршында һәр кеше үзе өчен җавапны үзе бирәчәк: гыйбадәт кылдымы, намаз укыдымы, ураза тоттымы? Хәләл белән яшәдеме; хәерле эшләр кылдымы; Аллаһының әмеренә буйсынып, Аллаһының фарызларын һәрдаим үтәп барырга тырыштымы; гыйлем алып, гыйлем эстәп, аның белән гамәл гыйбадәт кылдымы – һәрберсе өчен үзе җавап бирә. Хәләл белән яшәсә, хәләл өчен җавап бирәчәк, ә менә харам белән яшәсә, җавабы да каты, газабы да каты булыр. Аллаһыга шөкер, безгә иман нигъмәте бирелгән. Шуңа күрә иманыбыз белән файдаланыйк, тәүбәгә ашыгыйк. Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә рәхмәт карашы белән карар да: «Тәүбә кылучылар юкмы – тәүбәләрен гафу итәм», – дип әйтә». Кеше үз тормышында бик күп гамәлләр башкара. Алар арасында хәерлесе дә бар, хәерсезе дә, гөнаһлы вә ярамаганнары да бар. Кешеләр арасында зур гөнаһлылардан алып, кечкенә генә бер кимчелекклеләре яки ялгыш хаталылары да була ала. Кемнеңдер Аллаһы каршында гөнаһы бик күп, ә кемнекедер бик аз. Шуңа карамастан, бер генә кеше дә үзен гөнаһсыз, пакь дип атый алмый. Гәрчә, андый кешеләрне бүгенге көндә очратып була. Алар: «Мин үз гомеремдә бер кешене дә рәнҗетмәдем, бер кешегә дә зыян салмадым. Бер гөнаһ та кылмадым», – дип әйтәләр. Әле кайбер 5 вакыт намаз әһелләре дә шушы сүзләрне ялгыш кына әйтеп куялар. Әмма, тузан бөртеге генә кадәр гөнаһ та Аллаһы каршында зур була ала. Бер кечкенә генә бөҗәкне ялгышлык

белән таптап китсәк тә, аның өчен дә гөнаһ алып була, чөнки ул да Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә мәхлукаты бит.

Шуңа күрә дә Аллаһы Тәгалә безгә тәүбә ишекләрен ачык итеп кылган һәм шул рәвешле гөнаһтан арынырга безгә мөмкинлек биргән. Әмма, әлбәттә, зур гөнаһлар да бар, аларын Аллаһы Үзе теләсә, гафу итә, теләмәсә, юк! Әти-әнине рәнҗетү, кешеләрне нахакка рәнҗетү, кешенең хакына керү дә, харамга керешү дә (хәләл барын белә торып, харам куллanып яши башлау) – болар да зур гөнаһка керә. Әлбәттә, алар бик күп һәм төрле.

Әмма, безгә Аллаһының гафу итәргә яратучы зат икәнен исебездән чыгарырга ярамый. Кеше: «Йә, Раббым, гөнаһларымны, хаталарымны, кимчелекләремне гафу кыл, мине алардан арала. Мин Синең каршыңда тәүбә кылам», – дисә, шуңа өстәп, бу гөнаһларга башка бервакытта да әйләнеп кайтмаска сүз бирсә, Аллаһы Тәгалә Үзе теләгән бәндәсен ярлыкар, ин шә Аллаһ.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә: «Тәүбә кылган кеше бернинди дә гөнаһы булмаган кешегә охшаган», – дип әйтә. Бу очракта үз гөнаһын аңлап, аның турында уйланып, бу эшне бүтән башкармам дигән ният белән тәүбә кылу турында сүз бара. Биш вакыт намаз, ураза әһеле үзен пакь итеп хис итсә дә: «Йә, Раббым, гафу ит», – дип һәрвакыт дога кыла. Намаз укыгач, һәрберебез өч тапкыр «Әстәгъфируллаһ» дип әйтәбез. Ни өчен шулай күп тапкырлар кабатлыйбыз соң? Намаз укыганда әллә ничә төрле дөнья уйлары, дөнья фикерләре дә башыбыз аша уза ала: без базарга да барып кайтабыз, өебезгә дә йөгереп кайтып киләбез. Менә шуңа күрә без намаз укыгач та Аллаһы Тәгаләдән гафу сорап куябыз.

Гомумән алганда, көн саен берәр намаздан соң тәсбих алып, 100 мәртәбә булса да «Әстәгъфируллаһил-газыйм» дип әйтсәк, ничек хәерле булыр иде. Кыямәт көнендә Аллаһы каршында җавап кайтарулары бер дә

җиңел булмас, диелә бит. Бүгенге көндә бар да җиңел, менә бигрәк тә олы яшьтәгеләр: «Аллаһыга шөкер, бүген инде рәхәт тормышта яшибез», – дип әйтеп куялар. Чыннан да, авырлык юк бит, кая гына карасаң да җиңеллек кенә: ризык мәсьәләсендә дә, транспорт мәсьәләсендә дә һ.б.ларда да. Әлбәттә, авырлык күрүчеләр юк түгел, әмма Аллаһыга гыйбадәт кыла алабыз, тырышсак, үзебезгә күп нәрсәдә җиңеллек таба алабыз.

Инде кешене бу тормышта гөнаһ кылырга ни этәрә соң, дип сорасак, җавабы: кеше үзенең битарафлыгы аркасында, яки ваемсызлыгы аркасында бер гөнаһ эшли. Яки берәр тиеш булган вазифаны башкармавы аркасында гөнаһка чума. Инде шушы ялгышлыкларын тиз арада танып алган кеше, күңелендә тәүбә кылырга кирәклеген аңлый. Аллаһы каршында гөнаһ белән басып торып булмый дигән кеше: «Йә, раббым, гафу ит мине», – дип әйтә.

Зур галимнәребезнең үзләренә карата фикерләрен беләсез: алар үзләрен бик түбән дәрәҗәле, гөнаһлы кол итеп күрәләр, Аллаһы каршында үзләрен шулай тоталар. Алар ни өчен шундый тормыш рәвеше алып баралар соң? Ул галимнәребез бу түбән дөнья тормышына алданып китергә куркалар. Алар бу дөнья байлыкларын, бу дөнья мәшәкатьләрен артка калдырып, Аллаһының ризалыгын алуны иң беренче урынга куялар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең төнге намазларда басып торуыннан үкчәләре ярылып бетә торган булган. Сәхабәләр аннан: «Аллаһы Тәгалә синең үткән һәм булачак гөнаһларыңны ярлыкады бит инде. Ни өчен шуның кадәр гыйбадәт кыласың соң?» – дип сорагач, Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Минем шөкер кылучы кол буласым килмимени?» – дип җавап кайтарган.

Бу дәрәҗәгә ирешеп булмаса да, аңа ничек якынаеп була соң? Беренчедән, Аллаһы Тәгаләнең газабыннан, икенчедән, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән, өченчедән, Аллаһы Тәгаләнең контроленнән беркая да качып, котылып булмый. Шуны аңларга кирәк. Әгәр Аллаһы Тәгалә берәр

кешегә газабын җибәрсә, кая качып котыласың? Үлем килсә, язылган соңгы сулышыңны аласың да, бүтән берне дә арттыра алмыйча, үлеп китәсең. Бер сүз дә әйтергә, бер артык хәрәкәт тә кылырга мөмкин түгел.

Күңелендә тәкъвалык булган кеше үзенең кылган гамәлләренә, әйткән сүзләренә беркайчан да битараф түгел. Тәкъва бәндә үз гамәлләренә хакыйкый күзлек белән карап, һәрвакытта да: «Мин берәр гөнаһлы гамәл кылмыйм микән», – дип уйлый, – «Йә, Раббым Аллаһы, гөнаһларым күп инде, мине ярлыкасаң иде», – дип, Аллаһыдан гафу сорый.

Тәүбә кылу берәр изге гамәл белән дәвам ителсә, бу бик күркәм күренеш булачак. Хәдисләрдә: «Әгәр бер гөнаһлы гамәл кылсагыз, аның артыннан бер изге гамәл кылыгыз. Бу изге гамәл начар гамәлнең гөнаһын каплар», – дип килә. Тәүбә кылу да бар, шуңа өстәп Пәйгамбәребез: «Начар гамәл кылып, гөнаһлы булганнан соң да, изге гамәлгә таба атла», – дип әйткән кебек.

Аллаһы Тәгалә кешене зәгыйфь итеп бар кылган: җил бу яктан иссә, бу якка, теге яктан иссә, теге якка авып китәргә торабыз. «Кемнең арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың», – диләр бит. Әмма әгәр кеше һәрвакыт тәүбә-истигъфарда булса, кешенең күңеле чистара. Ул кеше Аллаһы каршында пакь, саф йөрәк белән басып торачак. Ә бу чисталык, бу нур башка кешеләргә дә күчә ала бит. Шуңа күрә максатыбыз булып һәрвакыт тәүбәгә ашкыну, аңа әзерлек булырга тиеш. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримгә «Тәүбә» сүрәсен юкка гына урнаштырмаган. Ул сүрә андагы гыйбрәтле вакыйгаларны, Нух галәйһиссәлам, Муса галәйһиссәлам кавемнәренең бозыклыклары турында укып, сабак алырга кирәклеге турында исебезгә төшерә. Кеше зәгыйфь, гөнаһ кылучан, әмма Аллаһы Тәгалә кешене Үзе шулай яраткан һәм ул кешенең тәүбә кылганын ярата. Пәйгамбәребез: «Әгәр кешеләр гөнаһ кылудан туктасалар, Аллаһы Тәгалә ул кешеләрне юк итеп, алар урынына гөнаһ кылучы кешеләрне бар кыла-

чак», – дип әйтә. Ягъни, гөнаһ кылганнан соң гафу сорап, Аллаһыга кайтучыларны бар кылачак.

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өметне өзәргә беркайчан да ярамый!

Кеше берәр гөнаһлы гамәл кылганнан соң, уң яктагы фәрештә сул яктагысына: «Ашыкма, әле кич җитмәгән, бәлки ул тәүбә кылыр», – дип әйтер. Кеше тәүбә кылса, ул аның бу гамәлен бер изге гамәл итеп язар. Мөэмин-мөселман, гөнаһ кылганнан соң, бу эшкә кире әйләнеп кайтмаячагын әйтеп, тәүбә итсә, ин шә Аллаһ, ярлыканыр. Мөэмин-мөселман беркайчан да Аллаһының гафу итәчәгенә өметен өзми. Риваятьләрдә Кыямәт көнендә җәһәннәмгә атылырга тиеш булган мөэмин-мөселманга: «Аллаһыдан өметеңне өзмә, Аллаһының рәхмәте киң», – дип әйтелер. Бу тормышта да Аллаһыдан күз яшьләре белән ялварып сорасак, чын күңелдән үкенсәк, ин шә Аллаһ, Аллаһы Тәгалә безне җәһәннәм утыннан саклап калыр. Галимнәребез: «Бер тамчы күз яше җәһәннәм утын сүндерә ала», – дип тә әйтеп калдырганнар. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ اللَّهَ لَا يَغْفِرُ أَن يُشْرَكَ بِهِ وَيَغْفِرُ مَا دُونَ ذَٰلِكَ لِمَن يَشَاءُ ۚ ﴿٤٨﴾

**«Аллаһы үзенә тиңдәшлек кылуны гафу итмәс, тиңдәшлек кылудан башка гөнаһларны Үзе теләгән кешедән гафу итәр».**

«Нисә / Хатыннар», 4:48

Ә бу аять исә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өметебезне өзмәс өчен иң яхшы сәбәп булып тора. Аллаһы Тәгалә барыбызга да хәер-сәгадәт, истикамәтләр бирсә иде. Әмин.

*Марсель хәзрәт Сабиров,*

*«Болгар» мәчетенең икенче имам-хатыйбы*

# Фәтвалар

# Зәкятне нисаб күләменнән артыграк итеп түләргә ярыймы?

**Сорау: Ярлы кешегә зәкятне нисаб күләменнән артыграк итеп бирергә ярыймы?**

Җавап: Нисаб күләме 100 000 сум, дип күз алдына китерик. Бай кеше бер үк мохтаҗ кешегә башта 50 000 сум, күпмедер вакыт узганнан соң тагы 40 000 сум, янә күпмедер вакыт үткәч 60 000 сум бирде, ди. Ягъни барлыгы ул 150 000 сум биргән. Бу рөхсәт ителә, чөнки түләүләр төрле вакытта һәм аларның күләмнәре нисабтан кимрәк иде. Бай кеше мохтаҗга соңгы 60 000 түләгәндә дә, ул кеше әле фәкыйрь санала иде, чөнки аның нисабы юк иде. Шул рәвешле, бу бар түләүләр дә зәкяттән санала.

Хәзер башка очракны карап китик. Нисаб күләме шулай ук 100 000 сум, дип күз алдына китерик, әмма бу юлы бай кеше мохтаҗга 500 000 сум түли. Башта ул аңа берьюлы 200 000 сум, аннан соң өчәр тапкыр 100 000 бирә, ди. Бу очракта зәкят булып беренче бирелгән 200 000 сум гына саналачак, чөнки аларны алганнан соң, мохтаҗ кеше фәкыйрь булып саналмый башлады, ул алган акчалар нисаб күләменнән артып китте.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР мөфтие*

# Башка кешенең бурычын түләү зәкят була аламы?

**Сорау: Зәкят бирү нияте белән башка кешенең бурычын түләргә ярыймы?**

Җавап: Башка кешенең бурычын капларга теләсәгез, аңа: «Мин зәкят түләп, синең бурычыңны капларга телим», – дип әйтергә тиешсез.

Әҗәтле кеше: «Бурычымны түлә», – дип ризалашса, сез акча түләгәннән соң зәкят түләгән дә, кешенең бурычын каплаган булып та саналачаксыз («Радд әл-Мохтар»).

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР мөфтие*

## Зәкят бай кешегә бирелсә

**Сорау: Мин зәкят түләгән кешенең фәкыйрь булмавы ачыкланды. Миңа хәзер нишләргә?**

Җавап: Бу мәсьәлә буенча берничә төрле фикер булса да, бу зәкят дөрес һәм аны яңадан түләргә кирәкми, дигән фикер гомум кабул ителгән булып санала (имам Мәүсыли, «Әл-Ихтыяр»).

Бай кеше аңа бирелгән акчаның зәкят булуын белмәскә дә мөмкин, әмма ул акчаларның зәкят икәнен белеп алганда, моның өчен җавап тотачагын аңларга тиеш.

Янә шуны да искәртәсе килә: зәкят түләүче кеше ниятен кычкырып әйтмәсә дә ярый, калебтә ниятләү җитә.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР мөфтие*

# Үрнәк затлар

# Өченче тугры хәлифә – Госман радыяллаһу ганһе

**Тулы исеме:** Госман бине Гаффән бине Әбү Әл-Гас бине Өмәйя бине Габдешшәмс бине Габдемәнәф бине Кусайй бине Киләб Әл-Өмәви Әл-Кураши.

**Әтисе:** Гаффән бине Әби Әл-Гас.

**Әнисе:** Әрва бинте Курайза.

**Кушаматлары:**

1) «Әбү Гамр» – җаһилият заманында йөрткән кушаматы.

2) «Габдуллаһ» – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кызы Рокыя аңа Габдуллаһ исемле ир бала тапканнан соң, Госманны «Әбү Габдуллаһ» дип йөртә башлыйлар.

3) «Зин-Нурәйн» – «ике нур иясе». Әлеге кушаматка нисбәтле ике версия бар: беренчесе – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ике кызы (Рокыя, Өмме Көлсем) белән никахлашканы өчен бирелгән; икенчесе – үзенең төнге намазларында Коръәнне күп укыганга (Коръән – нур һәм төнге намаз – нур).

**Яшәгән еллары:** Госман радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез Мөхәммәдтән (аңа Аллаһының сәламе һәм рәхмәте булсын) 6 яшькә кечерәк булып, якынча 577 елда Мәккәдә туган. 656 елда Мәдинәдә вафат була.

**Хәлифәлек еллары:** 644 – 656 (12 ел дәвамында хәлифә булып торган).

**Балалары:** уллары – Габдуллаһ (олысы), Габдуллаһ (кечесе), Гамр, Халид, Абан, Гомәр, Әл-Вәлид, Сәед, Габдуллаһ; кызлары – Мәрьям, Өмме Сәгъд, Гайшә, Өмме Абан, Өмме Гамр, Мәрьям, Өмме Әл-Бәнин.

## Ислам динен кабул итүе

Госман радыяллаһу ганһе ислам динен беренче булып кабул итүчеләрдән санала. Ул ислам динен 30 (кайбер чыганакларда 34 дип килә) яшендә, Әбү Бәкернең дәгъваты белән кабул итә. Беркөнне Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе Госман радыяллаһу ганһене туктатып: «Әй, Госман, күрче безнең халкыбыз нинди тирән адашу белән адашкан. Алар файда да, зыян да китерә алмаган таш сыннарга гыйбадәт кылалар», – дип әйткән. Госман аңардан: «Ә син нәрсә тәкъдим итәсең соң?» – дип сорагач, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе аңа: «Син Габдуллаһ улы Мөхәммәдне тыңлап кара әле, ул бер илаһлыкка чакыра. Үзен Аллаһының Илчесе дип әйтә», – дигән. Нәкъ шул вакытта алар яныннан Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үтеп бара торган булган һәм ул Госманны күреп: «Әй, Госман, Аллаһы Тәгалә сине Җәннәткә чакыра, ислам динен кабул ит», – дип әйткән. Госман исә үзен әнә шул көнне ислам динен кабул итүдән бернәрсә дә тыеп тора алмаганын хәбәр иткән.

Шулай ук, Госман радыяллаһу ганһенең бик тиз арада ислам динен кабул итүенә түбәндәге вакыйга да сәбәпче булырга мөмкин. Шамнан чираттагы сәфәреннән кайткач, Госман Талхә бине Гобәйдуллаһ белән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына керәләр. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһының сәламе һәм рәхмәте булсын) аларны исламга чакыра һәм Коръәннән сүрәләр укый, динне кабул иткән кешенең вазифаларын аңлата. Алар Мөхәммәд галәйһиссәламнең әйткән сүзләренә ышаналар, иман китерәләр. Шул вакытта Госман радыяллаһу ганһе: «Ий, Аллаһының Илчесе, мин әле генә Шамнан кайттым. Без Мәгән белән Әз-Зәрка арасында булганда, безне бер сөрән салучы уятып: «Әй, йоклаучылар, уяныгыз! Дөреслектә, Макталган Мәккәдә икән!» – дип әйтте. Инде кайтып җиткәч, без синең хакында ишеттек», – дигән.

Госман радыяллаһу ганһе ислам динен кабул иткәч, абыйлары тарафыннан төрлечә эзәрлекләүләргә дучар була, төрле газап-җәфалар күрә.

Башта аяк-кулларын бәйләп, базга ташлыйлар, соңыннан төтен белән буалар. Ләкин нинди генә авырлыклар күрсә дә, ул диненә тугры кала.

## Хәзрәти Госман радыяллаһу ганһенең Рокыя белән никахлашуы

Мөселманнар Госманның ислам динен кабул иткәнен белгәч бик шатланганнар һәм шул көннән алып аларны аның белән кардәшлек җепләре бәйләгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кызын Госманга кияүгә биреп, аңа олы хөрмәт белән караган.

Бу гаиләнең барлыкка килү тарихы болайрак: үз вакытында Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Рокыяны – Готбә бине Әбү Ләһәбкә, ә аның апасы Өмме Көлсемне – Готәйб бине Әбү Ләһәбкә ярәштергән була. Шуннан соң Аллаһы Тәгаләдән түбәндәге сүрә иңдерелә:

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ

تَبَّتْ يَدَا أَبِي لَهَبٍ وَتَبَّ ﴿١﴾ مَا أَغْنَىٰ عَنْهُ مَالُهُ وَمَا كَسَبَ ﴿٢﴾
سَيَصْلَىٰ نَارًا ذَاتَ لَهَبٍ ﴿٣﴾ وَامْرَأَتُهُ حَمَّالَةَ الْحَطَبِ ﴿٤﴾ فِي جِيدِهَا
حَبْلٌ مِّن مَّسَدٍ ﴿٥﴾

**«Әбү Ләһәбнең ике кулы корысын һәм һәлак булсын! Һәм һәлак тә булды! Аңа газаптан котылырга малы һәм кәсеп иткән нәрсәләре һич файда бирмәде. Тиздән ул ялкынлы утка кереп янар. Хатыны да утын күтәргән хәлдә утка керер. Ул хатынның муенында хөрмә мунчаласыннан булган бау бардыр».**

«Мәсәд / Бау», 111

Бу турыда белгәннән соң, Әбү Ләһәб һәм аның хатыны Өмме Җәмил бинте Хәрб бине Өмәйя улларына: «Мөхәммәднең кызлары белән аеры-

лыгыз!» – дип әмер бирәләр. Уллары әти-әнисенең сүзен тыңлап, гаилә тормышын башлаганчы ук хатыннарын аералар. Шул рәвешле, Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кызларын олылый, ә Әбү Ләһәбнең улларын түбәнсетә. Рокыяның аерылган хәбәрен ишеткән Госман радыяллаһу ганһе тиз арада Мөхәммәд галәйһиссәлам янына барып, кызының кулын сорый. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу никахка ризалыгын бирә. Хәдичә бинте Хөвәйлид кәләшне Госман янына үзе илтә.

Габдеррахман бине Госман Әл-Курашидан риваять ителгән: «Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кызы янына кергәч, аны Госманның башын юган хәлдә күргән һәм кызына нәсыйхәт буларак: «Кызым! Әбү Габдуллаһка яхшы мөнәсәбәттә бул, хакыйкатьтә, минем барлык сәхабәләрем арасыннан аның холкы минем холкыма якындыр», – дип әйткән».

## Хәзрәти Госман радыяллаһу ганһенең һиҗрәте

Мәккә мөшрикләре тарафыннан мөселманнарны кысрыклау, газаплаулар арткач, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманнарга Мәккәдән Хәбәшкә һиҗрәт кылырга рөхсәт итә.

Госман радыяллаһу ганһе хатыны Рокыя белән 12 ир-ат һәм 4 хатын-кызны ияртеп, Хәбәшкә (Эфиопия) һиҗрәт кыла. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларга: «Сез Лут галәйһиссәламнән соң динне саклау өчен беренче һиҗрәт кылучылар», – дип әйткән. Бу вакыйга 5 нче пәйгамбәрлек елының раҗәб аенда була. Коръәндә дә Аллаһы Тәгалә алар турында искә ала:

وَالَّذِينَ هَاجَرُوا فِي اللَّـهِ مِن بَعْدِ مَا ظُلِمُوا لَنُبَوِّئَنَّهُمْ فِي الدُّنْيَا حَسَنَةً ۖ
وَلَأَجْرُ الْآخِرَةِ أَكْبَرُ ۚ لَوْ كَانُوا يَعْلَمُونَ ﴿٤١﴾

**«Залимнәрдән золым күргәннән соң, хак мөэминнәр иркен урынга күчеп киттеләр. Без аларга дөньяда ук яхшы тормыш бирербез. Дөреслектә, аларга Ахирәттә биреләчәк нигъмәт олыграк, әгәр шуны кешеләр белсәләр».**

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:41

Шулай ук Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

قُلْ يَا عِبَادِ الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا رَبَّكُمْ ۚ لِلَّذِينَ أَحْسَنُوا فِي هَٰذِهِ الدُّنْيَا حَسَنَةٌ ۗ وَأَرْضُ اللَّهِ وَاسِعَةٌ ۗ إِنَّمَا يُوَفَّى الصَّابِرُونَ أَجْرَهُم بِغَيْرِ حِسَابٍ ﴿١٠﴾

**«Әй Мөхәммәд галәйһиссәлам, әйт: «Әй иман китергән Аллаһының бәндәләре, Раббыгызның газабыннан сакланыгыз! Дөньяда вакытта Аллаһыга итагать итеп, изге гамәлләр кылган хак мөэминнәргә Ахирәттә җәннәт нигъмәтләре бардыр. Аллаһы Тәгаләнең җире киңдер, торган җирегездә дингә тарлык булса, иркен җирләрнең теләгән урынына күчегез! Җиһад вә һиҗрәт мәшәкатьләренә сабыр итүчеләргә хисапсыз әҗерләр бирелер».**

«Зүмәра / Халык Төркеме», 39:10

## Хәзрәти Госман һәм Коръән

Госман радыяллаһу ганһе ислам динен кабул иткәннән соң иң күп гыйбадәт кылучылардан була. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән Коръән серләренә төшенә. Әбү Габдеррахман Әс-Сүләми: «Безне Коръән укырга өйрәткән Госман бине Гаффән, Габдуллаһ бине Мәсгүд һәм башкалар иң элек Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән ишеткән ун аятьне яттан өйрәнгәннәр, аннан соң бу аятьләрдәге белемнәрне үзләштергәннәр һәм шул гыйлемнәрне гамәлдә

куллангач кына яңа аятьләр өйрәнгәннәр», – дип әйткән. Шуңа да һәрбер сүрәне яттан өйрәнер өчен алар бик күп вакыт сарыф иткәннәр. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйткән:

كِتَابٌ أَنزَلْنَاهُ إِلَيْكَ مُبَارَكٌ لِّيَدَّبَّرُوا آيَاتِهِ وَلِيَتَذَكَّرَ أُولُو الْأَلْبَابِ ﴿٢٩﴾

**«Без сиңа индергән китап күп файдалы вә бәрәкәтледер. (Аны) аятьләрен уйлап, фикерләп аңласыннар һәм гакыл ияләре вәгазьләнсеннәр өчен индердек».**

«Сад», 38:29

Госман радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм исән чагында аңа тулысынча Коръәнне укыган. Госман үзе дә башкаларга Коръәнне өйрәткән. Аның укучылары арасында Әбү Габдеррахман Әс-Сүләми, Әл-Мугыйра Әбү Шиһаб, Әбү Әл-Әсвәд һәм Зирр бине Хөбәйшләр булган.

Госман радыяллаһу ганһе Коръәнне яттан белгән һәм бик күп укыган, хәтта, намазының бер рәкәгатендә тулысынча Коръәнне укып чыккан вакытлары булган. Ул үзе үк: «Бу дөньяда өч гамәл күңелемә хуш килде: ач кешене туйганчы ашату, ялангач кешене киендерү һәм Коръән уку», – дип әйтә торган булган. Госманның гамәлләре Коръәннең түбәндәге аятенә туры килгән:

أَمَّنْ هُوَ قَانِتٌ آنَاءَ اللَّيْلِ سَاجِدًا وَقَائِمًا يَحْذَرُ الْآخِرَةَ وَيَرْجُو رَحْمَةَ رَبِّهِ ۗ قُلْ هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ ۗ إِنَّمَا يَتَذَكَّرُ أُولُو الْأَلْبَابِ ﴿٩﴾

**«Әмма кичләрдә озак вакыт кыямда торып, сәҗдә кылып, Аллаһыга гына коллык кылган мөэмин ахирәт газабыннан куркып Раббысының рәхмәтен өмет итәдер. Шул мөэмин кяфер яки мөшрик монафикъ белән бертигез булырмы? Әлбәттә,**

**һич бертигез булмас! Кешеләргә әйт: «Батылны белеп батылдан ерак булган, хакны белеп хак тарафында сабит булган хак мөэминнәр, батылны да, хакны да белмичә адашып йөргән сукырлар белән бертигез булырлармы? Хакны батылдан аеру хакында саф гакыллы кешеләр генә вәгазьләнерләр һәм батылдан бизеп хакны кабул итәрләр».**

«Зүмәра / Халык Төркеме», 39:9

Коръәннән ул бары тик Аллаһы Тәгалә генә гыйбадәт кылырга лаек зат булуын аңлаган, Аның каршында үз бурычларын таныган. Шулай ук Госманның җәннәт һәм җәһәннәм (тәмуг), кешенең асылы хакында күзаллаулары Коръәнгә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләренә туры килгән. Башка сәхабәләрдән үзенең төнге намазлары белән аерылып торган. Һәр гамәлендә (Коръән уку, руза тоту, намаз уку) ихлас булырга тырышкан. «Калебе пакь булган кеше Коръән укудан һич туймас», – дип әйтә торган булган. Үзе Аллаһы рәхмәте белән ислам динен кабул иткәч, ул диннең таралуына бар тырышлыгын куйган, хак юлдан барган имамнарның берсе булып, башкаларга да дөрес юлны күрсәткән.

## Хәзрәти Госман радыяллаһу ганһенең Аллаһы Тәгаләдән куркуы

Госман радыяллаһу ганһе ихлас, тәкъва мөселманнардан була. Ислам динен кабул иткәнче, ягъни җаһилият заманында да ул беркайчан да потларга табынмаган, әдәпсезлек күрсәтмәгән, җирәнгеч гамәлләр кылмаган, шәраб кулланмаган. Ул үзе турында: «Мин җаһилият заманында һәм исламга килгәч тә шәраб эчмәдем. Җаһилияттә һәм исламда да зина кылмадым», – дип әйткән.

Госман радыяллаһу ганһе хәләлне генә кулланып, харамнан ерак булырга тырыша. Җәннәткә керү өчен бөтен көчен куя. Сәхабәләр аңа: «Бу тырышлыгың белән без беркайчан да сине изгелектә куып тота алмабыз», – дип әйтәләр.

Һәрвакыт Ахирәтне исендә тотып: «Без бу дөньяда мосафирлар гына», – дип әйтә торган булган. Үлемне искә төшерү өчен каберлекләргә еш йөргән, шунда сакалы чыланганчы елаган. Сәхабәләр аннан: «Кабер газабыннан куркып елыйсыңмы әллә?» – дип сорагач, ул: «Әйе, кабер кешенең беренче барасы урыны. Әгәр ул анда котылса, Ахирәттә дә котылыр. Әгәр анда газапка дучар булса, Ахирәттә аның белән ни булыр?» – дип әйткән.

Госман радыяллаһу ганһе гаять дәрәҗәдә инсафлы, юаш, миһербанлы, олы йөрәкле, киң күңелле, гүзәл холыклы булган; янына килгән кешеләрне үзеннән разый итеп җибәрергә тырышкан; аның җаһилият вакытыннан ук Корәеш һәм башка гарәп кабиләләре арасында хөрмәте зур була.

Һәркемгә игътибарлы, гадел мөгамәләле, башкаларга золым, хыянәт итүдән, өстендә кеше хакы калудан бик курыккан, хәтта, үзенең гаиләсе һәм хезмәтчеләренең дә хәтерләрен калдыруны сөймәгән. Якын һәм ерак кардәшләренең һәммәсен үзеннән разый итәргә тырышкан. Аллаһы исеме белән ант итүдән бик нык сакланган. Беркайчан да сүзен уйламыйча әйтмәгән. Тел афәтеннән саклану өчен авызына таш кабып йөргән.

## Хәзрәти Госман радыяллаһу ганһенең холкына хас сыйфатлар

Госман радыяллаһу ганһе бер яктан тугры булса, икенче яктан бик тә тыйнак була. Үз дәрәҗәсенә карамастан, барлык кешеләр белән дә бер дәрәҗәдә сөйләшә. Габдуллаһ Әр-Румидан риваять ителә: «Госман төннәрен тәһарәт алыр өчен үзе суны әзерләгән. «Бу эшне хезмәтчеңә

кушсаң әйбәтрәк булыр иде», – дип әйткән кешеләргә ул: «Юк. Төн аларныкы, алар төнен ял итәләр», – дип җавап кайтарган».

Госман бик оялчан кешеләрдән санала. Шул сәбәпле, сәхабәләр дә аның янында кыек эш эшләргә батырчылык итмиләр.

Әбү Сәләмә бине Габдеррахман Гайшә радыяллаһу ганһәдән риваять иткән: «Аллаһының Илчесе минем өемдә аягын күрсәтеп яткан иде. Шулвакыт Әбү Бәкер керергә рөхсәт сорады һәм ул ризалык алып керде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм шул халәтендә аның белән сөйләште. Шуннан соң Гомәр радыяллаһу ганһе керергә рөхсәт сорады. Аның белән дә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әлеге халәтендә сөйләште. Бераздан Госман керергә рөхсәт сорады һәм Пәйгамбәребез торып утырды, чапан астыннан чыгып торган аягын каплап куйды». Госман кергәч, алар сөйләшәләр. Ул чыгып киткәч, Гайшә радыяллаһу ганһә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Әбү Бәкер һәм Гомәр кергәч тә, аларны син яткан хәлеңдә кабул иттең. Нигә син Госман кергәч кенә торып утырдың, киемеңне тәртикә китердең, аягыңны каплап куйдың?» – дип сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Мин Госманны оялтудан курыктым, аннан бит фәрештәләр дә ояла», – дип җавап кайтарган (Мөслим).

Госман бине Гаффән башкалардан матурлыгы белән аерылып торган. Эчке һәм тышкы матурлыгы белән дә корәешлеләрнең мәхәббәтен яулаган. Ул пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә охшаган була. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм кызы Рокыяга: «Синең ireңнән кала беркем дә әтиеңә һәм бабаңа охшамаган», – дип әйтә торган булган.

Госман радыяллаһу ганһегә йомшаклык кебек күркәм сыйфат та хас була. Ул үз мәхәллә халкына йомшак мөнәсәбәттә булган һәм өммәте өчен бик нык борчылган. Мәхәллә халкының берәрсенә бер-бер хәл бу-

лып, үзе ярдәм итә алмаудан бик курыккан. Көчсезләрнең хәлен кайгыртып, үзләрен өстен тотканнарны шелтәләгән.

Госман бине Гаффән батыр, көчле булган. Бәдер сугышыннан кала, бөтен бәрелешләрдә дә катнаша. Бәдер сугышы вакытында авыру хатыны Рокыяны карый һәм бәрелештә катнаша алмый.

Госман радыяллаһу ганһе сәхабәләр арасында үзенең юмартлыгы белән дә танылa. Аның сәүдә кәрваннары һәр тарафка йөреп сәүдә кыла. Кешеләр аны «юмарт Госман», «киң күңелле Госман» дип йөрткәннәр. Аның юмартлыгына мисал итеп түбәндәгеләрне китерергә була:

1. Ислам динен кабул иткәннән соң Госман радыяллаһу ганһе һәр җомга саен бер кол азат иткән (сатып ала торган булган), барлыгы 2400 кол азат иткәнлеге билгеле.

2. Күп сәхабәләрнең бурычларын кичерә (Талхә радыяллаһу ганһенең генә дә 50 мең дирһәм бурычын кичергән).

3. Үзенә кадәр булган хәлифәләрнең барысына да тугры булырга ант иткән. Әбү Бәкергә, Гомәргә дәүләт белән идарә итәргә ярдәм иткән.

Әбү Бәкернең хәлифәлеге вакытында Мәдинәдә ачлык була. Ризык кытлыгы башлангач, Әбү Бәкер халыкны тынычландырырга тырышып: «Аллаһы Тәгалә безгә бу афәттән чыгу юлын бирми калмас», – дип әйткән. Шул ук төнне Мәдинәгә Госман радыяллаһу ганһенең ризыклар төялгән мең дөялек кәрваны керә. Алыпсатарлар аны чолгап алып, бер дөягә ике дөя бәясен тәкъдим итәләр. Госман радыяллаһу ганһе аларга: «Миңа күбрәк бирүче бар», – дип әйткән. Тегеләр гаҗәпләнгәннәр, сораштырганнар. Госман радыяллаһу ганһе: «Аллаһы Тәгалә», – дип әйткән һәм бөтен кәрванын мөселманнарга бүләк итеп биргән. Шуның белән Мәдинәдә ризык кытлыгы бетә;

4. Мөселманнар Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылганнан соң, Мәдинәдә су кытлыгы башлана. Шул вакыт Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм иң күп сулы кое хуҗасы Бәни Гыйбар гаиләсенә килеп тәкъдим

ясаган. «Бу коегызны җәннәттәге коега алыштырырга теләмисезме?» – дип әйткәч, Бәни Гыйбар: «Бу безнең бердәнбер табыш чыганагыбыз. Әгәр аны сиңа бирсәк, без малсыз калабыз», – дип кире каккан. Госман радыяллаһу ганһе бу хакта ишетеп, Бәни Гыйбар янына килгән, бу коены 35 мең динарга сатып алып, мөселманнарга бүләк иткән. Соңыннан ул Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп: «Йә Расүлуллаһ, син миңа Бәни Гыйбарга вәгъдә кылганны вәгъдә итәсеңме?» – дип сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа җавап итеп: «Әйе», – дип әйткән.

5. Госман бине Гаффән беркайчан да биргән садакалары белән мактанмаган, киресенчә, уң кулы биргәнне сул кулы күрмәсен дип тырышкан. Бервакыт мәчеттә чагында аның янына бер ир бала килә. Госман аның авыр хәлдә булуын аңлап, бу балага күлмәк бүләк итәргә уйлый. Күлмәкне төреп биргәндә, кесәсенә ун мең дирһәм акча сала. Малай өенә кайткач, әти-әнисенә күлмәкне күрсәтә. Бары шул вакытта гына әти-әнисе күлмәк кесәсендә булган акчаны күрәләр.

## Хәзрәти Госман радыяллаһу ганһенең дәрәҗәсе

Госман радыяллаһу ганһе сәхабәләр арасында иң югары дәрәҗәдә була. Аның дәрәҗәсен түбәндәге мисаллардан күрәбез:

1. Өченче тугры хәлифә.

2. Исән чагында ук җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең берсе.

3. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Әбү Бәкер, Гомәр радыяллаһу ганһүмнәрдән соң иң яраткан кешесе.

4. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ике кызына никахланып, «Зин-Нурәйн» («ике нур иясе») исеменә лаек булучы.

5. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм урынына вәкил булып калучы. Хөдәйбия солыхы төзелгән вакытта ул мәккәлеләр янына

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм исеменнән вәкил (илче) булып бара, аларга мөселманнарның теләгген, фикерен белдерә. Мәккәлеләр катгый рәвештә каршы төшеп: «Без моңа риза түгел, әгәр сезне шәһәргә кертсәк, без җиңелүче булабыз. Киләсе елда керерсез», – дип әйтәләр һәм бары тик Госман радыяллаһу ганһегә генә хаҗ кылырга рөхсәт итәләр. Госман бине Гаффән: «Мин Мөхәммәд галәйһиссәламнән башка бернәрсә дә эшләмим», – дип әйткән. Мөшрикләрнең моңа ачулары килеп, алар Госманны төрмәгә ябалар. Ләкин бу хәбәр мөселманнарга башка мәгънәдә, Госманны үтергәннәр икән дип барып ирешә. Шул сәбәпле мөселманнар: «Госман өчен үч алмыйча Мәдинәгә кире кайтмыйбыз», – дип бәйгать бирәләр. Бу вакыйгага бәйле Аллаһы Тәгалә түбәндәге аятьне иңдерә:

لَّقَدْ رَضِيَ اللَّهُ عَنِ الْمُؤْمِنِينَ إِذْ يُبَايِعُونَكَ تَحْتَ الشَّجَرَةِ فَعَلِمَ مَا فِي قُلُوبِهِمْ فَأَنزَلَ السَّكِينَةَ عَلَيْهِمْ وَأَثَابَهُمْ فَتْحًا قَرِيبًا ﴿١٨﴾

**«Сугыштан кайтмыйча, үлгәнче мөшрикләр белән сугышырга, дип агач төбендә сиңа бәйгать бирүче сахабәләрдән Аллаһы, шиксез, разый булды. Аллаһы аларның күңелләрендәге яхшы ниятләрен белде, аларга күңел тынычлыгын бирде һәм тиздән Мәккә фәтех ителәчәк, дип аларны шатландырды».**

«Фәтех / Җиңү», 48:18

## Хәзрәти Госман радыяллаһу ганһенең хәлифәлеге

Госман радыяллаһу ганһе хәлифәлеккә Гомәр радыяллаһу ганһедән соң сайлаулар нәтиҗәсендә килә.

Гомәр разыйаллһу ганһе үзеннән соң төрле фетнәләр килеп чыкмасын өчен хәлифә буларак алты кешене тәкъдим итә һәм алар арасыннан хәлифә сайларсыз, дип васыять итеп калдыра. Алар түбәндәгеләр:

– Гали бине Талиб

– Госман бине Гаффән

– Габдеррахман бине Гавеф

– Зөбәер бине Гаввам

– Сәгыйд бине Әбү Вәккас

– Талхә бине Гобәйдуллаһ.

Халык арасында сайлаулар үткәргәннән соң, Зөбәер бине Гаввам үзенең тавышын Галигә бирә. Талхә радыяллаһу ганһе тавышын Госманга бирә. Сәгыйд бине Әбү Вәккас Габдеррахман бине Гавефка бирә, ләкин ул хәлифә булырга теләми. Халык белән киңәшләшкәннән соң, Габдеррахман бине Гавеф үз тавышын Госманга бирергә карар кыла. Шул рәвешле, күпчелек тавыш белән, бу сайлауларда Госман бине Гаффән җиңеп чыга.

Госман радыяллаһу ганһе хәлифә булганнан соң, тирә-яктагы әмирләргә халыкка карата гадел һәм тугры булырга боерыклар җибәреп, аларга яхшы мөгамәлә күрсәтергә, һәртөрле халык арасында тигезлекне сакларга, ятимнәрне һәм башка диндә булган кешеләрне яклау астына алырга боера.

Ул Ислам мәмләкәте белән Гомәр вакытында булган тәртип белән идарә итә башлый.

Госман үзе дә зур байлардан, оста сәүдәгәрләрдән булганлыгы өчен, аның заманында сәүдә, байлык, тормыш дәрәҗәсе бик нык үсә. Халык арасында төрле кәсеп һәм һөнәр ияләре, сәнгать һәм игенчелеккә әһәмият бирүчеләр арта. Фарсы һәм Рум илләрендә булган бик күп файдалы сәнгать һәм һөнәрләр тарала. Мөселманнар арасында зур байлар, яхшы тормышка әһәмият бирүчеләр, гомумән, ислам дине әһелләре һәм фәкыйрьләр файдасына зур ярдәм күрсәтүчеләр күбәя.

Госман радыяллаһу ганһе яхшылыкка өнди һәм начарлыктан тыя. Ул башкаларга нәсыйхәт биреп кенә калмый, ә үзе дә шул гамәлләрне башкара. Алга таба берничә мисал китереп үтик:

1. Госман радыяллаһу ганһе Мөхәммәд бине Җәгъфар бине Әбү Талибне шәфран белән буялган кием киеп йөрүдән тыя, чөнки Мөхәммәд галәйһиссәлам моны тыйган булган.

2. Гыйддә вакытлары бетми торып, хаҗ кылырга җыенган хатын-кызларны да тәнкыйтьли һәм андыйларга кире кайтырга боерган.

3. Госман ниндидер мәгънәсез гамәл кылган һәм үзе белән корал йөрткән (хәтта таяк булса да) кешеләрне тәнкыйтьләгән һәм андыйларны шәһәрдән куып чыгарган.

4. Бәхәс вакытында Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең абыйсы Әл- Габбас бине Габделмотталибны кимсеткән кешене камчыларга боерган. «Аллаһының Илчесе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм абыйсын хөрмәт иткән һәм мин аны кимсетергә юл куймам! Бу гамәлне кылган һәм моны хуплаган кеше Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә каршы торучы», – дип әйткән.

5. Госман радыяллаһу ганһе шәраб куллануны тыйган, барлык афәтнең башлангычын нәкъ шунда күргән. «Шәрабка якын килмәгез, ул – барлык әшәкелекнең анасы», – дип әйткән.

## Хәзрәти Госман радыяллаһу ганһенең мәшһүр эшләре

1. Госман радыяллаһу ганһе идарә иткән чорда ислам зарарына тырышучы дошманнар белән төрле җирләрдә сугышлар алып барыла һәм ислам мәмләкәтенә кертелә. 28 нче һиҗри елда Төньяк Африка илләре, 30 нчы һиҗри елда Кипр утравы, 31 нче һиҗри елда Византия җирләре, 32 нче һиҗри елда Кавказ илләре.

2. Шулай ук ул идарә иткән чорда Әрмәнстан, Әзербайҗан, Тунис һ.б. дәүләтләр яулап алына.

3. Мөселманнарның беренче тапкыр флотилиясе төзелә (600 көймәлек флот).

4. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе хәлифәлек иткән дәвердә Изге Коръән бер китап булып җыела һәм бу бердәнбер нөсхә була. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе үзе үк бу беренче кулъязманы саклаучы итеп билгеләнә һәм аны үлгәнчегә кадәр үзендә саклый. Аның вафатыннан соң бу нөсхә Гомәр радыяллаһу ганһегә бирелә һәм ул шәһид булып киткәнчегә кадәр анда саклана. Гомәр радыяллаһу ганһе нык яралангач, Коръән кулъязмаларын сакларга кызы Хафсага тапшыра.

Бераз соңрак мөселманнар арасында Коръән уку буенча төрле каршылыклы сораулар туа. Бу хәбәр Хөзәйфә бине Әл-Йәмән исемле сәхабәгә барып җиткәч, ул куркуга кала һәм тизрәк Госман бине Гаффән янына ашыга. Шуннан соң Госман радыяллаһу ганһе мөселманнар арасында төрле фикер каршылыклары, бидгать гамәлләр килеп чыкмасын өчен, Коръән укуның бердәм формасын расларга карар кыла. Ул мөэминнәрнең анасы Хафсадан бер мосхафка туплар өчен Изге Коръәннең кулъязмасын алып тора. Бу мосхаф Зәйд бине Сәбит җитәкләгән Коръән хафизлар төркеме ярдәмендә туплана. Госман бине Гаффән әзер мосхафның җиде күчермәсен ясап, җиде төбәккә тарата (Мәккә, Мәдинә, Куфа, Басра, Йәмән, Мисыр, Шам).

5. Җомга намазына икенче азан әйтүне кертә. Беренче азан халыкны җыю өчен әйтелгән булса, икенче азан харам вакыт кергәнне хәбәр итү өчен әйтелә.

6. Сәхабәләр арасында малы белән иң күп ярдәм итүче, иганәләре белән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне һәм бөтен сәхабәләрне шатландыручы зат та Госман радыяллаһу ганһе була. Ул үз акчасына Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәчете янындагы җирләрне сатып алып, Расүлуллаһның мәчетен зур итеп, бизәкләп төзетә. Мәчетне беренче мәртәбә зиннәтләп төзүче дә ул була.

7. Мәккә шәһәрендәге Харам мәчетен киңәйтә.

8. Мәдинәдә хөкем йорты (дом правосудия) төзетә. Госман радыяллаһу ганһегә кадәр идарә иткән ике хәлифә суд эшләрен мәчеттә генә хәл итә торган булган. Шулай ук ул ислам дәүләтендә беренчеләрдән булып полиция (тәртип саклау) бүлегенә нигез сала.

9. Мөәзиннәргә махсус эш хакын билгели.

## Хәзрәти Госман радыяллаһу ганһенең шәһид булып китүе

Госман радыяллаһу ганһе хәлифәлеге вакытында Ислам дәүләте чәчәк ату чорын кичерә. Халык арасында гыйлем, мәгърифәт, байлык арта. Хәлифә миһербанлы, мөлаем булганга халык та аны ярата. Ислам дәүләте зурая. Шуңа да 80 яшенә җиткән Госман радыяллаһу ганһенең игътибары җитми башлый. Шул сәбәпле, ул идарәгә үзенең якын кардәшләрен кертә, ләкин алар аның ышанычын акламыйлар. Үзләре теләгәнчә, хәлифә рөхсәтеннән башка кайбер гамәлләр кылалар. Бу уңайдан файдаланып, Габдуллаһ бине Сәбәгъ исемле яһүди Мисыр җирләренә барып, халык арасында фетнә чыгара: «Сез ничек уйлыйсыз: Гайсә яхшымы яки Мөхәммәдме?» – дип сорый. Халык: «Әлбәттә, Мөхәммәд», – дип җавап кайтара. «Гали яхшыракмы? Госманны?» – дип сорау куйгач, халык Гали радыяллаһу ганһенең Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм нәселеннән булуын истә тотып: «Гали», – дип җавап кайтарган. Соңыннан ул: «Гали хәлифә булырга хаклырак, ул хәлифә булырга тиеш», – дип халык арасында сүз күтәрә. Аны бер төркем халык хуплап чыга. Шул рәвешле, фетнәчеләр баш калкыта. Алар халыкны хәлифәгә каршы котырталар һәм көч белән хакимиятне буйсындырырга, тартып алырга телиләр. Баш күтәрүчеләргә каршы Госман радыяллаһу ганһе үзе чыга. Аларга ашарга мал җитмидер дип мал бирә һәм кире борып җибәрә. Ләкин фетнәчеләр кире китмичә, Басра җирләренә барып, көч туплыйлар һәм Мәдинәдән халыкның хаҗга киткәнен көтеп торып, хәлифәлеккә һөҗүм итәләр һәм Мәдинәне яулап алалар. Алар, хәтта, Госман бине Гаффән яшәгән

йортны камауга алалар. Аннан хәлифәлекне азат итүен таләп итәләр. Госман радыяллаһу ганһе исә: «Мин ниндидер монафикъларның теләге белән генә Аллаһы Тәгалә һәм Аның илчесе кидергән киемемне салмыйм», – дип әйткән. Үзе янәшәсендә булган ярдәмчеләренә, күп кенә сәхабәләрнең улларына Госман бине Гаффән: «Аллаһы ризалыгы өчен мине саклаудан сезне азат иттем», – дип белдергән. Ләкин алар аның сүзенә колак салмыйлар. Хезмәтчеләре аны якларга ашыга. Госман радыяллаһу ганһе исә: «Миңа буйсынырга тиеш булган һәммәгезгә дә кулларыгыздагы коралларыгызны төшерергә әмер кылам», – дип әйткән. Ул сабырлык кылган, фетнәчеләргә каршы сугыш башламаган, мөселманнарның кан коюларын теләмәгән. Ул барлык сакчыларын, ярдәмчеләрен үз өеннән азат иткән. Алар киткәч, Коръәннең күчермәсен алып, укый башлаган. Шул чагында фетнәчеләрнең берсе (безгә кадәр килеп ирешкән хәбәрләрдә исеме телгә алынмый) өйгә кергән. Аны күреп, Госман радыяллаһу ганһе: «Минем белән синең арада – Аллаһы китабы», – дип әйткән. Ул кеше аңа бернинди дә зарар кылмыйча чыгып киткән. Шуннан соң Әл-Мәүт Әл-Әсвәд (Кара үлем) кушаматлы бер әүкереп, Госман бине Гаффәнны буа башлый, аннан соң кылыч белән суга. Госман сакланыр өчен кулын алга таба сузгач, ул кылычы белән аның кулын өзә. Госман бине Гаффән тын алып: «Бу Коръәннең кечкенә сүрәләрен язган беренче кул», – дип әйтә. Кайчандыр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа әйтеп торып Коръәнне яздырткан булган. Госман радыяллаһу ганһене Коръән укыган чагында ханҗәр белән кадап үтерәләр. Ярасыннан саркыган кан алдында яткан Коръәнгә, Аллаһының түбәндәге сүзләренә тамган:

فَإِنْ آمَنُوا بِمِثْلِ مَا آمَنتُم بِهِ فَقَدِ اهْتَدَوا ۖ وَّإِن تَوَلَّوْا فَإِنَّمَا هُمْ فِي شِقَاقٍ ۖ
فَسَيَكْفِيكَهُمُ اللَّهُ ۚ وَهُوَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ ﴿١٣٧﴾

**«...синә ярдәм бирергә Аллаһы үзе җитәдер. Ул ишетүче һәм белүче».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:137

Шул рәвешле, Госман радыяллаһу ганһе 35 нче һиҗри елда, зөлхиҗҗә аеның 18 нче көнендә, 82 яшендә шәһид булып китә. Җеназа намазын аңа үзенең васыяте буенча Зөбәер бине Гаввам укый.

Мөселманнарның өченче тугры хәлифәсе, күренекле сәхабә, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кияве Госман радыяллаһу ганһенең шәһид булып китәчәген Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм элегрәк үк әйткән булган.

Әнәстән риваять ителә: «Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әбү Бәкер, Гомәр һәм Госман радыяллаһу ганһүмнәр белән бергәләп Өхед тавына күтәрелә. Шул чагында тау селкенеп куйган. Аллаһының Илчесе: «Тынычлан, Өхед! Синдә пәйгамбәр һәм ике шәһид кенә тора», – дип әйткән.

Бу вакыйгалардан соң мөселманнар тормышында зур фетнәләр башлана.

# Зәйнәб бинте Җәхеш

**Исеме:** Зәйнәб бинте Җәхеш (Мөхәммәд галәйһиссәламгә кияүгә чыкканчы Бәрра исемен йөрткән), икенче исеме – Өмме Әл-Хәкәм.

**Туган елы, урыны:** 592 нче елда, һиҗрәткә егерме ел кала Мәккәдә туган.

**Әтисе:** Җәхеш бине Риаб бине Ягъмур Әл-Әсәдий.

**Әнисе:** Өмәймә бинте Габделмотталиб бине Һашим.

**Тормыш иптәше:** Зәйд бине Харис, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм.

## Зәйнәбнең Мәдинәгә һиҗрәте

Мөэминнәрнең анасы Зәйнәб – Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ике туган сеңлесе; Пәйгамбәр галәйһиссәлам – аның апасының (түтәсенең) улы. Алар икесе дә Габделмотталибның оныклары.

Шуны да искә алып китәргә кирәк, туганда аңа Бәрра исеме бирелә. Ләкин тора-бара Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның исемен Зәйнәб итеп үзгәрткән. Аллаһы Тәгалә Зәйнәбне чибәрлек һәм байлык белән бизәгән, ул үзенең игелеклелеге һәм йомшаклыгы белән аерылып торган. Корәеш аксөякләреннән булган һәм Мәккәнең иң мәшһүр хатын-кызларыннан саналган.

Зәйнәб Ислам динен кабул иткәч, мәккәлеләрдән күп рәнҗетү һәм мәсхәрәләү күрә. Ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дәгъваты белән нык илһамлана һәм шуңа да иманында нык торып, туганнары тарафыннан эзәрлекләүләргә дә каршы тора. Ул беренче мөселманнар белән Мәдинәгә һиҗрәт кыла.

## Зәйнәб һәм Зәйд бине Харис

Һиҗрәт кылучылар арасында Зәйд бине Харис та булган. Ул кече яшьтән үк Хәдичә радыяллаһу ганһәнең колы булган. Хәдичә аны Мөхәммәд галәйһиссәламгә бүләк иткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны коллыктан азат итеп, уллыкка алуын, үзенең варисы итеп билгеләвен игълан иткән. Шул рәвешле, аны «Зәйд бине Мөхәммәд» дип йөртә башлыйлар. Коръәннең түбәндәге аяте иңдерелгәч, аңа болай эндәшмәгәннәр:

ادْعُوهُمْ لِآبَائِهِمْ هُوَ أَقْسَطُ عِندَ اللَّهِ ۚ فَإِن لَّمْ تَعْلَمُوا آبَاءَهُمْ فَإِخْوَانُكُمْ فِي
الدِّينِ وَمَوَالِيكُمْ ۚ وَلَيْسَ عَلَيْكُمْ جُنَاحٌ فِيمَا أَخْطَأْتُم بِهِ وَلَٰكِن مَّا تَعَمَّدَتْ
قُلُوبُكُمْ ۚ وَكَانَ اللَّهُ غَفُورًا رَّحِيمًا ﴿٥﴾

**«Тәрбияләр өчен үз гаиләгезгә алган ир балаларга аталарының исеме белән дәшегез, бу эш сезнең өчен Аллаһы хозурында гаделрәктер, әгәр аталарының исемнәрен белмәсәгез, ул балалар – диндә сезнең кардәшләрегездер, ул вакытта кардәшем дип дәшегез...».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:5

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аны бик нык ярата, Зәйд балигълыкка ирешкәч тә, үзе үк аңа Зәйнәбне хатынлыкка сайлый. Зәйнәб башта каршы чыга. Ул: «Аксөяк хатын-кыз колның хатыны булырга тиеш түгел», – дип әйткән. Моңа карата Расүлебез галәйһиссәлам: «Аңа кияүгә чык. Нәкъ менә аны мин сиңа ир итеп сайладым», – дип әйткән. Зәйнәб карар кабул итәр алдыннан Аллаһы Тәгаләдән түбәндәге аять иңгән:

وَمَا كَانَ لِمُؤْمِنٍ وَلَا مُؤْمِنَةٍ إِذَا قَضَى اللَّهُ وَرَسُولُهُ أَمْرًا أَن يَكُونَ لَهُمُ
الْخِيَرَةُ مِنْ أَمْرِهِمْ ۗ وَمَن يَعْصِ اللَّهَ وَرَسُولَهُ فَقَدْ ضَلَّ ضَلَالًا مُّبِينًا ﴿٣٦﴾

**«Әгәр Аллаһы һәм Аның Илчесе сайласалар, мөэмингә дә, мөэминәгә дә ул эштә сайлау булмый. Аллаһыга һәм Аның Илчесенә итагать итмәүче ачык адашуга төшә».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:36

Аллаһының һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең теләгенә буйсынып, Зәйнәб Зәйднең хатыны була. Шулай итеп, сыйнфый тигезсезлеккә карамастан, ирекле хатын белән кол арасында никах укыла.

Өйләнешсәләр дә, Зәйнәб Зәйдне ир итеп кабул итә алмаган. Аңа салкын караган, үзен бик нык тәкәббер тоткан. Ләкин бу никах ул вакыттагы ялгыш күзаллауларны юкка чыгару өчен кирәк була.

Зәйд еш кына үги әтисе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Зәйнәбнең тәкәббер булуын, аны түбәнсетүен сөйләгән. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аңа сабыр булырга, үз башына төшкән сынауга түзәргә киңәш иткән. Ул аңа: «Хатыныңны үз яныңда калдыр һәм Аллаһыдан курык!» – дип әйткән.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм талакның котылгысыз икәнен күреп, һәм үги улларны чын улларга тиңли торган гадәтне бетерү өчен, Зәйнәбне үзенә алырга кирәк булачагын аңлаган. Әмма кешеләрнең «Башкаларны тыйса да, үзе улының хатынына өйләнде», дип сөйләүләреннән куркып, хисләрен беркемгә дә белдермәгән. Соңрак мөселман галимнәре: «Әгәр дә Мөхәммәд галәйһиссәлам Коръәннән берәр нәрсәне яшерергә теләсә, ул түбәндәге аятьне яшерер иде», – дип әйтәчәкләр.

وَإِذْ تَقُولُ لِلَّذِي أَنْعَمَ اللَّهُ عَلَيْهِ وَأَنْعَمْتَ عَلَيْهِ أَمْسِكْ عَلَيْكَ زَوْجَكَ وَاتَّقِ اللَّهَ وَتُخْفِي فِي نَفْسِكَ مَا اللَّهُ مُبْدِيهِ وَتَخْشَى النَّاسَ وَاللَّهُ أَحَقُّ أَن تَخْشَاهُ ۖ فَلَمَّا قَضَىٰ زَيْدٌ مِّنْهَا وَطَرًا زَوَّجْنَاكَهَا لِكَيْ لَا يَكُونَ عَلَى

الْمُؤْمِنِينَ حَرَجٌ فِي أَزْوَاجِ أَدْعِيَائِهِمْ إِذَا قَضَوْا مِنْهُنَّ وَطَرًا ۚ وَكَانَ أَمْرُ اللَّهِ مَفْعُولًا ﴿٣٧﴾

**«Менә син Аллаһы нигъмәт биргән һәм син нигъмәтләндергән кешегә: «Хатыныңны үз яныңда калдыр һәм Аллаһыдан курык!» – дип әйтәсең. Син Аллаһы белгән нәрсәне күңелеңдә яшердең һәм кешеләрдән курыктың. Ә бит Аллаһыдан гына куркырга кирәк. Зәйд аның белән теләген канәгатьләндергәннән соң, үги уллары аерылганнан соң, мөселманнарга шул хатыннарга өйләнүдә авырлык булмасын өчен, Без сине аңа өйләндердек».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:37

Шулай итеп, илаһи тәкъдир өстен чыккан һәм Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм кыенсынмыйча Раббысының боерыгын үтәгән.

## Зәйнәб бинте Җәхешнең Мөхәммәд галәйһиссәлам белән никахы

Зәйнәбнең гыйддә вакыты тәмамлангач, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам Зәйдкә Зәйнәб янына барып, аны үзенә яучыларга боерган. Зәйд ул кушканны үтәгән. Зәйнәб тәкъдимгә: «Раббым миңа боермыйча, мин бернәрсә дә эшләргә җыенмыйм», – дип җавап биргән. Шуннан соң, үзе өчен нәрсә яхшырак булуын сорап, истихара намазы укый башлаган. Әлеге намазга җавап булып югарыда әйтелгән аять иңгән.

Шуннан соң Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Зәйнәбне хатынлыкка алган. Киләчәктә Зәйнәб Пәйгамбәр галәйһиссәламнең башка хатыннары алдында: «Сезне аталарыгыз кияүгә бирсә, мине җиде кат күк биеклегеннән Аллаһы Үзе кияүгә бирде», – дип сөйләгән.

Зәйнәб Аллаһының боерыгын үтәүнең мисалы булып тора. Күргәнебезчә, ул башта барлык кешеләрнең дә тигез икәннәрен раслау өчен колның хатыны булган, ә хәзер Пәйгамбәр галәйһиссәләмгә кияүгә чыккан.

Туй 5 нче һиҗри елда уза. Бу вакытта Зәйнәбкә 35 яшь булган. Бу вакыйга уңаеннан зур мәҗлес оештырылган. Әнәс бине Мәликнең әнисе Өмме Сүләйм бинте Милхән туй сые әзерләгән. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әнәс радыяллаһу ганһегә: «Әбү Бәкерне, Гомәр, Госман һәм Галине бирегә чакыр. Мәчеттә булган һәм юлыңда очраган һәркемне дә монда чакыр», – дип әйткән. Әнәс моңа гаҗәпләнгән, ул шулчаклы кешегә ризык җитмәс, дип бик борчылган. Кешеләр төркем-төркем булып, Мөхәммәд галәйһиссәламнең йортына агылганнар. Барлык халык җыелып беткәч, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм табынга ризык тулы савытны куйган вә Аллаһы Тәгаләдән бу ризыкның бәрәкәтен сораган һәм кунакларга: «Өстәл янына унышарлап утырыгыз һәм алдыгызда булган ризыклардан сыйланыгыз», – дип әйткән. Әнәс радыяллаһу ганһе: «Барлык килгән кеше дә тамаклары туйганчы ризыкланды. Алар ашаган саен ризык арткан кебек тоелды», – дип әйткән. Ул бу хәлләрне әнисенә кайтып та сөйләгән. Әнисе аңа: «Гаҗәпләнмә. Аллаһы Тәгалә барлык мәккәлеләрнең бу ризыктан авыз итүләрен теләсә, барысы да ашарлар һәм тукланырлар иде», – дип әйткән. Бу – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер могҗизасы булган.

Туй мәҗлесенә чакырылган кунаклар киткәч, өч кеше әңгәмәгә бирелеп, өйдә калганнар. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларның китүләрен көтә, бүлмәдә йөри башлый. Тегеләр исә аның нишләп болай йөргәнлеген аңламаганнар. Шуннан соң ул үзенең хатыннары бүлмәләрен әйләнеп чыгарга теләгән, шул рәвешле, ул вакытка бу кешеләр чыгып китәрләр дип, уйлаган. Шушы хәлдән соң Коръәннең түбәндәге аяте иңгән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تَدْخُلُوا بُيُوتَ النَّبِيِّ إِلَّا أَن يُؤْذَنَ لَكُمْ إِلَىٰ طَعَامٍ غَيْرَ
نَاظِرِينَ إِنَاهُ وَلَٰكِنْ إِذَا دُعِيتُمْ فَادْخُلُوا فَإِذَا طَعِمْتُمْ فَانتَشِرُوا وَلَا مُسْتَأْنِسِينَ
لِحَدِيثٍ ۚ إِنَّ ذَٰلِكُمْ كَانَ يُؤْذِي النَّبِيَّ فَيَسْتَحْيِي مِنكُمْ ۖ وَاللَّهُ لَا يَسْتَحْيِي
مِنَ الْحَقِّ ۚ وَإِذَا سَأَلْتُمُوهُنَّ مَتَاعًا فَاسْأَلُوهُنَّ مِن وَرَاءِ حِجَابٍ ۚ ذَٰلِكُمْ أَطْهَرُ
لِقُلُوبِكُمْ وَقُلُوبِهِنَّ ۚ وَمَا كَانَ لَكُمْ أَن تُؤْذُوا رَسُولَ اللَّهِ وَلَا أَن تَنكِحُوا
أَزْوَاجَهُ مِن بَعْدِهِ أَبَدًا ۚ إِنَّ ذَٰلِكُمْ كَانَ عِندَ اللَّهِ عَظِيمًا ﴿٥٣﴾

**«Ий мөэминнәр, Пәйгамбәр галәйһиссәлам өйләренә аш мәҗлесенә барганда, ашның өлгергәнен көтеп тормыйча, рөхсәтсез кермәгез. «Керегез», дип чакырылсагыз, керегез, ашап-эчеп тәмам булгач китегез. Бер-берегезнең хәлләрен сорашып, озак вакыт утырмагыз, сезнең шулай озак утыруыгыз Пәйгамбәрне борчыйдыр, ул сезгә инде кайтыгыз дип әйтергә ояладыр, әмма Аллаһы хакны әйтергә оялмыйдыр. Әгәр Пәйгамбәр хатыннарыннан бернәрсә сорасагыз, пәрдә аркылы сорагыз, әнә шулай соравыгыз сезнең күңелләрегезгә дә, аларның күңелләренә дә пакьлектер. Сезгә Пәйгамбәрне бернәрсә белән рәнҗетү лаек булмады, шулай ук, Пәйгамбәрнең хатыннары үзеннән соң сезгә мәңге хәләл булмады. Дөреслектә, Пәйгамбәрне рәнҗетү, вә аның хатыннарына никахлану –Аллаһы хозурында сезгә бик олугъ гөнаһ эш булды».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:53

Бу вакыйгадан соң Пәйгамбәр галәйһиссәлам йортында, мөэминнәрнең аналарын – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хатыннарын – чит-ят күзләрдән саклар өчен, пәрдәләр эленгән.

Зәйнәб радыяллаһу ганһә күп вакытларын гыйбадәттә уздырган. Бик күп өстәмә намазлар кылган һәм уразалар тоткан.

Бервакыт Пәйгамбәребез галәйһиссәлам мәчеттә эленеп торган бер бауны күреп ала: «Бу нәрсә?» – дип сорый. Сәхабәләр: «Бу Зәйнәб ананыкы», – дип җавап биргәннәр һәм намазларын укыганда басып торып аяклары арыгач, аның шушы бауга тотынуын әйткәннәр. Бу хәл Пәйгамбәр галәйһиссәламгә ошамаган һәм ул: «Гыйбадәт кылып, үзеңне шулай бимазаларга ярамый. Бу бауны сүтеп алыгыз. Намаз укырга хәлегез булганда гыйбадәтләрегезне кылыгыз», – дип әйткән.

Зәйнәб радыяллаһу ганһә Пәйгамбәр галәйһиссәлам йортына аның хатыны булып килеп керә һәм бу исә аның дәрәҗәсен күтәрә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны хөрмәт итә һәм мөэминнәрнең анасы Гайшә радыяллаһу ганһә: «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең барлык хатыннары арасында Зәйнәб кенә минем белән бер дәрәҗәдә иде», – дип әйткән.

Зәйнәб бинте Җәхеш тугры, һәркемнең дә хакларын хаклап, дөреслек яклы булган. Шулай бервакыт Гайшә радыяллаһу ганһәгә яла ягалар. Пәйгамбәр галәйһиссәлам бу турыда Гомәр, Госман, Гали радыяллаһу ганһүмнәрдән сораштыра. Ул Зәйнәб радыяллаһу ганһәдән дә бу хакта сорагач, Зәйнәб: «Әй Аллаһының Илчесе, мин күзләремне һәм колакларымны үзем күрмәгән һәрнәрсәдән саклыйм. Аллаһы белән ант итәм, Гайшә турында яхшыдан кала мин бернәрсә дә әйтә алмыйм», – дип җавап биргән.

Иренең үрнәгенә ияреп, Зәйнәб юмарт һәм тыйнак була. Шулай көннәрнең берендә Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләм барлык хатыннары барында: «Миннән соң сезнең иң озын куллыгыз миңа ияреәчәк», – дип әйткән. Пәйгамбәр галәйһиссәламнән соң беренче булып Зәйнәб бинте Җәхеш үлгән. Шул вакытта Пәйгамбәр хатыннары аның «иң озын куллы» (юмарт) булуын белгәннәр, чөнки Зәйнәб кул эшләрен

яратып башкарган (тире эшкәрткән, күннән киемнәр теккән, дисбеләр ясаган) һәм ярлыларга шул малдан садакалар тараткан. Бу гамәлләрен ул барысын да Аллаһы ризалыгын өмет итеп башкарган. Өмме Сәләмә Зәйнәбнең үлеменнән соң: «Зәйнәб бик тугры хатын иде. Бик еш уразалар тотты һәм бик күп кул эшләре белән шөгыльләнде һәм шул рәвешле эшләп тапкан акчасын ярлыларга таратты», – дип әйткән.

Бервакыт Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһегә: «Дөреслектә, Зәйнәб бинте Җәхеш – Аллаһы Тәгаләгә буйсынучан!» – дип әйткән. Гомәр бине Хаттаб: «Бу нәрсәдә чагыла соң?» – дип сорагач, Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Зәйнәб – тугры хатын, Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылуда тыйнаклык күрсәтә», – дип әйткән һәм түбәндәге аятьне дә өстәгән:

إِنَّ إِبْرَاهِيمَ لَحَلِيمٌ أَوَّاهٌ مُّنِيبٌ ﴿٧٥﴾

**«Дөреслектә, Ибраһим шәфкатьле вә Аллаһыдан куркып аһ-ваһ итүче һәм тәүбә белән Аллаһыга кайтучы».**

«Һуд», 11:75

Зәйнәб Пәйгамбәр галәйһиссәлам белән сугышларда катнашкан, Хәйбәрне яулап алуның шаһите булган. Шулай ук ул Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең башка хатыннары белән бергәлектә Саубуллашу хаҗында катнашкан. Әлеге хаҗ вакытында Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенең хатыннарына: «(Сез хаҗ кыласыз) бары тик бу юлы гына. Киләчәктә сез өйләрегездә калырга тиешсез», – дип боерган. Бу боерыкны Сәүдә бинте Зәмга һәм Зәйнәб бинте Җәхештән кала барлык хатыннары да бозган. Шуңа күрә, Зәйнәб башка беркайчан да хаҗга бармаган.

## Пәйгамбәр галәйһиссәламнең вафатыннан соңгы тормышы

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң, ул үз өендә калып, калган гомерен Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылуга багышлаган. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе хәлифә булган вакытта, аны мөэминнәрнең анасы буларак хөрмәт итеп, төрлечә кайгырткан. Аннан соң булган хәлифә – Гомәр бине Хаттаб үзеннән алдарак булган хәлифәнең күркәм гадәтен дәвам итеп, Пәйгамбәр галәйһиссәламнең һәрбер хатынына ел саен 12 мең дирһәм түләү билгеле. Зәйнәб үзенә тиешле түләүләрне алгач та, тиз арада ятимнәргә, ярлыларга, фәкыйрьләргә тарата.

Зәйнәб бинте Җәхеш тәкъва, нык иманлы булган. Аның күркәм сыйфатлары турында Гайшә радыяллаһу ганһә: «Мин Зәйнәбтән дә тәкъварак, гаделрәк, туганлыкны ныграк саклаучы, садака таратуда аяусызрак кеше күрмәдем. Шулай итеп, ул Аллаһы Тәгаләгә якынлаша иде», – дип әйткән.

Һиҗри белән егерменче елда Зәйнәб авырый башлый, гомеренең соңгы көннәре якынлашканын сизенә. Үлем түшәгендә яткан чагында ул: «Мин үземә кәфенлек әзерләп куйдым инде. Мөэминнәрнең әмире Гомәр дә миңа кәфенлек җибәрәчәк. Аның берсен садака итеп бирегез. Әгәр дә изарымны садака итеп бирә алсагыз, аны да бирегез», – дип әйткән.

Зәйнәб бинте Җәхеш һиҗри белән егерменче елда 53 яшендә Мәдинәдә вафат була. Җеназа намазын аңа Гомәр бине Хаттаб укый. Аны Җәннәт әл-Бакыйгъ зиратына күмәләр.

# Фән

# Заһир Әр-Ривайә – Надир Әр-Ривайә

Имам Мөхәммәднең[1] «Заһир Әр-Ривайә» исеме астында билгеле булган хезмәтләре түбәндәге алты китаптан тора:

– «Әл-Асыл» («Әл-Мәбсут»);

– «Әз-Зиядәт»;

– «Әл-Җәмигъ әс-сагыйр»;

– « Әл-Җәмигъ әл-кәбир»;

– «Әс-Сийәр әс-сагыйр»;

– «Әс-Сийәр әл-кәбир».

Бу китапларның кайберләрен имам Мөхәммәд үзенең остазы Әбү Йосыф белән фикерләшеп, ә кайберләрен аның катнашында төзегән. Атамасында «кәбир» сүзе булган китаплар – аның тарафыннан, ә «сагыйр» сүзе булганнар Әбү Йосыф белән берлектә язылган, дип хәбәр ителә.

Әлеге алты китапның «Заһир Әр-Ривайә» дигән гомуми исем астында булуының сәбәбе – имам Мөхәммәд тарафыннан башкаларга билгеле булган юл белән тапшырылуында. Хәнәфи мәзһәбендә алар төп чыганаклар булып торалар. Бу китапларда чагылган карашлар җитди сәбәпләрсез кире кагыла алмый. Имам Мөхәммәднең мондый дәрәҗәдәге тагын ике китабы бар:

– «Әл-Хөҗҗа галә әһлил-Мәдинә»;

– «Китаб әл-әсәр».

«Заһир Әр-Ривайә» дип саналырлык тагын бер китап – «Әл-Мүвәттә». Ул имам Мөхәммәд тарафыннан имам Мәликтән тапшырылган. Бу китапның күп өлешендә хәдисләр булганлыктан, ул фикһ китаплары арасында телгә алынмый, ләкин анда фикһ буенча күп кенә иҗтиһадлар бар. «Ихтиләфү Әбү Хәнифә вә Ибне Әби Ләйлә» һәм «Әр-Радәгъ» китапларына килгәндә, галимнәр арасында аларны бу атама

[1] Имам Мөхәммәд бине Хәсән бине Фәркад Әш-Шәйбани – Әбү Хәнифә һәм Әбү Йосыфның укучысы

астына кертмәгәннәре һәм «Надир Әр-Ривайә» дип санаучылары да бар. Шулай ук имам Мөхәммәднеке булуы мөмкин дип фаразланган башка хезмәтләр дә бар. Аларны «Надир Әр-Ривайә» дип атыйлар. Аларның ни өчен шулай аталуларына төгәл мәгълүмат булмаса да, Ибне Габидин, Әбү Заһра һәм башкалар бу китапларның сирәк очрый торган (надир) алымнар белән тапшырылуларын әйткәннәр. Без исә моңа өстәп, ул китаплар «Заһир Әр-Ривайә» китаплары кебек гомуми дәресләр нәтиҗәсендә һәм күп укучылар тарафыннан тапшырылмаганнар, ә имам Мөхәммәдтән шәхси дәресләр тыңлап, шул рәвешле аерым шәхесләр тарафыннан язылганнар, дип уйлыйбыз.

Бу түбәндәге китаплар:

– «Әл-Кайсанийят»;

– «Әл-Харунийят»;

– «Әл-Җүрҗәнийят»;

– «Әр-Раккийят»;

– «Зиядәт әз-зиядәт»;

– «Әл-Мәхариҗ» фил-һиләл».

Мөхәммәд Заһид Әл-Кәүсәри үзенең «Булугъ әл-Әмәни» китабында болай язган: «Имам Мөхәммәднең китаплары башка мәзһәб вәкилләре тарафыннан төзелгән бик күп китапларга ярдәмлек булып торалар. Башка мәзһәбләр буенча язылган китаплар имам Мөхәммәднең китапларын ачык рәвештә үзләренә чыганак һәм үрнәк итеп алалар, моны яшерү мөмкин түгел. Мәлики мәзһәбендәге «Мүдәввәнә» китабының нигезе булган «Әсәдийә» китабы, авторы Әсәд бине Әл-Фуратның имам Мөхәммәд дәресләрен тыңлап, аның китапларын куллану нәтиҗәсендә дөнья күргән».

Санап үтелгәннәрдән тыш та имам Мөхәммәднең бик күп китаплары бар. Имам Мөхәммәднең (аңа Аллаһының рәхмәте булсын) хәнәфи мәзһәбенә икенче нигез салучы булуында бернинди шик юк. Хәнәфиләр

аның китапларына зур ышаныч белән караганнар һәм төрле сораулар-да ул китапларга таяна алганнар. Аның китаплары хәнәфи мәзһәбенең аңлатмачылары ролен уйнаганнар.

Әл-Кәүсәри хәнәфи мәзһәбе буенча фәтвалар чыгаручылар-га галимнәрнең биографияләре һәм китаплары белән танышуның мөһимлеген һәрдаим ассызыклый. Бу уңайдан әлеге темага бәйле бер мәкаләнең тәрҗемәсен бирүне мәслихәт күрәбез[1].

Мөхәммәд Заһид Әл-Кәүсәри (аңа Аллаһының рәхмәте булсын) болоай дип әйтә: «Имам Суфьян бине Сәед (аңа Аллаһының рәхмәте булсын) үзе яшәгән вакытта бик күп мөхәддисләр булган, дигән сүзне ишеткәч: «Әгәр корабта диңгезчеләр саны кирәгеннән артык булса, кораб батачак», – дип әйткән». Син шул ук сүзләрне бүгенге көндә мөфтиләрнең күплегенә бәйле әйтә аласың.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән дини гыйлемнәр алган һәм Коръәннең иңүенә шаһит булган сәхабәләр фәтвалар бирүдән ерак торганнар. Кайберәүләре дөрес булмаган җавап бирүдән сакланып, үзләренә бирелгән сораулар белән бүтән берәүгә җибәргәннәр. Мөслимнең «Сахих»ында китерелә: бервакыт Әбү Әл-Минхәл Зәед бине Әкрамнан акчага бәйле чыгымнар турында сорый. Аңа җавап итеп Зәед бине Әкрам: «Әл-Бәра бине Газибтән сора», – дип әйтә. Әл-Бәрага шул сорау белән мөрәҗәгать иткәч, ул исә бу турыда Зәедтән сорарга киңәш иткән[2].

«Әл-Мөхәддис әл-Фасыл» китабының авторы Әбү Мөхәммәд Әр-Рамәһүрмузи Габдеррахман бине Әбү Ләйлнең түбәндәге сүзләрен җиткергән: «Мин бу мәчеттә йөз егерме әнсар белән таныштым. Аларның берсе дә хәдис тапшырырга теләмәде. Аларның һәрберсе кардәше бу

1 «Айдын Ташның «Muhammed b. el-Hasan eş-Şeybânî'nin Hukuk Anlayışı» докторлык диссертациясе (Төркия, Әрҗиес университетының Социаль фәннәр институты) материаллары кулланылды.

2 Мөслим, «Китап әл-Мусакат», 4156 хәдис

гамәлне яхшырак башкарыр дип уйлады. Шулай ук бирелгән сорауга үз иптәшләре арасыннан берәрсе дөрес фәтва бирер дип өметләнде.

Шулай ук Рамәһүрмузи түбәндәгеләрне тапшырган: «Әш-Шәгъбидән берәү «ниндидер сорау биргәч алар үзләрен ничек тотканнар?» дип кызыксынган. Ул җавап итеп: «Син бу хакта яхшы белгән кешегә туры килдең. Әгәр берәүгә сорау бирсәләр, ул бу турыда үз иптәшләренең берсеннән фәтва чыгаруын сораган. Тегесе үз чиратында аны икенче берәүгә җибәргән. Бу хәл сорау беренче булып бирелгән кешегә әйләнеп кайтканчыга хәтле дәвам иткән».

Бер күренекле имам: «Әгәр минем Аллаһы каршында белемем югалыр дигән куркуым булмаса, мин беркемгә дә фәтва бирмәс идем. Фәтва алган кеше үз үтенеченең үтәлүеннән канәгатьлек ала, ә моның өчен җаваплылык минем иңнәремдә кала», – дип әйткән.

Әгәр элгәреләр белемнәрне яшерүнең гөнаһыннан курыкмасалар, алар бер тапкыр да фәтва бирергә тырышмаслар иде. Элегрәк чорларда кешеләр биргән фәтвалары өчен җаваплылыктан курыкканнар һәм моңа бәйле күп кенә риваятьләр дә бар. Ләкин без бу хәлнең киресен күрәбез, хәзерге заман кешеләре фәтва чыгаруда ярышалар һәм моның өчен үзләренә җаваплылык алырга ашыкмыйлар. Мөселман илләрендә кайбер мәсьәләләр буенча фәтвалар китермәгән бер генә дини басма да юк. Һәм шул рәвешле үк, мәзһәб тотмаучыларның да, үз эченә гакыйдә һәм гамәли сорауларга бәйле уйлап чыгарылган фәтвалар кермәгән бер генә үгет-нәсыйхәт җыентыгы да юк. Хәтта иң гади генә бер автор да авыр һәм җентекле мәсьәләләр буенча фәтва бирергә тарсынмый. Ул өстәмә бернәрсә дә өйрәнеп тормыйча, бары тик үзенең кулында булган Фәрәҗулла Әл-Курдистани һәм Әш-Шәех Әл-Хәрраниның (Ибне Тәймия) фәтвалар җыентыкларын куллану белән генә чикләнәчәк. Мисал өчен, әлеге фәтва җыентыкларыннан талик әт-талакка бәйле ике бит өземтәләр китереп, ул китаплардагы фәтваларны газета һәм журналларда бастыра-

чак. Өстәвенә, әлеге китапларны нәшер итүченең ышанычлы булу-булмавын, хезмәтнең асыл нөсхәсенә үз ихтыяры белән яки үз нәфесенә буйсынып «төзәтүләр» кертү-кертмәү мәсьәләсен тикшермичә бастырып чыгарачак. Шулай ук ул китапта урын алган автор фикеренең дөреслеккә туры килүен, сүзләре хакыйкатькә никадәр якын, алар, гомумән, җәмәгать карашларыннан никадәр аерылуын тикшерүне дә кирәк дип тапмый.

Дини мәсьәләләр шулчаклы киңкырлы, аларны тикшергәндә, хәтта, күренекле галимнәр дә хата җибәргәннәр. Бу өлкәгә яңа гына килүчеләрнең, әлбәттә, хаталары булачак. Шуның нәтиҗәсендә, билгеле бер сорау буенча төрле чыганаклардан алынган бер-берсеннән аерылып торган фәтвалар милли кыйммәтләр бөтенлеген югалтуга, хәтта, кешеләр күңеленнән чыгарылган фәтваларга карата ихтирам, шәригать кануннарын олылау һәм галимнәргә булган хөрмәт хисе югалуга китерә. Ә нәтиҗәдә болар барысы да өммәтнең дини яктан йомшаруын аңлатачак. Көнчыгыш һәм көнбатышта мөселманнар бу дәвамлы тәртипсезлекләрне (анархияне) күргәч, аларның күңелләрендә Мисыр галимнәре берлегенә карата булган хөрмәт, ышаныч, ихтирам хисе югалачак.

Галимнәр турында алар бер-берсен яратучы һәм ярдәм итүче кардәшләр буласы урынга, киресенчә, бер-берсен тәнкыйтьләү һәм гаепләүдән кала бернәрсә белән дә шөгыльләнмиләр, дигән сүзләрне ишетү бик тә күңелсез хәл. Мөселманнарны кечкенә төркемнәргә бүлүгә каршы торган берлек хакына хезмәт итәсе урынга, бу галимнәр кул кушырып утырудан һәм хезмәт хакы алудан кала бернәрсә дә эшләмиләр яки һәрбер очраган артыннан тыңлаучан гына баралар.

Аллаһы Тәгаләгә яхшы билгеле, үз заманының факиһлары арасында әйдәп баручылардан булган шәех Мөхәммәд Бахит (аңа Аллаһының рәхмәте булсын) вафатыннан соң, Мисыр дәүләте фәнни абруен һәм чит илләрнең безгә карата булган хөрмәтне югалта. Казыйлар һәм галимнәр кыенлыкларны хәл итәргә өметләнеп, аңа мөрәҗәгать итә торган булган-

нар. Аңа нинди генә казый, йә факиһ үзен борчыган мәсьәләләр белән мөрәҗәгать итмәсен, ул шунда ук соравына үз мәзһәбенә ярашлы җавап алган. Нәтиҗәдә, казый аннан алынган карар буенча хөкем иткән, ә кешеләр аның фәтвасын үтәгәннәр. Мәзһәбләр фикһы буенча киңкырлы тикшеренүләр алып баруы, дәвамлы казыйлык һәм бай укыту тәҗрибәсе булганлыктан, ул берәр нәрсәне гамәлдән чыгарса, аны гомерлеккә һәм тулаем чыгарган, әгәр инде берәр кагыйдәне кертсә, барлык кешеләрне дә тулаем ышандыра алырлык дәлилләр китергән. Барлык казыйлар һәм мөфтиләр фикере буенча, әлеге дөньякүләм танылган галим бик югары дәрәҗә тоткан.

Мин шәехкә бик еш мөрәҗәгать иткән бер күренекле казыйны беләм. Фикһ буенча тирән белемле булуына карамастан, ул үзе авыр дип санаган темалар буенча аннан киңәшләр сорап мөрәҗәгать иткән. Үз уй-фикерләрен ныгыту максатыннан, фикһ китапларында очраган теге яки бу гыйбарәгә карата аның фикерләрен дә белгән. Шәйх Бахит вафатыннан соң, шул ук казый, гадәтенчә, хөкем карары буенча Мисырга мөрәҗәгать иткән (карар Мисырдан читтә чыгарылырга тиеш булган). Эш буенча хөкем чыгаруны ул үз соравына җавап алганчыга хәтле кичектергән. Ни кызганыч, аңа җавапны бер, ике, өч ай көтәргә туры килгән. Ислам дөньясында шул рәвешле абруй казанып буламы?

Без мондый вакыйганың шаһитлары булган идек. Фәтвалар чыгара торган инстанция тикшерелә торган мәсьәлә буенча фикер каршылыкларын җентекләп өйрәнергә, барлык дәлилләрне тупларга, бу сорау буенча әйтелгән шәхси фикерләрне дә карарга тиеш. Ә бу инстанция алдарак искә алынган фәтвалар китапларына ышанып, көчсезлек күрсәтеп, җәмгыятьнең бердәм фикеренә каршы килеп бу фәтваны чыгарган. Хәзер исә бу карарны күп кенә сәхабәләр, табигыйннәр һәм элекке буын факиһларныкы дип уйлыйлар. Чынлыкта исә, күпчелек сәхабәләр һәм табигыйннәр ягыннан бу карар файдасына бернинди төпле күрсәтмәләр

булу түгел, хәтта, бер генә булса да сәхабә, табигыйн яки элекке буын факиһ авызыннан чыккан бер сүз дә юк. Бу хәтта шундый сорау ки, аның буенча буыннан-буынга абруйлы галимнәрнең бердәм фикере (иҗмагъ) урнашкан.

Асылда, бу сорау түбәндәгедән гыйбарәт. 5 нче һиҗри елда Ибне Хәзем тиешле җентеклелек күрсәтмичә, Гали радыяллаһу ганһенең көч куллану һәм мәҗбүриләү нәтиҗәсендәге бер вакыйга сәбәпле чыгарган карарын «мәҗбүриләүсез үзеңнең антыңны бозма»[1] дигән кагыйдәгә әйләндергән. Тагын моңа охшаш гамәлне ул Тавустан риваять иткәндә кыла, тапшырган вакытта ялганга бара. Шул рәвешле ул карардагы Шурайх тарафыннан әйтелгән сүзләрнең мәгънәләрен боза. Риваятьтәге «ул моны бидгать дип санамады»[2] дигән гыйбарә, әгәр Шурайх талакны билгеле бер шартлар белән бәйләгән кешенең гамәлләрен бидгать дип санаса, ул аерылу файдасына хөкем итәчәген күрсәтә.

---

1 Гали радыяллаһу ганһе янына бер кешене китергәннәр. Ул бу рәвешле: «Мине походка чыкканчы (тынычлыкта) калдырыгыз, әгәр мин бер ай эчендә хатынымның чыгымнары өчен акча җибәрмәсәм, ул үзен аерылган санасын», дип ант итәргә мәҗбүр булганлыктан, аннан хатыны белән аерылуны таләп иткәннәр. Ләкин ул антында тормаган. Гали радыяллаһу ганһе бу кешенең хәленә кереп һәм дә аның бу эшкә мәҗбүр ителгәнен аңлап, аңа хатынын кире кайтарган. Шуннан соң бу кешене үзе янына китергән кешеләргә карата ул өстәрәк китерелгән фразаны кулланган. Моннан ачык күренә, әгәр мәҗбүр итү булмаса, ул ир белән хатынның аерылулары файдасына карар чыгарган булыр иде һәм һиҗри белән V гасырга кадәр моны шулай аңлаганнар да. Ләкин Ибне Хәзм хаталык кылган һәм Гали радыяллаһу ганһенең карарыннан кагыйдә чыгарган: мәҗбүриләү булса, йә булмаса да талак әйтелгәннән соң аерылуның срогын кичектерү антны бозуга тиң, шуңа да антны бозган очрактагы кебек кәффарәт кылырга кирәк (Билгеле, бу мәҗбүриләп аерылуның дөрес түгеллегенә нигезләнә. Күп галимнәр әлеге фикергә таянсалар да, хәнәфи мәзһәбе башка фикергә таяна. Аларның фикере буенча, мәҗбүр итү нәтиҗәсендә булган аерылу шулай ук дөрес дип санала.

2 Габдерразакның «Мосаннаф»ында Ибне Сириннең бер хикәяте китерелә: «Казый Шурайх хөкеменә бер кешене китерәләр. Ул бер бидгать кылса, хатыны белән аерылачагын хәбәр итә. Шуннан соң ул кемнәндер вакытлыча гына качыр ала һәм аңа атланып Хәббән Гайан дигән җиргә бара. Шуннан соң ул качырны Исбаһәнгә китерә, аны сатып, ул акчага шәраб эчә. Шурайхтан: «Хатыны аерылган булып саналамы әллә юкмы?» – дип сорыйлар. Шурайх: «Әгәр теләсәгез, ул хатынынннан аерылган дип шаһитлек китерә аласыз», – дип әйткән. Шаһит булырга теләмичә алар берничә мәртәбә шул ук сорауны биргәннәр. Шурайх һәрвакыт бертөрле җавап кайтарган (ягъни бу кешенең гамәлен бидгатькә санамаган, 6/388)».

Ибне Гомәрнең фәтвасы, Галинең «Сез кешегә карата көч кулландыгыз», дигән карары, Ибне Мәсгуднең фикерләре, Әбү Зәрра һәм Әз-Зөбәернең гамәлләре, Габдерразак һәм Ибне Әби Шәйбәнең «Мосаннаф»ларындагы, Сәгыйт бине Мансур һәм Бәйһакыйның «Сунан»нарындагы, Ибне Габделбаррның «Тәмхид»ендәге һәм башка китаплардагы фәтвалар – болар барысы да заһиритларга һәм бу сорау буенча ялгыш фикерлеләргә каршы шаһитлык бирә.

Бары тик әлеге һәм аларга охшаш китаплар гына сәхабәләрнең һәм табигыйннәрнең фикерләрен чагылдырган ышанычлы чыганаклар булып торалар. Шул сәбәпле, әгәр берәү бу китаплар белән таныш булмыйча, ниндидер бер фикерне сәхабә яки табигыйнгә бәйле караса, үзен галимнәр даирәсе алдында көлке хәлгә калдыра һәм алар ягыннан һәртөрле хөрмәтне югалта.

Әйтик, күз алдына китерик, галимнәрнең берәрсе, авторны бәхәскә тартып, болай дип әйтте ди: «Монда әйтелгәннәр фәлән вакытта фәлән номер астында чыккан канун түгел, ә өммәтнең танылган имаммөҗтәһидләре чыгарган шәригать карары! Әгәр шушы мәсьәлә буенча һичшиксез сәхабәләрне яки табигыйннәрне искә алырга кирәк булса, ул чагында, сөннәт китапларының берәрсендә бу мәсьәләгә карата яхшырак фикернең дөреслеген раслаган бер генә булса да сәхабәнең яки табигыйннең ышанычлы риваяте барлыгын раслагыз! Чөнки Аллаһы Тәгалә бу мәсьәлә буенча сәхабәләрдән, табигыйннәрдән яки соңгырак факиһлардан тапшырылган нинди дә булса риваятьне китерергә сезне мәҗбүр итми. Ибне Әл-Мунзирдә һәм башка китапларда теркәлгән, иҗмагъка каршы килгән карашны яклаган өчен сине Аллаһы Тәгалә генә түгел, ә кешеләр дә кичерә алырлык булсын». Бу очракта автор нәрсә әйтә алыр иде? Ул хакыйкатьне кабул итеп, фәтвасыннан баш тартыр идеме, югыйсә, ялгыш карашында нык торып, тагын да баткаклыкка чумуын дәвам итәр идеме. Нәрсә эшли ала ул?

Мустафти, ягъни фәтва алучы ике халәтнең берсен сайлый: йә ул әһле-сөннәт тарафыннан танылган имамнарның берсенә иярә, йә мәзһәбне кабул итмәүчеләрнең берсе була.

Әгәр мустафти әһле-сөннәт тарафынан танылган берәр имам артыннан ияреп, мисалга, йә шәфигый яки мәлики булса, аңа фикер каршылыкларын әйтми генә, үз мәзһәбендәге бердәнбер кабул ителгән фикергә бәйле фәтва бирелә. Шунысы ачык, фәтва биреләчәк сораугa карата төрле карашлар әйтелсә, шик-шөбһәләрдән кала бу бернәрсәгә дә илтми. Фәтва кешедәге шикләрне арттыру өчен түгел, ә, киресенчә, аны шул шикләрдән коткарыр өчен бирелә. Мәзһәб имамнары «Рәсм әл-Мөфти» һәм «Әдәп әл-Каза» китапларында бу темага кагылып үтәләр.

Шуңа да үзеннән фәтва сораган кешегә, мисалга, мөфтинең: «Имам Шәфигыйның (аңа Аллаһының рәхмәте булсын) бу сораугa карата ике фикере бар. Аның элекке фикере буенча болай, ә соңрак әйтелгән сүзе буенча менә болай», – дип әйтүе кабул ителми. Йә булмаса мондый җавабы: «Бу мәсьәлә буенча имам Мәликтән алты риваять китерелә. Аларны Ибне Әл-Касыйм, Ашхаб, Ибне Әл-Мәҗишун, Әл-Ләйси, Габделмәлик бине Хәбиб һәм Әл-Готби тапшырган». Йә монысы: «Хәнәфи мәзһәбендә бу темага карата «Заһир Әр-Ривайә», «Надир әр-Ривайә»дә, Әбү Йосыф, имам Мөхәммәд һәм имам Зөфәрдә китерелгән биш караш бар». Йә мондый: «Бу сорау буенча «Әр-Риваять әл-Кубра» дип аталган китапта Әхмәд бине Хәнбәлдән тапшырылган ун риваять бар». Имамнарның дәвамчылары гасырлар дәвамында ышанычлы (дөрес) фикерләрне аерып алганнар һәм һәр мәзһәбтә фәтва бирү юлы аша бер фикерне ныгытканнар. Бер мәзһәбкә таянган мөфти үз мәзһәбенең ышанычлы китапларына гына мөрәҗәгать итәчәк һәм мәзһәбнең ышанычлы карарларыннан чыгып фәтва бирә алырга мөмкин.

Өйрәнүче-факиһ Әбү Сугуд Әл-Гыймади һәм аңа ияргән, төрле катлауларга караганлыктан карашлары мәзһәб фикере буларак кабул ителмәгән галимнәрнең ялганнарына ышанырга тиеш түгел.

«Әгәр мин болай эшләсәм, минем өчен бу талак булып саналсын», дигән кеше турында: «хәнәфи мәзһәбендә моңа карата ике төрле караш бар», дип әйтү аның тарафыннан хата булыр иде. Бу дөрес тә түгел, чөнки урнашкан тәртип буенча бу фикернең нәтиҗәсен билгеләргә була.

Шәйх Бахит (аңа Аллаһының рәхмәте булсын) мәзһәбкә бернинди дә мөнәсәбәте булмаган китапчык чыгарып ялгышса да, фоторәсемнәргә карата булган хөкемнәре бик күп дөрес фикерләре арасында аз мәгънәгә ия булса да, әмма бу аның фикере. Аллаһы Тәгалә аны кичерсен.

Гарәпләрнең кайсысы «Галәййә әт-талак» («миңа талак булсын») дигән әйтем астында әйтүченең хатыны белән аерылуын аңламасын? Бу әйтемгә башка мәгънә бирү гарәп грамматикасы ягыннан һәм мәзһәб күзлегеннән дә хаталы санала. Мәзһәб шәйхларының фәтваларын туплаган китапларның кайсысында, булсын ул «Заһир Әр-Ривайә», «Надир әр-Ривайә» яки хәзерге заман мәсьәләләренә караган фәтваларны тупланган китапларда бу фикер бар? Киресенчә, моңа охшаш бернәрсә дә юк. Дөреслек исә моннан гыйбарәт: гадәттә, хатын белән аерылу өчен әйтелгән һәртөрле сүз никахны таркату була.

Әбү Сугудның мондый хата кылуына җитди сәбәп бар. Ул яшәгән төрек төбәгендә әлеге әйтемне кулланып хатынны аеру гадәте булмаган, ә гарәп өлкәләрендә, киресенчә, бу сорауга карата ныклы фикер урнашкан.

Мин бу мәкаләдә Әбү Сугудиның «Әл-Магзурат»ындагы барлык көчсез урыннарны һәм йөзәр еллап көчсез саналган Дар әл-Ифтаның (фәтвалар бирә торган инстанция) фәтваларын әйтергә теләмим. Әлеге Дар әл-Ифтага күп факиһлар кергән, бервакыт Әбү Сугуд та анда рәислек иткән.

Әгәр фәтва сораучы бер мәзһәбкә дә карамаган кеше булса, төрле илләрдә мәзһәб кабул итмәүчеләрнең күп кенә төрләре булуын күз алдында тотарга кирәк. Алардан берәрсе тәсаувыф исеме астында бөтен нәрсә рөхсәт ителгәнлек принцибын тарата (ибахийя сектасы). Кемдер сәләфиләр исеме астында тәҗсимне вәгазьли, Аллаһы Тәгаләгә предметлыкны бәйли һәм чынбарлыкта Аның куллары һәм аяклары бар дип саный (мүҗәсим сектасы). Кемдер хәдисләр итеп тарихта калган исмәгыйльләр сектасын тартып чыгарырга тырыша. Ә кайсысыдыр сөннәт астында Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иңгән вәхигә бәйле сорауларга каршы тора. Аларның барсын да бер нәрсә – мәзһәб имамнарына каршы көрәш һәм барлык мәзһәб системасын юкка чыгару теләге берләштерә. Моннан тыш алар арасында бернинди дә уртаклык юк. Аларның ялгыш карашларын ничек итеп мәзһәбкә бәйле карап булганлыгын мин күз алдына да китерә алмыйм. Теге яки бу мәзһәбкә карамаганлыктан, аларга билгеле бер мәзһәбтән чыгып фәтва бирергә кирәк дигәнне шарт итеп куярга ярамый.

Киресенчә, әгәр дә галимнәр тамчыдан күл җыелганчы, аларның тамырларына балта чапмыйча, көч туплап үсеп китүләренә ирек куйсалар, әлегә кадәр имин дип хисапланган илдә[1], Аллаһы сакласын, ахыр нәтиҗәсе билгесез булган процесслар башкарыла башлавы ихтимал. Әгәр мәртәбәле һәм белемле галимнәр, кичектермичә, үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәсәләр һәм фәтваларга карата үзләрен балалар кебек тотканнарга каршы торсалар, ялган, файдасыз дини карашлар ташкынын хак юлга борырга тырышсалар, бу хәлләрне булдырмый калырга мөмкин. Шуннан соң инде «фәтвалар чыгаруда ни өчен тәртипсезлек дәвам итә һәм нигә Исламда модернистик агымнар барлыкка килүгә күз йомалар?» дигән сорауларны ябып булыр иде.

1 Айдын Таш Төркияне күз алдында тота.

Искәрмә: әйтелгән сүзләрнең барысы да үз өммәтләренә иман белән, тугры хезмәт иткән имамнар турында түгел.

Хәнәфи мәзһәбендә танылган Әл-Кудуриның китабына нигезләнгән Касыйм бине Котлыбуганың «Әт-Тәсһиһ вә әт-Тәрҗиһ» дип аталган хезмәтеннән бер тәрҗемә китерәбез. Бу хезмәтендә ул фәтваларга һәм тәрҗиһкә (өстенлек бирү) мөнәсәбәтле игътибар итәргә кирәклеген әйтә.

Миңа үз күзләрем белән безнең имамнарның үз теләкләренә таянып мәзхәбләрендә эш иткәннәрен күрергә туры килде. Хәтта кайбер казыйлардан: «Үзеңә ошаган хөкемгә таянып эш итүнең нинди начарлыгы бар?» дигән сүзләрне дә ишетергә туры килде. Мин аларга: «Бар. Кешенең синең теләкләрең артынан иярүе – харам. Раҗиһ (яхшырак саналган) булганда, аңа каршы торган мәҗрух (кимчелек булганы) әһәмиятсез. Бер сорауга карата төрле күрсәтмәләр булганда, өстенлек бирергә сәбәпләре булмый торып, берсен генә сайларга ярамый».

Имам Йәгъмәри (һиҗри белән 799 елда вафат) «Табсырат әл-Хуккам фи усулил-Гакдийя вә Мәнәхиджи әл-Әхкәм» дип аталган китабында: «Ике риваятьнең яки фикернең кайсысы төплерәк икәнен белмәгән кеше тәрҗиһ (өстенлек бирү) кагыйдәләрен сакламыйча алар арасыннан берсен сайлап карар чыгара алмый», – дип әйткән.

Имам Әбү Гамр бине Әс-Салях (һиҗри белән 643 елда вафат) «Әдәп әл-Мөфти вә әл-Мөстәфти» дип аталган хезмәтендә: «Шуны бел: тәрҗиһ кагыйдәләренә буйсынмыйча фәтва яки хөкемнәрнең берсенә өстенлек биргән, үзенең фикһ мәсьәләләре буенча чыгарган фәтвасы яки гамәлләре чынбарлыкта яшәп килгән карашларның берсенә туры килүе белән канәгатьләнгән кеше җаһилеккә төшкән һәм иҗмагъны бозган була», – дип әйткән.

Әл-Баҗи мондый вакыйга сөйләгән. Бервакыт ул бер хәлгә юлыга һәм кайбер галимнәр моннан чыгып Әл-Баҗига зыян китерә алырлык фәтва кабул итәләр. Әл-Баҗи ни өчен шундый фәтва чыгаруларын сора-

гач, алар: «Без бу хәлнең синең белән булганын белмәдек». Шуннан соң ул: «Сез чыгарган фәтваны кабул итәрлек түгел һәм бу мәсьәләдә иҗмагъ тарафдарлары арасында ихтиләфләр юк», – дип әйткән.

Имам Йәгъмәри (һиҗри белән 799 елда вафат) «Табсырат әл-Хуккам фи усулил-Гакдийя вә Мәнәхиджи әл-Әхкәм» дип аталган китабында: «Мөфти белән хаким (судья) арасында бернинди аерма юк, фәкать, мөфти кануннарны игълан итә торган вазифа башкарса, ә хаким аларны конкрет очраклар белән бәйли», – дип әйткән.

Фикһ алымнарын яхшы белүчеләр: «Бер килешү бар: бер сорауга бер мәзһәбнең карашыннан чыгып гамәл кылсаң, моннан соң икенче караштан чыгып эш йөртергә, карашыңны үзгәртергә ярамый. Мәзһәбтә шулай кабул ителгән», – дип әйткәннәр.

Имам Әбү Әл-Хәсән Әл-Хатыйб Такыеддин Әс-Субки (һиҗри белән 756 елда вафат) «Әл-Фәтәвә»дә: «Әгәр бер мәзһәбкә караган мөфти мөҗтәһидләрнең бер мәзһәбе буенча фәтва биргән булса да, ниндидер мәсьәлә буенча «болай» дип әйтсә һәм шуннан соң, шул ук мәсьәлә буенча икенче мәзһәб буенча хөкем итеп, каршы як карарын кабул итсә – бу дөрес булмый. Бу бит үз нәфесеңнең теләкләре юл кую дигәнне аңлата», – дип язган.

Шул ук хезмәтендә Әс-Субки: «Әгәр кеше бер мәзһәб белән бәйле булып, икенче бер мәзһәб аның терәге булмаса, ул һәрвакыт бу имамның мәзһәбенә ияреrgә тиеш», – дип әйткән.

Мөкаллидкә (ияручегә) икенче мәзһәб ярдәмче була алмый. Мөҗтәһид мөкаллид кебек түгел. Ул бер дәлилдән икенче бер дәлилгә күчә ала. Бу сорауны күтәреп, имам Әс-Субки алдарак әйтелгән бердәм карар кабул итү мәсьәләсен аңлатырга тырышкан.

Әс-Субки: «Бер-берсенә капма-каршы булган иҗтиһидларга нигезләнеп чыгарылган карарны кабул итәргә ярамый», диелгән иҗмагъ фикере бар. Мисал буларак алар башындагы берничә бөртек чәчкә генә

мәсех кылып, тәһарәт алган, шул рәвешле намаз укыган, соңыннан тәненә эт кагылган булуын ачыклаган кешенең халәтен китергәннәр», – дип әйткән.

Шиһабетдин Әл-Әкфахси (һиҗри белән 808 елда вафат) үзенең «Тәвкыф әл-Хуккам галә Гәвамид әл-Әхкам» хезмәтендә «иҗмагъ килешүе буенча ялган» дигән гыйбарәгә ачыклык кертеп: «Ниндидер сораугa карата бер хөкемне бер мәзһәбтән, ә икенче бер хөкемне икенче мәзһәбтән алып кабул ителгән ялган карар, иҗмагъ килешүе, ягъни мөселманнарның бердәм килешүе буенча ялган була», – дип әйткән.

Боларны берничә мисалда аңлатып, Шиһабетдин Әл-Әкфахси: «Күп кенә надан казыйлар әлеге хатаны кылалар. Алар ялган карар нигезендә хөкем чыгаралар», – дип әйткән.

Галимнәрнең бурычларын аңламаган кайбер кешеләр: «Әбү Хәнифә бер хөкем әйтеп, ә аның ике укучысы аңа капма-каршы булган хөкем әйтсәләр, мөфти һәм казый аларның берәрсен сайлауда ирекле. Моны галимнәр шулай раслаган», – дип әйткәннәр. Мин аларга болай җавап бирдем: «Юк, сез дөрес фикер йөртмисез. Имам Галләмә Әл-Хәсән бине Мансур бине Мәхмүд Әл-Үзҗәнди (һиҗри белән 592 елда вафат), икенче исеме Кадыхан, үзенең Әл-Фәтәва» дип аталган хезмәтендә:

«Безнең заманда хәнәфи мәзһәбенә караган һәрбер мөфти үзеннән фәтва сораганда түбәндәге алымнарны кулланырга тиеш:

– әгәр каралачак сораугa булган хөкем «Заһир Әр-Ривайә»дә теркәлсә һәм безнең сәхабәләр (Әбү Хәнифә һәм аның укучылары) аны кире какмасалар, ул шушы хөкемгә таянырга һәм аңа ярашлы рәвештә фәтва чыгарырга тиеш. Әгәр ул мәзһәбтә нык мөҗтәһид булса да, аның хөкеме имамнарга каршы килә алмый. Шунысы ап-ачык: сәхабәләребезнең яшәп килгән фикерләрен игътибарсыз калдыру мөмкин түгеллеге иң дөрес караш булып тора. Кешенең шәхси иҗтиһады аларның иҗтиһадлары дәрәҗәсенә җитә алмый. Ул имамнарның гомуми фикерләренә каршы

килгәннәрне тыңламас һәм аларның дәлилләре белән килешмәс, чөнки безнең имамнар барлык дәлилләрне яхшы аңлаган хәлдә, ышанычлы һәм шиксез дәлилләрне ышаныч тудырмаган, нигезсез дәлилләрдән аердылар;

– әгәр бу мәсьәлә безнең сәхабәләр арасында бәхәсле булса, ул чагында Әбү Йосыф һәм имам Мөхәммәднең фикерләре Әбү Хәнифә белән туры килмәгәнен карарга кирәк. Әгәр дә аларның берсе бу мәсьәлә буенча Әбү Хәнифә белән бер караштa торса, әлеге икәүнең хөкемнәрендә дөрес дәлилләр һәм нәтиҗәләр булуга карап, мөфти аларның фикерләренә таянып фәтва чыгара;

– әгәр ике имам (имам Әбү Йосыф һәм имам Мөхәммәд) бу мәсьәләне чишүдә Әбү Хәнифә белән килешмәсәләр, фикерләр төрлелеге ни сәбәпле туганын ачыкларга кирәк. Әгәр сәбәп вакытлар үтү һәм гадәтләрнең үзгәрүенә бәйле икән (чөнки вакытлар үтү белән кешеләрнең хәле үзгәрә), мөфти ике имамның хөкемнәренә нигезләнеп карар чыгарырга тиеш. Моны судларда кайбер очракларда бары тик ап-ачык гаделлек принцибына таянып эш итүләренә охшатып булыр иде. Нәкъ шулай ук җир арендасы (музарагат), сәүдә һәм эшлекле мөнәсәбәтләргә (мөгамәлә) бәйле сорауларда ике имамның фикерен яхшырак күрү кирәк, чөнки бу сорауларда галимнәр ике имамның фикере тирәсендә берләшкәннәр;

– санап кителгән өч очрактан тыш мөҗтәһид булган мөфти үз сайлавында ирекле. Ул үз карашларына якынрак дип санаган имамнарның фикерләреннән чыгып эш итәргә мөмкин. Ләкин Габдуллаһ бине Әл-Мөбарәк (һиҗри белән 118 елда вафат): «Мондый очракта мөфти Әбү Хәнифә ягын ала», – дип әйткән.

– әгәр бу сорау буенча карар «Заһир Әр-Ривайә»дә булмаса, ул чагында мәзһәбнең гомуми кагыйдәләре белән аның туры килгәнлеген карарга кирәк. Туры килсә, бу карар белән эш итәргә;

– әгәр замана галимнәре карала торган сорау буенча төрле фикерләрдә торсалар. Мөфти иҗтиһад кылып, үзе дөрес дип санаганнан чыгып карар кабул итә;

– әгәр мөфти мөҗтәһид түгел, ә бары тик иярүче генә булса, ул үзенең бик яхшы таныш факиһы янына барып, шуннан соң инде аның хөкемнәренә нигезләнеп, фәтва чыгарырга тиеш;

– әгәр яхшы таныш факиһ ерак шәһәрдә яшәсә, мөфти аңа хат юлларга һәм аннан җавапны көтәргә тиеш (чөнки мөфти Аллаһы исеменнән әйтә, шуңа да ул Аллаһыга нахак яла ягудан сакланырга, ягъни рөхсәт ителгәнне харам, ә тыелганны хәләл дип әйтүдән, төгәл булмаган җавап бирүдән сакланырга тиеш).

«Әл-Мохит әл-Борһани» исемле хезмәттә мөфтигә карата алда әйтелгәннәр шулай ук казыйларга да карый, дип аңлатма бирелә.

Имам Галләмә Әбү Бәкер Мәсгуд бине Әхмәд Әл-Кәсәни (һиҗри белән 587 елда вафат) үзенең «Бәдәигъ әс-Сәнәигъ» китабында: «Әгәр казый, мөҗтәһид хәлендә, үз карашларына ярашлы рәвештә ниндидер бер нәтиҗәгә килә икән, аларга таянып гамәл кылу аңа вәҗиб була. Әгәр инде ул мөҗтәһид түгел икән, бу очракта аның безнең сәхабәләрнең әйткән фикерләрен яхшы белгәнлеген һәм аларны үз аңында нык саклаганын карарга кирәк. Әгәр шулай булса, ул карашларының дөреслегенә ышанган имамның хөкемнәренә таянып карар чыгарырга мөмкин. Әгәр инде ул безнең сәхабәләрнең хөкемнәрен хәтерләмәсә, шул шәһәрдә яшәгән хәнәфи мәзһәбендәге факиһларның фикерләренә таянырга тиеш. Шәһәрдә бер генә факиһ-хәнәфи булган очракта, аның күрсәтмәләрен тыңларга тиеш», – дип язган. Шулай ук Әл-Кәсәни казыйлар башкарган эшләрнең үзенчәлеген искәртеп: «Каза (казый тарафыннан чыгарылган суд карары) Аллаһы өчен генә булырга тиеш. Каза ул – гыйбадәт. Ә гыйбадәт, тулысынча Аллаһы ризалыгы өчен башкарыла», – дип әйткән.

Борхан Әл-Аиммә Әс-Садр Әш-Шәһид Хассафның (һиҗри белән 536 елда вафат) «Әдәп әл-Каза» хезмәтенә булган аңлатмаларында түбәндәгеләрне язган: Суд карарын чыгарганда казый ике очракка игътибарлы булырга тиеш:

1. Карар безнең сәхабәләрнең бердәм килешүенә нигезләнергә мөмкин. Ул чагында казый аңа нигезләнеп (ә башка мәзһәбләрнең карашларына нигезләнеп түгел) карар чыгара, чөнки ияртүче «дөрес фикер ул – безнең сәхабәләрнең хөкемнәре», дигәнгә ышанырга тиеш.

2. Сәхабәләр арасында бу карар буенча төрле фикерләр булырга мөмкин. Бу очракта Габдуллаһ бине Әл-Мөбарәк: «Әбү Хәнифәнең фикерен сайларга кирәк, чөнки аның фикере – ул сәхабәләрнең фикере, моннан тыш ул табигыйннәр заманында ук фәтвалар биргән. Шуңа да ихтиләф вакыт үтү белән килеп туган үзгәрешләр нәтиҗәсе булмаса, аның сүзе дөресрәк һәм ышанычлырак булырга тиеш», – дип киңәш биргән. Соңгырак чорда яшәгән галимнәр исә казый мондый очракларда казыймөҗтәһидтән сорарга тиеш, дип әйткәннәр.

«Әл-Һидая»гә аңлатма булган «Фәтех әл-Кадир» хезмәтендә, Ибне Әл-Хумам (һиҗри белән 861 елда вафат) мөҗтәһиднең гамәлләрендәге каршылыкларны күрсәтә. Алар үз карашларына каршы килгән карар чыгаралар, ахырда исә әйтелгәннәргә түбәндәгечә нәтиҗә ясыйлар: «Әгәр ул үз карашын онытып яисә белә торып үз фикереннән баш тартса, ике очракта да аның карары дөрес булмый. Мондый юл белән хәл итү безнең имамнар заманында булган һәм хәзер дә әле үз көчендә кала бирә.

Тиешле фәтва бирү дөресрәк була, чөнки бүгенге көндә дә белә торып үз фикереннән баш тартуның нигезле дәлилләре булуы мөмкин түгел. Иң кимендә, шәригатьтә хупламаган теләкләргә ияртүне тәкъдим итәргә мөмкин. Ә инде үз фикерен онытып, башка кешенең фикеренә таянып карар чыгарган казыйга килгәндә, казыйга мөрәҗәгать иткән кеше судка килеп, казый аның эшен башкаларның фикерләренә ияреп түгел, ә үз

фикерләренә таянып хәл итәр дип килә. Монда әйтелгәннәр, мәзһәбнең мөҗтәһиде саналган казыйга карый».

«Әл-Кунья» китабында: «Үз карашыңа каршы килеп кабул ителгән дөрес яки дөрес булмаган карарга бәйле барлык риваятьләр казый-мөҗтәһидкә карый. Әгәр инде казый-мөкаллид үз мәзһәбенә каршы булган карар чыгарса, аның карары дөрес булмый», – дип әйтелгән.

Әбү Әл-Габбас Әхмәд бине Идрис Әл-Карафи (һиҗри белән 684 елда вафат): «Мөфтигә яхшырак күрелгән хөкемгә таянып фәтва чыгару вәҗиб булган кебек, хакимгә (судья) үз карашына туры килгән суд карарын чыгару вәҗиб буламы? Әллә инде аның ике хөкем арасында яхшырак күрелгәне булмаса, ул аларның берсенә таянып хөкем итә аламы? Бу сорауга җавап мондыйрак: әгәр хаким мөҗтәһид булса, аның үз карашларына туры килмәгән хөкемгә таянып карар кабул итүе яисә фәтва чыгаруы кабул ителми. Әгәр инде ул иярүче генә булса, мәзһәбтә өстенрәк булган фикергә таянып фәтва бирүе кабул ителә. Аңа үз имамының фәтваларына ияргергә кушылган кебек, нәкъ шулай ук суд карарын чыгарыр өчен хөкемне сайлаганда да ул аңа охшарга тырышырга тиеш. Үз теләкләрңә ияреп, бердәм килешеп фәтва чыгару – харам. Нигезсез хөкемгә таянып фәтва яки суд карарын чыгару иҗмагъны бозу була», – дип әйткән.

«Без үз карарларыбызда кемнең хөкеменә таянырга тиешбез, мөҗтәһидләр, факиһлар да калмадымы бит?» – дип сорау биргән кешегә безнең җавап мондый булыр: «Төрле риваятьләр булган сорауларга карата Габдуллаһ бине Әл-Мөбарәк киңәшенә таянып эш итәчәкбез. Шулай да, мөҗтәһидләр эзсез югалмаганнар. Алар үзләреннән соң бәхәсле сорауларга карата фәтваларны, өстенрәк күрелгән фикерләрне калдырганнар. Әлеге шәхесләр тарафыннан язылган китаплар Әбү Хәнифәнең карашларына таянырга кирәклекне раслыйлар. Кайбер сорауларда, искәрмә буларак, Әбү Хәнифәнең (аңа Аллаһының рәхмәте булсын) әйткәннәре булмаса, имам Мөхәммәд һәм Әбү Йосыф хөкемнәренә өстенлек бирелә.

Әгәр инде алар бу имамнарда да кирәкле хөкем тапмасалар, Зөфәрнең фикеренә мөрәҗәгать иткәннәр. Шул рәвешле, аларның өстенрәк күрелгән фикерләре һәм фәтвалары барлык заманда да гамәлдә булганнар, әйтерсең лә, алар безнең көннәрдә дә, үзләре яшәгән чорда тоткан карашларга яраклы рәвештә, безгә фәтва бирәләр кебек.

Әгәр имамнар тарафыннан бирелгән карарлардан тыш тагын башка каралар булып, фәтва чыгарганда алар тирәсендә фикер каршылыклары туса, бу очракта нишләргә? Без моңа болай җавап бирәбез: безнең элгәреләребез кирәкле хөкем сайлаган вакытта кешеләрнең торышларына, гадәтләренә һәм традицияләренә бәйле үзгәрешләргә игътибар иткәннәр һәм алар арасыннан кешеләргә туры килгәннәрен сайларга тырышканнар. Без дә алар кебек эш итәчәкбез. Ләкин бу эш белән үзләрен яхшы белгеч дип санаган кешеләр түгел, ә чын мәгънәсендә бу эшкә сәләтлеләр, көчле хөкемне көчсезеннән аера алганнар шөгыльләнергә тиеш. Ислам дөньясында мондый кешеләр табылачак. Ә кемнәрнең исә моны эшләргә сәләтләре җитми икән, алар үзләреннән җаваплылыкны төшерер өчен, бу эшкә сәләтле булганнарга мөрәҗәгать итәргә тиешләр».

*Камил хәзрәт Самигуллинның*

*«Введение в ханафитский фикх» китабыннан тәрҗемә*

# Тарих

# Пәйгамбәрләр тарихы

## Пәйгамбәрлек килгәч Мәккәдәге әхвәл

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә хәзрәти Җәбраил галәйһиссәлам вәхи китерә башлады, кирәк булган саен Аллаһы Тәгаләнең сүзен (Коръәнне) аять-аять иңдерер иде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы Тәгалә боерганча, халыкны дингә өнди башлады. Әүвәл башта потларга гыйбадәт кылудан тыеп, Аллаһы Тәгаләгә хаслаб гыйбадәт кылырга вә үзен растларга димләр иде. «Ләә иләәһә илләллаһ Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ» – дип икърар итүгә боерыр иде вә аз-аз иңгән Коръән аятьләрен халыкка укыр иде. Баштарак иман китерүче аз булды, Корәеш кабиләсе ата-баба диненнән чыкмыйбыз, искедән гыйбадәт кыла килгән потларыбызны ташламыйбыз, диделәр. Вә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә төрле җәфалар кылдылар вә иман китергән сәхабәләргә дә җәфа тидерергә тырыштылар. Иман китергән сәхабәләр күп җәфа вә бәла күрсәләр дә, чыдадылар вә иманнарыннан дүнмәделәр һәм Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккә кяферләренең төрле-төрле җәфа вә бәлаләренә сабыр итеп, һәнүз[1] дингә өндәр иде. Һәркемне йомшаклык берлә вәгазь вә нәсыйхәт итәр иде, күргән халыкны димләр иде; җаһилият заманында булган иман, халыкларны гакылга вә инсаниятькә хилаф эшләрдән тыяр иде; потларның бернәрсәгә дә яраксызлыгын, гыйбадәтнең бары Аллаһы Тәгаләгә тиешле идекне ачык-ачык әйтер иде. Халыкның каршына карап хакны әйтүдән вә хакка өндәүдән туктамас иде, пәйгамбәрлегенә могҗиза сораган кешегә төрле могҗизалар күрсәтер иде. Байтак адәмнәр Коръән аятьләрен ишеткәч, бу аятьләр бер дә адәм сүзенә охшамый, әлбәттә, Аллаһы Тәгаләдән иңгән булыр, дип, иман китерделәр, вә каюлары Расүлуллаһ салләллаһу

[1] Һәнүз – әле дә, һаман, һаман да.

галәйһи вә сәлләмнең яшьлегеннән бирле күргән холкы, дөньяга ихлассыз, һәр эшендә тугры, гомерендә асла ялган сөйләмәгән кеше булганлыгындин, әлбәттә, бу сүзләре дә растдыр, дип ышанып, иман китергән. Вә каюлары Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гыйлемен күреп, вә төрле-төрле хикмәт сүзләрен ишетеп, иман китерделәр, чөнки Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккә халкының күз алдында туып үскән иде, бер җиргә дә барып гыйлем укыган түгел иде, галимнәр берлә утырдаш булганы юк иде, язу язарга өйрәнмәгән иде вә һәм китап укырга өйрәнмәгән иде. Шулай була торып, бу кадәр гыйлем күрсәтүе, әүвәлге пәйгамбәрләрнең (галәйһимуссәлам) вә аларның өммәтләренең хәлләрен белдерүе вә ахирәт хәлләрен бәян итүе, Аллаһы Тәгаләне танытуы вә халык төзәтмәк өчен булган нәсыйхәтләре, вәхи берлә уйлаган күп адәмнәр иман китерер иделәр. Мәккәнең үз халкыннан башка Мәдинә шәһәреннән вә башка чит җирләрдән килеп, иман китерүчеләр вә Исламга килүчеләр күбәймәк тә иде. Вә бүлек-бүлек Аллаһы Тәгаләдән хәзрәти Җәбраил галәйһиссәлам аркылы Коръән иңмәктә иде. Һәр иңгән сүрә-аятьләрне Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләргә укыр иде вә аларга өйрәтер иде, вә һәм вәхи язучыларына яздыра барыр иде. Иман китерүчеләр вә Ислам диненә керүчеләр көн бикөн[1] артса да, мөшрикләрнең вә Корәеш кавеменең каршылыклары вә җәфалары һәнүз күп иде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үзенә вә сәхабәләргә төрле-төрле җәфа вә бәлаләр күрсәтерләр иде. Әүвәлдән Исламга керүчеләр вә Мәккәдә иман китерүчеләр: ирләрдән әүвәл иман китерүче – Әбү Бәкер Әс-Сыддыйк, хатыннардан – Хәдичә Әл-Кубра, сабыйлардан – Гали бине Әбү Талиб, азатлылардан[2] – Зәйд бине Хариса радыяллаһу ганһүм иде. Әбү Бәкер Әс-Сыддыйк радыяллаһу ганһе бик

[1] Көн бикөн – көннән-көн.

[2] Зәйд кечкенә вакытында коллыкка эләгә, соңыннан аны Хәдичәгә бүләк итәләр, Пәйгамбәребез аны тәрбиягә ала – ред.

гакыйль[1], тугры фикерле кеше иде, шуның өчен җаһилият вакытында да асла потларга мәхәббәт итмичә, аларны яман күреп, бер хак дин булса иде дип, күңеле берлә эзләнмәге бар иде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне әүвәлдән ышанычлы, раст сүзле, тугры эшле дип бик артык белә иде. Шул сәбәптән, башта ук бер дә тоткарсыз иман китерде вә һәм күп сәхабәләрнең иманга килүләренә сәбәп булды. Болардан соң иман китерүчеләр ошбулардыр: Госман бине Гаффән, Габдеррахман бине Гавеф, Сәгъд бине Әбү Вәккас, Зөбәер бине Әл-Гаввам, Талхә бине Гобәйдүллаһ радыяллаһу ганһүм. Болардан соң Әбү Габидә бине Габдуллаһ бине Әл-Җәррах, Сәгыйд бине Зәйд, Хәббаб бине Арат, Әбү Сәләмә бине Габделәсәд, Госман бине Мәзгун, Габдуллаһ бине Мәсгуд, Билал Хәбәши, Сөһәйб Руми, Гаммәр бине Ясир вә анасы Сөмәя, хәзрәти Гомәрнең карендәше Фатыйма бинте Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһүм иделәр. Болардан соң Хәмзә бине Габделмотталиб, Гомәр бине Әл-Хаттаб иманга килде.

## Хәзрәти Хәмзә бине Габделмотталиб радыяллаһу ганһенең иманы

Нәбүвәттән[2] алтынчы елда бер көн Әбү Җәһил Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә очрап, яман сүзләр әйтеп тәхфиф[3] итте. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер сүз дими сабыр итте. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гаме[4] хәзрәти Хәмзә ул вакыт иман китермәгән иде. Шул көнне кырдан кайткач, Әбү Җәһилнең әдәпсезлекләрен хәзрәти Хәмзәгә бер җария[5] сөйләде. Хәзрәти Хәмзә һәнүз иман китергән булмаса да, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм өчен Әбү Җәһилгә бик ачуланып, Корәеш арасында тугры китереп: «Минем

1 Гакыйль – акыллы.

2 Нәбүвәт – пәйгамбәрлек.

3 Тәхфиф – кимсетү.

4 Гамь – ата белән бертуган ир кардәш.

5 Җария – яшь кол хатын, кәнизәк.

карендәшем углын син ни өчен сүктең», – вә ук җәясе берлә Әбү Җәһилнең башын ярды. Әбү Җәһил дә Корәеш арасында киберле[1] вә игътибарлы адәм булдыкыннан, аны яклап, бәгъзе кяферләр хәзрәти Хәмзәгә ябышмак булсалар да, Әбү Җәһил туктатты, Хәмзәнең карендәше углына кулым тиде, ачуланса да гаеп түгел, диде. Фил-хакыйка[2], Әбү Җәһил хәзрәти Хәмзәнең мөселман булуыннан курка иде. Аның хәтерен саклап, үз араларыннан чыгармаска тырыша иде, чөнки хәзрәти Хәмзә бик йөрәкле баһадир, сүзе үткен, Корәеш арасында кадерле кеше иде. Мөселман улса, мөселманнар өчен бик зур арка булырлык иде. Хәзрәти Хәмзә Әбү Җәһилнең башын ярганнан соң, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына барып, вакыйганы сөйләде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм иман китерсә, шатланачагын хәзрәти Хәмзәгә аңлатты, хәзрәти Хәмзә филхәл[3] кәлимәи шәһадәт әйтеп иман китерде.

## Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһенең иманы

Хәзрәти Хәмзә иман китергәч, мөселманнар бик шатландылар, мөселманнарга хәзрәти Хәмзә радыяллаһу ганһе бик зур куәт булды. Корәешлеләр бу вакыйгадан соң бик хәсрәтләнделәр: «Болай булса, Мөхәммәднең ише бик күбәя, эшләре куәтләнә, тизрәк бер гыйлаҗ[4] кылыйк», – дип сөйләштеләр. Һәр каюсы бер төрле мәкер итеп күрделәр. Әбү Җәһил Мөхәммәдне үтермәктән башка чара юктыр, һәркем аны үтерсә, бу кадәр алтын бирермен, дип кызыктырды. Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһе ул вакытта иман китермәгән иде вә һәм Корәешнең киңәшендә иде. Әбү Җәһил сүзенә каршы: «Бу эшне миннән башка кеше кыла алмас», – дип, урыныннан кузгалды. Корәеш як-яктан хәзрәти Гомәрне хупладылар вә күтәрделәр, вә шуннан ук хәзрәти Гомәр кылычын алып, Расүлуллаһ

[1] Киберле – олы, бөек.

[2] Фил-хакыйка – хакыйкатьтә.

[3] Фил-хәл – шундук, бик тиз.

[4] Гыйлаҗ – әмәл, чара.

салләллаһу галәйһи вә сәлләмне эзләп китте. Юлда кыз карендәше Фатыйма бинте Әл-Хаттабның вә кияве Сәгыйд бине Зәйднең иман китерүләрен ишетеп бик ачуланып, әүвәл аларның өйләренә китте. Алар сүрә «Та Һә» өйрәнеп вә укып утырыр иделәр. Хәббаб бине Арат радыяллаһу ганһе дигән сәхабә аларга өйрәтеп утырыр иде. Гомәрнең бик шәддәт[1] вә гайрәт берлә килгәнен күргәч үк, Кәлам Шәриф язган кәгазьләрен яшерделәр. Хәббаб өйнең бер почмагына качты. Гомәр: «Ни эшләп утыра идегез, ни укый идегез?» – дип, бик шәддәт берлә сорады. Болар: «Бернәрсә дә юк», – дисәләр дә, Гомәр: «Сез Мөхәммәднең сихеренә алданган икәнсез», – дип, кияве Сәгыйдне якасыннан тотып җиргә салды, хатыны Фатыйма араламак булгач, Гомәр аның йөзенә сугып, йөзен канатты. Карендәше Фатыйма радыяллаһу ганһәнең йөзе кып-кызыл канга буялгач, Гомәрнең шәфкате килде, ачуы басылды. Фатыйма гайрәт[2] диниягә килеп: «Ий, Гомәр, Аллаһыдан курыкмыйсыңмы, бу кадәр могҗиза күрсәткән пәйгамбәргә инанмыйсың, менә мин вә ирем, әлхәмдүлилләһ, дин Ислам берлә мәшриф[3] булдык, башыбызны кисәр исәң дә, кайтмыйбыз», – дип, кәлимәи шәһадәт китерде. Гомәр аптырап китте вә күңелендә бер әсәр[4] хасил булды. Утырып: «Шул укыган китабыгызны миңа күрсәтегез», – дип сорады. Фатыйма сүрә «Та Һә» язылган кәгазьне чыгарып бирде, Гомәр һаман укыды: لَهُ مَا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ وَمَا بَيْنَهُمَا وَمَا تَحْتَ الثَّرَى ﴿٦﴾ аятенә ирешкәч, уйлап торды, аннан соң «Та Һа» сүрәсенең 8 нче аятен укыды вә бераз уйлады. Бу аятьләрдә булган фәсахәт[5] вә мәгани[6] әсәр итте, такатьсез[7] булды, шунда ук: «Әшһәдү әл-ләә иләһә илләл-лааһ вә әшһәдү

---

1 Шәддәт – көч, киеренкелек.
2 Гайрәт – батырлык, кыюлык.
3 Мәшриф – кадерле, хөрмәтле, бәхетле.
4 Әсәр – эз, йогынты, тәэсир.
5 Фәсахәт – матур теллелек.
6 Мәгани – мәгънәләр.
7 Такать – көч, куәт.

әннә Мүхәммәдәр-расүлүллааһ», – дип иман китерде. Моны ишетү берлә почмакка качкан Хәббаб сикереп чыгып, тәкбир әйтте: «Йә, Гомәр, сиңа бәшарәт[1]! Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ий, Аллаһы, дин Исламны Әбү Җәһил берлә яки Гомәр берлә газиз ит», – дип дога иткән иде. Бу дәүләт сиңа насыйп булды», – диде. Шул сәгатьтә Гомәр радыяллаһу ганһе Хәббаб радыяллаһу ганһе берлә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм хозурына киттеләр. Ерактан күргән мөселманнар Гомәр радыяллаһу ганһенең кылыч берлә килүеннән куркып, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына ялгыз керүеннән курыксалар да, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә хәзрәти Җәбраил галәйһиссәлам вәхи китереп, хәзрәти Гомәрнең иман китерүне белдергән иде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм көтеп тора иде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм хозурына кереп, алдына тез чүкте. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Йә, Гомәр, иман китер», – диде. Хәзрәти Гомәр хәзер тәмам ихлас илә кәлимәи шәһадәт укыды, мөселманнарга бик зур шатлык хасыйл булды, һәммәсе бердән тәкбир әйттеләр, тәкбир авазы Мәккәнең урамнарына ишетелде.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә вә сәхабәләргә бик яман җәфа кылучы Мәккә кяферләренең мәшһүрләре вә олуглары ошбулар иде: Әбү Җәһил (Гамр бине Һишам), Вәлид бине Әл-Мөгыйра, Готбә бине Рабига, Шәйбә бине Әбү Могыйт, Гаммәраһ бине Әл-Вәлид, Өмәййә бине Халәф, Гас бине Вәил, Харис бине Кайс, Әсвәд бине Габде-Йәгус, Әсвәд бине Әл-Мотталиб, ахырда бу бәдбәхетләр хур вә зәлил[2] булып һәлак булдылар.

*(Дәвамы бар)*

*Галимҗан Баруди, 1899 ел*

[1] Бәшарәт – шатлык, шатлыклы хәбәр.

[2] Зәлил – хурлыклы, түбән.

# Сигезенче мөфти – Ризаэтдин хәзрәт

1789 елда Духовное собрание мәхкәмәсе ачылгач, губернатор барон Илгистрах тарафыннан эш программасы бирелеп, 117 ел дәвам иткән. Фәкать 1905 елда гына мөфти Солтанов бер җыелыш ясап, шул уставка өстәмә керткән һәм Петроградка җибәргән. Ләкин миссионер Червонск: «Без Духовное собраниене 5 областька бүләбез, таратабыз», – дип, проект төзеп, Министрга керткән. Моңа каршы мөселманнар протест ясап, дау чыгардылар. Шунлыктан Червонскның проекты гамәлгә ашмый калды. 1923 елдагы Уфадагы съездны Җәмаледдин Курамшин алып барды, мөфти һәм казыйлар сайладылар. Мөфти итеп Ризаэтдин Фәхретдин сайланды. Казыйлар: Кәшшаф Тәрҗемани, Зиаэддин Кәмали, Габдулла Сөләймани, Мөхлиса Бубия һәм Мәһди Мәгъкулый сайланды.

8 нче мөфти халык сайлаган мөфтинең икенчесе булып эшкә кереште. Кыскача тәрҗемәи хәле болай.

Ризаэтдин бине Фәхретдин типтәр нәселеннән дип үзен бәян иткән. 4 нче бабасы Бикмәткә кадәр мулла булган. Төп чыгышлары – Казан губернасы Зөя өязе Шырдан авылыннан. 1700 ел башларында Юлдаш дигән бабасы Шырдан авылын ташлап, иярченнәре белән Бөгелмәгә киләләр, һәм бер җиргә авыл булып утыралар. Ике суның бергә кушылган җире булганлыктан, Кичүчаты дип исем бирәләр. Шул авылда 1859 елда дөньяга килә. Башта атасыннан гыйлем ала, соңыннан күрше авылда Шәлчәле (Чәчеле, Чыршылы) дигән авылда Габделфәттах хәзрәт мәдрәсәсендә гыйлем тәхсыйл кыла. Бераз хәлфә булып укыта, шуннан башка мәдрәсә күрми, чит ил күрми, фәкать шул авыл мәдрәсәсендә алган гыйлеме белән мөселманнарга зур хезмәт күрсәтә. Атасы һәм остазының тәрбиясе аркасында бөек диндар галим була. Гыйлемгә мәхәббәте өстенә китапка да мәхәббәте зур була. Гыйлемгә комсыз егет галимнәрне бик сөя, гыйлем мәҗлесен бик ярата. Шәлчәледә шәкерт вакытында Петербург ахунды

Хәмидулла хәзрәтнең балалары Зәйнелгабидин, Фатих, Зарифларны укыта. Шул мөнәсәбәт белән Петербургта Хәмидулла хәзрәттә кунакта булып, анының аркылы Мәгариф Министры белән танышып «Тарихи вә әхлакый» хәл хакында язган беренче китабын бастырып чыгара. «Китабел игътибарны» Казанда Мөхәммәдҗан Минһаҗев хараҗәте белән бастыра. Шуннан соң инде мәдрәсәгә бармый. Икенче елда күршедәге Илбәк дигән авылда имам була. 2 елдан соң мөфти Солтанов күрсәтүе буенча, казый булып сайлана, һәм ахунд дәрәҗәсе белән 1891 елда Собраниягә килгәч, яңа муллаларны имтихан кылуда нык катнаша.

Мөфти Солтанов яңа архивны тәртипкә салырга куша һәм ул архивны җиренә җиткереп тәртипкә сала. Метрикәләрне елын-елга аерып юлга сала, номер суга. Мөфти моңа бик тәхсин кыла. Шул тикшерү аркасында Риза казый бик күп мари-чуаш исемнәре очрата. Шул сәбәпле, халыкка гарәп исемнәре кушу өчен Мөфтигә гариза язып кертә, һәм исемнәр дәфтәре төзеп, халыкка тарата. Һаман архивка мәхәббәт кую аркасында, тарихи мәгълүмат иясенә әйләнә. Күп галимнәр хакында тарихи мәгълүматлар яза. Тәрҗемәи хәлләр яза. Замана ирек биргән кадәр генә булса да, файдаланып, әсәрләр язды. Яшь галим каләм хезмәте белән халыкка әдиб булып танылды. 4 мәртәбә сайланып, 15 ел казый булып хезмәт итте. 1906 елда үзе теләп казыйлыктан чыкты. 1905 елда матбага ирекге чыккан иде. Шуннан файдаланып, Истанбулда укып кайткан туганы Фатыйх Кәримов Гыйльман ахунд улы белән берлектә «Вакыт» гәзетасы ачып, миллионер Рәмиевлар хисабына чыгара башладылар. Шул вакытта Риза казый да Оренбургка килде. Рәмиевлар бик хуп күреп, каршы алдылар. Бик аз гына киңәшеп «Шура» журналы чыгара башладылар. Хөкүмәт рөхсәте белән Риза казый редакторлык итә башлады, мөхәррир булды.

Тирән гыйльми, тарихи мәкаләләрне эченә алып, «Шура» журналы вакытлы татар матбугатында зур урыннарның алдынгысында булды. 1908 елның 10 нчы гыйнваренда 1 нче номеры басылып чыкты.

Айга ике мәртәбә чыгып, 9 ел дәвам итте. 9 елдан туктатылды. Каләм ияләре, мөдәррисләр, мөгаллимнәр, имамнар – барысы да язышып, мөселманнарны аң-белемгә ирештерде. Эчке Россия мөселманнарына таралып, арада танышуларга сәбәп булды. Наданлык сәбәпле, мөселманнар арасында оялап яткан хорафат, ырым, им-том, шомлану кебек әкиятләрнең йөзләре ачылды. Монархия заманында гыйлем һәм аннан мәхрүм булган, наданлыкта пыскып яткан һәм Ислам диненең нәрсә тәгълим иткәнен дә белмәгән, күрмәгән бичара җансыз татар муллалары да күзен ачты һәм Ислам хакыйкатенә йөзен юнәлдерә башлады.

1917 елда вакытлы хөкүмәттән соң большевиклар идарә кыла башлагач, милли матбугат ябылды һәм «Шура» туктатылды. Ниһаять, 1918 елда Риза хәзрәт яңадан казыйлыкка сайланды. Гражданнар сугышы вакытында һичбер якка тайпылмыйча, дөрес хезмәт итеп, Нәзарәтне һәм аның милкен яхшы саклады. Шунлыктан Галимҗан мөфти аның эшеннән разый булып, аның хакында түбәндәгечә әйтәдер: «Соңгы заман халкы өчен мәтен (таяныч) буларак бәян кыламын – Ризаэтдин бин Фәхретдиннең куәт гыйльмиясе вә әдәбиясе галидер (бөек). Иң мөһим булган хәдис аңа дөрес рәвештә яхшы бирелгән. Тарих һәм тәрҗемә хәлендә дә дөрес мәгълүмат ияседер, дини вазифасында нык торучыдыр. Холкы күркәм, йомшак күңелле, аз сүзле, күп эшләүчән. Һәркемгә изге теләктә, дөрес сүзле зат, табигатендә төзек, фикере югары. Шунлыктан тәнкыйть фөкрен сөючән туры бер затдыр. 1920 ел, мөфти Галимҗан Баруди. Тәхсин тәмам».

Менә шундый халык арасында һәм мөфтиләр тарафыннан хуп күрелгән һәм мактауларга лаек булган зат иде. Шулай мөфтилеккә сайланып, бу хезмәтен үтәгәндәге хезмәтләре…

1925 ел башларында Диния нәзарәтенең биналарын һәм архивларын бушату хакында Уфа губерна исполкомы тарафыннан приказ бирелде. Шул ук көнне мөфти Ризаэтдин ашыгыч рәвештә аларга ачык хат язды.

## Мөфти Ризаэтдин бине Фәхретдиннең әҗәл авыруы

1936, 1354 нче һиҗри елда мөфти әҗәл авыруына дучар булды. Бу көннәрдә илебездә тормыш гаять дәрәҗәдә авыр иде. Һәрьяктан тынычсызлык, көрәш, ачлык хөкем сөрә иде. Икмәккә чират зур һәм ул юк. Мөфтинең дә тормышы җиңел түгел. Диния нәзарәте ихтиярый иганә белән генә яшәгәнгә, шундый авыр елда нинди ихтиярый иганә булуы мөмкин соң?

Мөфтигә авыру тигәч, табибларның да ярдәме җитмәслек булу да аңлашылды. Төрле яктан голәмәләр хәл белергә җыйналды, һәм хәзрәт вафатыннан соң, бу вазыйфага кем лаеклы, дигән фикер алышулар башланды.

Мөфтинең урынбасары итеп, җыелышта Кәшшаф казый сайланган иде. Ул күп тәҗрибә күргән һәм озак эшләгән казый да иде. Шулай булгач, ашыгып мөфтилеккә кеше эзлисе дә юк иде. Ләкин моңа каршы килүче затлар булу сәбәпле, ата-бабадан калган гадәт кебек көнчелек-каршылыклар эшкә зур комачаулык китерде. Казыйлар арасыннан Зияэддин Кәмали һәм Мәһди Мәгъкулыйлар Кәшшаф Казыйга каршылык күрсәттеләр. Бу эш түшәктә яткан авыру мөфтигә бик нык тәэсир итте. Мөфти Казаннан Шәһәр Шәрәф мулланы чакыртып казыйларга, мулллаларга карата бер васыятьнамә яздырды. Урыныннан торып, калтыраган кулы белән имза кылды. 1936 ел, 3 нче март миладе, 1354 һиҗри. Ләкин каршы торучы Зияэддин Кәмали, Мәһди Мәгъкулыйлар васыятькә дә каршы булдылар, нәсыйхәтне кире кактылар. «Расүлуллаһи үзе дә үлгәндә урынына кеше билгеләмәде» диделәр, дәгъва чыгардылар. Васыятьнамәгә кул куймадылар. Бу эш Кәшшаф Казый планы диделәр.

Шулай итеп, халык арасында һәм авыру мөфти күңлендә зур тынычсызлык тудырдылар. Мөфти бу хәлгә бик кайгырып ятты. Шул васыятьнамәдән бер ай гомер узгач, 1936 ел 8 нче апрельдә, 1354 нче һиҗридә Ислам кабул иткән бәйрәм көнне, мөфти үзенең яткан

бүлмәсенә казыйларны чакырып, васыятьнамәне укыды. Кәшшаф казый вәсыятьнамәне укыганда бик ихлас белән тыңлап утырды. Соңрак мөфти: «Инде бер иттифакка килегез, Диния нәзарәтен тыныч саклагыз», – диде дә, бәхилләште. Нәсыйхәткә өстәп: «Күп еллардан бирле мөфтигә наиб (наместник) булып эшләгән тәҗрибәле казый Кәшшаф Тәрҗемани мөфти сайлау мәҗлесенә кадәр мөфтилектә хезмәт итсен һәм шуңа разый булып язылган протоколга кул куярсыз», – дип тәмам итте. 8 нче апрельдә протокол язылды, мөфти калтыраган кулы белән имза куйды. Казыйлардан Кәшшафлар, Мөхлисалар кул куйдылар, әмма баягы Зияэддиннар, Мәһдиләр кул куймадылар. Халык арасында тәшвиш туды, күп хатлар килде. Съездда сайланган наиб Кәшшаф казый файдасына халык күп иде. Шуннан соң 5 көннән, 12 нче апрельдә мөфти вафат булды. Җыелган халыкка зур мәсьәлә – мөфти сайлау иде. Кәшшаф казый эшне дәвам иттерсә дә, каршы як аны танымадылар.

Мөфти вафатын Кәшшаф казый Мәскәүгә телеграмма белән хәбәр итте. «Мөфти Ризаэтдин Фәхретдинов вафат. 1936 ел, 12 нче апрель. Урынына мин эшләп торам, тәсдыйк кылуыгызны үтенәм. Казый, наиб мөфти Кәшшаф Тәрҗемани». Казыйның телеграммын тотып каравылчы почтага китә, аңа ияреп шымчы Габдеррахман да бара. Каршылар Мәһди бүлмәсенә җыелып Габдеррахман тәкъдиме белән Кәшшаф телеграммына каршы Мәскәүгә икенче телеграмма җибәрәләр. Телеграммалар капма-каршы була: «Муфтий Фахрутдинов умер. На месте его Тарджиманов объявляет себя самовольно муфтием, которого мы протестуем. Члены собрания». Зияэддин Кәмали, Мәһди Мәгъкулый, Габдеррахман Расүли – менә бу затлар тарафыннан шундый хәсрәт вакытында, Мәскәүгә берсенә каршы берсе ике телеграмма килеп төшә. Мәскәү җавап телеграмма җибәрә. «Башкортстан И.П.К. Идарәсенә Устав буенча эш итәргә кушыгыз һәм тынычлыкны дәвам иттерегез», дип И.П.К. Идарәсе Краснов шуның буенча тынычлыкка боерык бирә.

15/IV 1936 елда Нәзарәт кассасыннан 3000 сум акча сарыф итеп, мөфти хәзрәтнең җәсәден Уфа зиаратенә дәфен кылдылар. Мөфтинең барлык китапларын нәзарәт китапханәсенә тапшырдылар. Абыстайга 5000 сум акча бирделәр. Иртәгәсен Зияэддин Кәмали, Мәһди Мәгъкулый эшкә чыкмадылар. Мөфтинең васыятен, наибнең карарын санламадылар, фетнә чыгардылар. Шуларга ияреп бер фирка нәзарәткә мөфти эзләргә керештеләр. Сайланган кеше була торып, кеше өстенә кеше (вә әсәфә, ни үкенеч).

Риасәтне сөймәүче дәрвиш табигатьле Зияэддин үзе мөфти була алмый. Мәһди алып бара алмый, Кәшшаф казыйны төшереп калдырып, кемне дә булса мөфти сайлау мәҗлесенә кадәр вакытлыча эшләп торучы итеп билгеләргә кирәк иде. Шулвакыт, шунда тыкшынып йөрүче Габдеррахман Расүлигә кемнеңдер тәкъдиме була. Шуны гына көтеп йөргән, аяк астыннан табылган бәхетне алып, кичекмәстән тиз кереп утыра һәм вакытлы мөфти булып эшли башлый. Үзара протокол язып, Башкортостан дини эшләр идарәсенә кертеп, тәсдыйк кылдыралар. Шулай итеп, мөфти сайлау мәҗлесенә кадәр генә дип кергән кеше, җыелыш ясамыйча, сайлау үткәрмичә, мөфтилек эшендә гомер итте. Бу Диния нәзарәтендә 9 нчы мөфти Габдеррахман Расүли.

Ризаэтдин хәзрәтнең матбугатта нәшер ителгән хезмәтләре 110 данә булып, басылмаганнары 10 том кулъязмасы булып тора. Уфаның Тел, әдәбият, тарих институты китапханәсендә саклана. Шуңа күрә мөәррих дип исем бирелгән.

*Габделхак хәзрәт Саматовның*
*«Милләтебездә Ислам дине» китабыннан*

# Иске Задур ишаны Әхмәтсафа Биккулов

Мин үзем туып-үскән Чүпрәле районы тарихы белән күптәннән кызыксынам. Башыннан күпне кичергән Шәйморза халкы үткәнен өйрәнгәндә, ерак түгел урнашкан Иске Задур авылыннан Ислам дине гыйлемен яхшы белүче Биккуловлар династиясе Вәлит, Фәтхулла һәм Сафа (Әхмәтсафа) турында материалларга тап булдык. Аларның кайберләре турында Р. Фәхретдиннең «Асар» китабында да язылган. Шәйморзадан читтә, Ташкент шәһәрендә төпләнгән атаклы авылдашлар Әбдерәшитовлар, Бәхтиевләрнең нәсел тармаклары Таджиевлар белән элемтәдә торабыз. Алар белән аралашып яшәүче София Биккулова (1950 нче елда туган), Әхмәтсафа Биккуловның оныгы Мидхәтнең кызы. Мәшһүр бабасы Әхмәтсафа турында шактый материалларны һәм истәлекләрен безгә җибәрде. Шактый ук олы яшьтә һәм сәламәтлеге дә мактанырлык булмаса да безнең белән электрон почта аша элемтәдә булды. Районыбыз тарихчысы булган Р. Субаев китабында ишанның үзе һәм ул яшәгән чор турында шактый язылган. Ниһаять, Биккуловларның Әбүбәкер хәзрәт аша Иске Шәйморза белән бәйләнешләре ачыкланды. Шулай итеп Сафа Биккулов турында аерым мәкалә язу зарурлыгы килеп чыкты.

Иске Задур авылында XX гасыр башларында бик танылган ишан хәзрәт Әхмәтсафа яшәгән. «Иске Задур ишаны» дигән исеме Татарстаннан ерак җирләрдә дә билгеле булган.

«Татар энциклопедик сүзлек»тә язылганча (рус басмасының 535 нче битендә) Задур авылы Казан ханлыгы заманында ук барлыкка килгән. 17 гасырның 2 нче яртысында авылның бер өлеше көнчыгышкарак китеп, Имән елгасы буена урнашалар. Бу авыл Яңа Задур дип атала. Иске һәм Яңа Задур авыллары Сембер губернасы Тогай өязенә кергән.

Иске Задурның иң зур вакыты (400 йорт) 1932 елларда була. Яңа Задурда 1997 елда 66 кеше яши. Иске Задурда 2 мәхәллә – ике мәчет була. Беренче мәчетнең салынган елы билгеле түгел, аны картлар әйтүе буенча, Уби авылы хәллеләре салдыра. Икенче мәчет 1923 елда хәзерге мәчет торган урын тирәсендәрәк салына.

Бу авылга мулла булып 1801 елда Вәлит Биккулов килә (Яңа Чокалы яисә Яңа Тинчәле авылыннан дип уйлыйбыз). Шуннан берничә буын Биккуловлар бу авыл мәхәлләсен генә түгел, ә тирә-як авыл халкын да дин кануннары буенча тәрбияләп киләләр. Авыл картлары сөйләвеннән, буласы ишан Сембер губернасы (хәзерге Ульяновск өлкәсе) Тимерчән авылында яшәүче әнисе Әхмәтсафа яшь вакытта Иске Задур хәзрәте Фәтхуллага кияүгә чыга, үзе белән ияртеп малаен да алып килә. Әхмәтсафа үсеп җиткәч авылда хәзрәт булып кала. Икенче мәчет салынгач, анда имам булып Әхмәтсафаның улы Фәтхелкадыйр билгеләнә.

Әхмәтсафа үз тирәсендә зур гыйлемлеккә ия булган зыялы галимнәр, муллалар белән аралашып, ил-көндә барган хәлләрен анализлап, үз фикерен белдереп яшәүче акыл иясе була. Казан мәдрәсәләрендә белем алган, 30 ел буена авылда халыкны дингә эстәп, йолаларын өйрәтеп, ихтирамын яулаган. Октябрь революциясенең дингә каршы сәясәтен һәм аның нәтиҗәсендә авыл крестьяннарына файда булмавын сиземләгәнгә ул яңа властьны өнәмәгән. Урыны һәм җае туры килгәнгә яңа хуҗаларның халыкка булган мөнәсәбәтен тәнкыйтьләрлек кыю кеше булган.

Авыл халкы аңа дини бурычларны үтәү генә түгел, ә тормыш-көнкүреш, дөньяви зарурияте буенча да киңәш, ярдәм сорап килгәннәр. Ишанның йогынтысына Буа кантонының Чүпрәле һәм Городище волостьлары мөселманнары чын күңелдән табынган була. Сөйләшер өчен ишан янына Чуваш иленнән, Сембер ягыннан да килгәннәр. Киңәш сораучыларның фикер алышу үзәгендә дин мәсьәләләре булса да, илдә барган үзгәрешләр, икмәк әзерләү, салым сәясәте турында сүз булмый

калмаган. Мондый темага 1929 елларда бәхәсләр һәр авылда барган. Гомер буе әхлак һәм гореф-гадәтләр кануны булган динне кинәт халык тормышыннан кысрыклап чыгару дин тотучыларда ризасызлык тудырмыйча калмаган. Динне социалистик идеяләрнең дошманына әверелдерүне болай кисәк гамәлгә ашыру большевикларның зур ялгышуы булуын ул вакытта ук аңлаучылар, әлбәттә, булган. Динне кысу, күтәрә алмаслык салымнар, авыл хуҗалыгы продукциясен бирергә, әгәр бирмәсәләр көчләп алырга, юк акчадан заемнар түләтү – халык арасында яклау тапмаган.

Әхмәтсафа буйга 180 см. дан артык, мөселманча чал сакал-мыеклы, ачык зәңгәр күзле була. Ул электән татар халкы киенгән киемнәрне кия. Башында түбәтәй, аякларында йомшак күн читекләр, өстенә озын сулдан уңга каптырмалы ак күлмәк, аның өстеннән татарча бишмәт була. Гомерендә тәмәке тартмаган һәм аракы да эчмәгән. Электән килгән гадәт һәм дини кануннар нигезендә фотога төшүне гөнаһ санаган, шуңа күрә аның төшкән фотолары юк. Физик яктан нык, таза булган.

Биш вакыт намазын калдырмаган. Иртән торып, тәһарәт төзеп, чиста кием-салым кигән һәм мәчеткә намазга барган. Намаздан соң мәчеткә җыелган халыкка хак Ислам дине тарихыннан кыйссалар сөйләгән. Кичке намаздан соң тормыш-көнкүреш темаларына фикер алышу булган. Халык ишанны югары дәрәҗәдәге әхлак нигезләре, төпле дини һәм хуҗалык белемнәре, кылган яхшылыклары һәм акылы өчен хөрмәт иткән. Гади халык аңарда хәтта алдан күрү сәләте бар иде дип сөйлиләр.

Аның таланты, логик фикерләү һәм тирән акылы мисалы итеп ТАССР ГПУы өчлеге утырышының 14 гыйнвар 1931 ел протоколын китерергә мөмкин. Биредә Әхмәтсафа: «Коммунизм – ул фантазия, без аңа беркайчан да җитмәячәкбез», – дип әйтә. Бу сүзләр ишанны гаеплəү өчен китерелә. Ә ул вакытта бу сүзләрне бик акыллы һәм дөреслек яратучы кеше генә әйтә ала.

Бу дөреслекне инде тормыш үзе раслады.

Сафа хәзрәтнең әтисе Фәтхулла зур Ашыт мәдрәсәсендә белем ала һәм аның әтисе Вәлид Ш. Мәрҗани хезмәтләрендә телгә алына. Ишан хәзрәт зур агач өйдә яши. Биредә, кабинетта, язу өстәле, диван һәм китапханә тора.

Ишан хәзрәт күп күләмле җирләрдә авыл хуҗалыгы эшләре алып барган, моның өчен шактый гына атлары була. Кыр эшләрен башкару өчен Сафа сезонлы һәм даими эшчеләр тота. Гаиләдә ир-атлар һәм эшчеләр зур казанда пешкән азыкны бергәләп ашыйлар. Биредә эшчеләр гаилә әгъзалары белән бер дәрәҗәдә йөриләр. Сафа крестьян хезмәтен үзе дә яратып башкара.

Һәр пәнҗешәмбе көнне Иске Задурга ишан янына халык җыела. Намаздан соң дөнья хәлләре турында сөйләшү була. Әле күптән, революциягә кадәр гадәткә керткән шушы фикер алышу өчен ГПУ Сафаны «Халыкны Советларга каршы котырта» дип гаепли.

Властьларның «Яңа тормыш төзибез, алда безне бәхет көтә» дигән сүзләренә халык ышанмый. Өстәвенә 1921-22 елларда Идел буенда булган ачлык афәте әле халыкның исендә, күңелгә нык кереп калган гарасат була.

Вакыйгалар үсешен академик И. Р. Тагировның «Очерки истории Татарстана и татарского народа» китабына нигезләнеп бирәбез. Очерк башлыча КГБ РТ да саклanучы документлардан алып язылган. ГПУ тикшерү уздыра һәм гаепләү нәтиҗәләре чыгара. Бу документның тулы исеме «Обвинительное заключение по делу контрреволюционной организации, состоявшей из Ново-Чукальской, Старо-Чукальской, Старо-Шаймурзинской, Ново-Ильмовской, Татарско-Саплыгской, Ново-Ишлинской, Чекурской и Каракитанской кулацко-мульской группировок». «Эш» Татарстан ГПУы начальнигы Кандыбин Д. Д. тарафыннан имзаланган. 63 биттән торган эшнең 5 бите җавапка тартылган кешеләр исемлегеннән гыйбарәт.

1929 ел Биккуловлар гаиләсе өчен авыр сынаулар алып килә. Тирә-як авылларда хәлләр кискенләшә. Оештырылган җыелышлар нәтиҗә бирми, аның урынына кире эффект бирә башлыйлар. Мәсәлән, Иске Шәйморза авылы җыелышларында крестьяннар: «Безгә мондый икмәк хәзерләү кирәкми, безнең үзебезгә дә икмәк җитми. Нигә кулакларга икмәкне бетереп тапшырырга кушасыз, ә бит алар безгә ачтан үләргә бирми. Власть безне буа һәм налоглар белән кыса, ә үзләреннән бернинди файда юк. Совет власте безне чишендерә һәм вәгъдәләр белән сыйлый». Шундый ук диярлек ситуация башка авылларда да килеп чыга.

Төп группировка итеп ГПУ Яңа Чокалы авылы крестьяннарын гаепли. Аларның башында мулла Шакир Галлямов тора, аның белән бергә хатыны Сараны (Сафа Биккуловның кызы) һәм кызы Әминәне гаеплиләр. Аларның активлыгы аркасында колхозларга каршы хәрәкәт башлыча хатын-кызлар кулына күчә. Алар хатын-кызларны өйләреннән куып чыгарылучы авылдашларны, мулла-мөәзиннәрне яклау, мәчетләрне авыл җыены «карары» буенча ябуга каршы көрәшкә өндиләр.

1929 нчы елның декабрендә Яңа Чокалы авылында узган җыелышта Фәхретдинов Шакир: «Безнең авылда Сталин яки Калинин үзләре килеп үгетләсәләр дә колхоз оештыра алмаслар, сәнәкләр белән каршы торачакбыз, безгә барыбер үлем, яки хәзер, яки колхозда», – дип җыелышны тарката.

Татар Саплыгы авылында 1930 елның октябрь аенда колхоз төзиләр. Кулак семьяларын читкә озату мәсьәләсе туа. Читкә озатучыларны яклап хатын-кызлар чыга. М. Валиханова, Н. Кәлимуллина, М. Хәйруллова һәм Мөкәтдәсова йортлар буйлап йөреп сельсоветка җыелырга өндиләр. Хатын-кызлар сельсоветка җыелалар һәм биредә «Долой колхоз» өндәмәләре яңгырый. Шул вакытта крестьянин Мифтахетдинов үз тирәсенә 25 ләп кеше җыеп, заемнарга каршы агитация алып бара.

Түбән Чәке авылында Муратова Шәрифзадә активлык күрсәтә. Ул партия члены һәм укытучы буларак, колхозларга каршы хәрәкәт башында була. Мәчетләрне киредән кайтару өчен көрәш башлый. Хатын-кызлар мәчетләргә эленгән кызыл флагларны алалар, булган портретларны һәм плакатларны тар-мар итәләр.

ГПУ эшне башлыча Иске Задур ишаны Әхмәтсафа һәм аның иярченнәре тирәсендә башлап җибәрә. Әхмәтсафа халыкның дини остазы, киңәшчесе буларак илдә һәм авылларда барган хәлләрдән хәбәрдар булганы ачык. Менә аның бер чыгышы: «Мөселман дине һәртөрле иректән мәхрүм ителде. Ахыргы вакытта без мәктәпләр ачуны кире кагу һәм эшләп торганнарын ябу, дингә бирелгән кешеләрне кулга алу, салымнарны бу кешеләргә чамасыз арттыру, икмәкне көчләп тартып алу һәм көчләп облигацияләр тарату кебек күренешләрне күзаллыйбыз. Динне мондый һөҗүмнәрдән яклау өчен без нәрсә дә булса эшләдекме? Әйтергә кирәк юк, без йоклап яттык».

Бу сүзләр ишанны советларга каршы агитациядә гаепләү өчен кулланыла. Әмма биредә Совет властен бәреп төшерергә яки хәрби көч куллануга чакыру юк.

ГПУ процессның көчәюен диккать белән күзаллап тора һәм крестьяннарның совет властена каршы күтәрелүеннән куркып торганга зур масштаблы операция үткәрергә карар итә. Крестьяннарның иң авторитетлы активистларын кулга ала башлыйлар.

Иң беренче итеп 12 январьга каршы төнне Сафа Биккулов кулга алына. 12 кешедән торган опергруппа Яңа Чокалыга килгәндә авылда җыелыш бара. Группа Ш. Галлямовны һәм аның белән 5 кеше активистларны кулга алып, мәктәп бинасына ябып куя.

Бу вакытта Ш. Галлямовның хатыны Сара һәм кызы Әминә авыл буйлап, «Каравыл, разбой» сүзләрен кычкырып, авыл халкын кузгатып йөриләр. Хисмәтуллова җыелыш барган җиргә кереп: «Мулланы кулга ал-

дылар», – дип кычкыра. Бу сүзләрдән соң халык мәктәпкә ташлана. Тиз арада 800 ләп кеше җыела, кызлар һөҗүм чараларына кучәләр. Ике сәгать буе камалып торган опергруппа мәктәп баскычына Галлямовны чыгара. Төркем мулланы кулларына күтәреп өенә таба алып китәләр. Шул вакытта икенче группа чекистлар икенче мулла Гафуров Кадыйрны тотып киләләр. Халык Гафуровны да азат итә, муллаларны өйләренә кайтарып җибәрәләр. Мәктәп янында хәл кискенләшә, халык басымы арта бара. Милиция калган кулга алынганнарны да җибәрергә мәҗбүр була, аннан соң авылдан да чыгып ук китә.

Бу хәлләр крестьяннарның властьлар белән капма-каршы торуының апогее була. Яңа состав белән көчәйтелгән опергруппа тирә-як авылларда активистларны яңадан кулга ала башлый.

1930 нчы елның икенче яртысыннан 1932 нче елның азагына кадәр Татарстанда 498 мәчет һәм 70 чиркәү эшләүдән туктатыла (Хәйри Ә. Хак тарихыбыз хакына // Сөембикә. – 1991. – № 4.).

Түбәндәге мулла-мәәзиннәр бу елларның репрессия корбаны булдылар:

Иске Шәйморзадан – Әсәдулла Абаев, Мөхәммәт Рәшидов (атылган), Әбүбәкер Мәхмүдов (хәбәрсез югалган), Фәезрахман Бәрхиев (атылган);

Яңа Чокалыдан – Кадыйр Гафуров (атылган);

Иске Чокалыдан – Шиһаб Әхмәтов;

Чүпрәледән – Садыйк Әхмәтов;

Татар Убиеннан – Сафа Вәлишев;

Зур Чынлы мөтәвәлие Хисаметдин Бәдретдинов;

Кече Чынлы авылыннан – Хөҗҗәт әл Ислам Хөсәенов (беренче мәчет имам-хатыйбы, атылган), Идиятулла Абдуллин – Коми АССР лагерьларына җибәрелә, шунда һәлак була һ. б.

ГПУ тарафыннан кузгалтылган эш Солтангалиевнең икенче аресты һәм «Мәскәү үзәге» эше белән дә бер үк вакытка туры килә. Солтангалиев

эше буенча суд җаваплылыгына татар педагогы, тарихчы һәм җәмәгать эшлеклесе Һади Атласов тартыла. Яңа «эш» буенча Буа якларында туып үскән, хәзер Казанда яшәүчеләр һәм туган як белән араны өзмәүчеләр репрессияләнә. Фабрикацияләнгән эш буенча Ибраһим Биккуловны, Касыйм Биккуловны, Шиһаб Әхмәровны җавапка тарталар.

Бу юлы Касыйм Биккулов гаепләү материаллары җитмәү аркасында Уфа шәһәренә китеп, репрессиядән котыла.

Халык репрессияләргә каршы торып карый. Бу аеруча Рәшитов Мөхәммәтне кулга алганда күренә. Оператив группа авылдан чыгып китүенә комачау ясау планы белән Чынлы елгасы аша салынган күперне сүтәләр. Сүтелеп бетмәгән өлешенә салам аударып, ут төртәләр (Иске Шәйморза авылы). Күпер янып китә алмый.

Оператив группалар бернигә карамый алдан билгеләп куйган эшләрен башкаралар.

Бу хәлләрдән соң Иске Задурда ике мәчет тә ябыла, имамнары юкка чыгарыла. Татар Төкесендә, Иске Чокалыда 6 мәчет, Иске Шәйморзада 6 мәчет, Кече Шәйморзада 1 мәчет, Зур Чынлыда 4 мәчет, Кече Чынлы мәчетләре, Яңа Ишледә 2 мәчет, кыскасы, һәр авылда мәчетләр эштән туктатыла. Кайбер авылларда муллалар дингә каршы капмания башланасын ишетү белән үзләре эштән китүләре турында властьларга белдерәләр һәм кайсы кая тарала.

Сафа Биккуловны кулга алгач ул 13 ай диярлек Казан төрмәсендә утыра. Шунда ук аның белән бергә улы Фәтхелкадыйр да була. Ул вакытларда төрмәдә бик кысан, кешеләр камераларда шыпылдап тутырылган.Савыт-саба, койкалар, хәтта кайнаган су да җитешми, санитария таләпләре аннан-моннан гына үтәлгән, камералар пычрак. Әлбәттә, 75 яшьлек карт кешегә бу бик җитди сынау була. Алай да Әхмәтсафа кеше өстенә яла якмый. Барлык авырлыкларны үз өстеннән кичерә, Аллаһы Тәгаләдән генә ярдәм сорый. Мөселман кешесенә тиеш булган гамәлләрне башкара килә.

1931 елның 14 январенда Татар ОГПУы тройкасы иң югары хөкем чарасы – атырга карар чыгара. 1931 елның 25 февралендә Казан шәһәрендә бу хөкем үтәлә. Шулай итеп, хак динебез өчен Сафа Биккулов үзенең гомерен бирә.

Центр генеалогических исследований дигән документта «Казан шәһәренең Архангел зиярәтендә бу хөкем үтәлде», дип язылган. Әхмәтсафага каралган бу чаралар «Хәтер китабы»ннан алып язылды. Димәк, бу язмышка нокта куелган. Тик шулай да халык арасында һәм Әхмәтсафа туганнары арасында йөри торган бер риваятьне сөйләми китми булмый. Моңарга нигез дә юк түгел.

1931 елда Иске Задурга күрше чуваш авылыннан элек Казан төрмәсендә сакчы булып эшләгән кеше кайта. 1931 елда ул конвой составында 3 кешене төнге сәгать 2 дә атарга алып килә. Тоткыннарның берсен ул таный, бу Әхмәтсафа ишан була. Процесс барганда ишан эзсез югала, аның гәүдәсен дә таба алмыйлар. Камерада бары тик кул таягы гына калган була. Төрмәдә тикшерүләр үткәрәләр, шау-шу куба. Тик боларның берсе дә нәтиҗә бирми.

Бу хәлләрдән соң сакчы чуваш биредә бүтән эшли алмый, расчет алып, туган авылына кайтып китә. Мөселман булмаган бу кешегә шушы вакыйганы уйлап чыгару бернигә дә кирәкми. Халык: «Шундый чиста күңелле, пакь кешене Аллаһы Тәгалә мыскыллауга юл куймыйча, Үзе янына күккә алган», – дип сөйлиләр. Гаип булды – юкка чыкты, күккә ашты дигән мәгънәне аңлата. Бу риваять, бердән, халыкның ишан хәзрәтне олылавын күрсәтә. Икенчедән, ишанның нәсел тармаклары һаман күңел түрендә янып торган өмет чаткысын сүндерми яшиләр.

Дөньяда җан ияләренең бер өлеше – Адәм балаларына Аллаһы Тәгалә өмет бүләк иткән. Өмет – ул караңгыда янып торган ут кебек кешегә юл яктыртып тора. Өмет көчле салкыннарда җанны җылытып торган учак чаткысы кебек. Өмет белән, адәм баласы Аллаһы Тәгалә ярдәменә тая-

нып барлык авырлыкларны җиңеп чыга. «Өметсез – шәйтан», диләр. Әхмәтсафа нәсел тармакларының бабалары бүтән язмышка дучар булып, исән калгандыр дигән өметләренә ышанасы килә. Аллаһы Тәгаләдән аларга ярдәм һәм сабырлык сорыйк.

Татарстан ОГПУ начальнигы Д. Я. Кандыбин операция нәтиҗәләре турында доклад ясаганда, Галлямов хатыны Сараны, Ибнеаминова Сараны һәм Яңа Чокалыдан 6 кешене атырга ОГПУ рәисе урынбасары Ягөзидан рөхсәт сорый. Бу сорау канәгатьләнми кала (Р. Кашапов).

Хәзер Сафа һәм башка «халык дошманнары»ның гаиләләре күргәннәр турында язып китик. Хәзерге көндә Ташкент шәһәрендә яшәүче Сафия Биккулова болар турында шактый тулы итеп язып җибәргән.

Иң югары чарага хөкем ителгән Сафаның бар мөлкәте тартып алына. Гаиләсе Себергә сөрелә. Шундый ук язмыш Фәтхелкадыйр гаиләсен дә көтә. Сара Галлямова 10 ел концлагерьга, Әминә 8 елга хөкем ителә.

Сафаның хатыны Мәхфүзә абыстай 1973 нче елда туган (Шакир Галлямовның апасы, Яңа Чокалы авылыннан). Физик яктан таза, урта буйлы һәм изге күңелле кеше була. 12 бала тудыра, шуларның алтысы исән кала. Уллары Фәтхелкадыйр, Вафа һәм Вәли. Кызлары Әминә, Сария һәм Камәрия. Сара – Сафаның беренче хатыныннан, Шакир Галлямовка кияүгә чыккан.

Сафаның икенче кыз туганы Хөсниҗамал һәм Гайни. Хөсниҗамал Мучәли авылыннан Сәгъдетдин Субиевка кияүгә чыга. Гайнинең кияве Иске Кәкерле авылыннан Хәсәнов.

1929 елда ачлык, корылык була, игеннәр уңмый. Югарыдан бирелгән үтәп булмастай икмәк бирү йөкләмәсен үтәү өчен җирле властьлар һәр крестьян йортында тентү үткәрәләр. Ашлыкны гына түгел, чәчүлек орлыкны, хуҗалык инвентарен көчләп алалар. Йорт хуҗаларын (хәлле крестьяннар, кулак саналган таза тормышлы кешеләр) өйләреннән урамга куып чыгарылалар.

Мәхфүзә әбине семьясы белән Чита өлкәсенә сөрәләр. Балалары белән тайгада урман кисеп, үзләренә яшәү өчен барак төзиләр, шахтада эшлиләр. Авырлыкларга түзә алмый тиздән Мәхфүзә әби үлә. Ахырдан санап карыйлар, ул хәләл җефете Сафадан бер атна гына яшәгән икән. Кызлары бер караучысыз кала, аларны үз канаты астына абыйлары Вафа ала. Ни кызганыч, Вафа Биккуловны да анонимка нигезендә лагерьда яңадан суд ясап, 58-2 статьясы буенча аталар (1938).

Сара Биккулованы (Сафаның беренче хатыныннан туган кызын) – 10 ел лагерьларга хөкем итәләр.

Фәтхелкадыйр (Сафаның икенче хатыныннан туган улы) – 5 ел лагерьга хөкем ителә.

Вәли – 5 ел лагерьга хөкем ителә.

Вафа, Әминә, Камәрия һәм Сария – спецпоселениегә җибәреләләр.

Идиятулла Абдуллин Кече Чынлы авылы имам-хатыйбы Әхмәтсафа белән берничә буын кодалык җепләре белән бәйләнгән. Әхмәтсафаның Яңа Тинчәледән туганы – Маһирә Биккулова Идиятулланың хатыны. Идиятулланың бертуган абыйсы Сафиулла – Ш. Мәрҗанинең кызы Галиянең кияве. Шуңа күрә Маһирәнең кызы Нәфисә Казан шәһәрендә Галиянең кызлары белән уйнап үсә, шул вакытта Аитовларның хатын-кызлар гимназиясендә укый. Вакыты җиткәч Нәфисә Абдуллина белән Фәтхелкадыйр Биккулов гаилә корып җибәрәләр. Шулай итеп, ике кат туганлык җепләре белән бәйләнгән нык семья барлыкка килә.

Репрессияләр ташкыны вакытында Идиятулла Абдуллинны Әхмәтсафа белән бервакытта диярлек кулга алалар. Алар икесе дә ишаннар булып, күп санда мөритләре була. Берничә мәртәбә хаҗ сәфәрендә булып, мөселман дөньясында дәрәҗәле кешеләр булганнар. Идиятулла Коми АССР лагерьларында 1932 елда үлә.

Спецпоселениегә хөкем ителгән Маһирә әби һәм Нәфисә Биккулова (Абдуллина) гаиләләре белән Себергә озатылалар. Бу гаиләләр башка

берәүләр кебек качып котылу ягын карамыйлар, чөнки үзләрен гаепле санамыйлар. Бик күп михнәтләр чигеп, Чита өлкәсе Могочинский районы Кудеч поселогына килеп җитәләр. Биредә ике кытайлылар йортыннан башка бернинди дә торак булмый. Поселениегә килүчеләр землянкада яшәп, үзләре өчен торырга урман кисеп, барак салалар. Бер баракта 10-12 гаилә яши, бер-берсеннән ситца чаршау гына аерып тора. Баракта салкын, пычрак, тәрәзәләргә боз ката. Кешеләр, аеруча, балалар еш авырыйлар. Сөрелгән халык алтын рудникларында эшлиләр. Халыкны зәңгелә (цинга) авыруы газаплый, чи бәрәңге ашап котылалар.

Нәфисә апайның үзе белән ике улы була. Зурысы – Мидхәт олылар белән бергә алтын комы юа. 100 кг. ком сыешлы 100 бадьяны эшкәртергә норма куелган була.

1931 елда Фәтхелкадыйр хөкем ителгән лагерь срогын спецпоселениегә алыштыралар һәм ул да монда килә. Зур гәүдәле Кадыйрның аяк киеме үлчәме 46 була, шуңа да аяк киеме буенча һәрвакыт проблема чыгып тора. 1943 елда Кадыйр бозда таеп егыла, кулы сына һәм йөрәк өянәге кузгала. Шул сәбәптән февраль аенда үлә.

Мидхәт укырга хирыс була һәм комендатурага әйтми генә техникумга документларын җибәрә. Техникум аның укырга керүе турында чакыру кәгазе җибәрә. Кәгазь комендатурага килә һәм зур гауга килеп чыга. «Халык дошманы» улына укырга ярамый икән. Сәләтле Мидхәт өчен бу зур бәрелеш була, алай да кешенең табигате үзенекен ала икән. Мидхәт сугыш рационализаторлык эшен дәвам итә. ВДНХга чакырыла һәм «Үзбәкстанның атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исемгә лаек була.

1941 елда танк бронясын ясау өчен заводларга молибден җитешми башлый. Халыкның барысын да молибден рудникларына куалар. Молибден рудасын көл хәленә китереп ваклыйлар һәм су белән юалар. Гаилә үсмер Җават өчен кайгыра, чөнки аны да молибден юарга куялар. Руданы тездән салкын суда баскан килеш юалар, балалар берничә айга гына чы-

дыйлар. Әнисе Нәфисәнең догалары Аллаһы Тәгаләгә барып ирешкәнме, күпмедер вакыттан Җаватны десятник итеп куялар. Шулай итеп аның тормышы сакланып кала һәм гомерлек һөнәре – бухгалтерлыкка юл ачыла.

1945 елда кисетүләргә чыдый алмыйча Җават ышык урында каравыллап, комендант Крестьяновны кыйнап ташлый һәм документларсыз поездларга утырып Россиягә кача. Юлда аны, әлбәттә, тоталар. Ул үзен Беллоруссиядән качкын дип башка фамилия белән атый. Алты ай утырып, тикшерүләр үтә һәм ireккә чыга. Яңа исемдә паспорт алуга ирешә. Ашхабадта сәүдә техникумын бетерә һәм берничә елдан үз фамилиясен кире кайтара.

Мидхәт 1941 елда фронтка китәргә сорый, әмма рөхсәт булмый. Сталинград сугышларыннан соң 1942 елның октябрендә ниһаять рөхсәт килә.

1944 елда ул үпкәсе яраланып, Тбилиси госпиталендә дәвалана. Шунда Җиңү бәйрәмен каршылый. Сугыш бетү аркасында аны армиядән демобилизациялиләр. Коры климатлы Урта Азиядә яшәргә киңәш ителә (ярасы үпкәсендә була).

Мидхәт Урта Азиядә төпләнә. Аннан хатыны Нәфисә һәм балалары аның янына җыелалар.

Мәкаләбезнең бәян ителгән өлешенә нәтиҗә ясап, болай дип әйтергә мөмкин: бу хәлләрдән соң инде күп сулар акты, динебез әһелләренә һәм гаиләләренә карата кылган гамәлләр ялгыш дип табылды. Милекләре дәүләтнеке итеп авылдан сөргенгә сөрелгән, һәртөрле авырлыклар һәм җәберләүләр кичергән гаиләләр 1960 һәм аннан соң елларда тулысы белән акландылар. Шул исәптән, Әхмәтсафа ишан 1998 елның 16 сентябрендә реабилитацияләнде. Халык күңелендә бу кеше хак динебез өчен гомерен аямаган, туры сүзле, дөреслек яратучы булып калды.

* * *

2016 елның 22 мае көнне Иске Задур авылында тантаналы рәвештә авыл җыены үткәрелә. Бу турыда мәгълүмат бирүче, җыен үткәрүне башлап йөрүче, төп оештыручыларның берсе – авыл имамы Шәүкәт Алиуллин булды. Җыен турында мәгълүмат халык арасында киң таралды. Татарстан телевидениесе дә бу турыда хәбәр бирде. Мәкаләнең авторы соравы буенча журналыбыз редакциясенә Ш. Алиуллин мәгълүмат җиткерде. Бу язмалар шуңа таянып язылды.

Бәйрәмне Коръән аятьләре белән хәзрәт Шәүкәт Алиуллин башлап җибәрде. Үзенең вәгазендә Иске Задур мәчете төзелгәнгә 25 ел булуын әйтте. Бу изге эшне башкарып чыккан колхоз рәисе мәрхүм Вәгыйз Алиулловка, төзелешкә иң зур өлеш керткән Мәсум һәм Мидхәт Хузеевларга, Тәүфикъ Шәйхетдиновка (мәрхүм) бөтен авылдашлардан рәхмәтен җиткерде.

Район хакимияте башлыгы А. Шадриков, район мөхтәсибе Р. Ракипов, Әхмәтсафаның оныгы Рашат Биккулов, Рамил Шарапов, Ульяновск шәһәреннән Кәримә Алиуллина, Солтан Шәйдуллин чыгышлар ясап, кунакларны, авылдашларны сәламләделәр. Алардан тыш бәйрәмдә кунаклар – тарих фәннәре докторы Наил Таиров, профессор Иршат Гафаров, ислам дине магистры Камил Бикчәнтәев, РИУдан Габдулла Шәнгәрәев, Татарстан мөфтиятеннән Рөстәм Хәйруллин, Ильяс Җиһаншин, Ульяновскидан аксакаллар шурасы рәисе Варис Равиловлар, күп кунаклар һәм авылдашлар бар иде.

Әхмәтсафаның исән оныгы Рашат авыл халкын һәм килгән кунакларны сәламләде.

Чыгышында ул ишан хәзрәтнең өч улы, дүрт кызы, егерме оныгы һәм утыз оныкчыклары барлыгын әйтте. Моннан чыгып Әхмәтсафаның нәсел җепләре әле дә булса өзелмәгәнен күрәбез.

Рамил Шарапов үзенең чыгышында авылның тарихына экскурс ясады. Әхмәтсафа хәзрәтнең йорт-җире авыл халкына мәктәп булып хезмәт иткәнлеген әйтте.

Шуннан соң Ульяновск шәһәреннән Кәримә Алиуллина, Солтан Шәйдуллин чыгыш ясадылар.

Авыл җыенын әзерләгәндә авыл Советы депутаты Залалдинов Әнвәр, Хузеев Мидхәт, Каримов Илһам, Миначев Фаик, Алиуллин Нурислам, Хәйбуллин Марс, Хәлиуллин Фидаил һәм Фәргать, Әхмәтов Ильмас, Шарапов Шәфкат һәм башкалар зур тырышлык күрсәттеләр.

Бәйрәмнең тантаналы өлешеннән соң авыл кешеләре һәм кунаклар өйлә намазына мәчеткә узды. Намаздан соң кунакларны корбан ашы көтә иде. Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен 13 корбан чалынды. Коръән укыганнан соң мәшһүр хәзрәтебез, барлык әрвахлар рухына дога кылынды. Шушы Аллаһы йортына халыкның эзе суынмасын. Азан әйтелеп, биш вакыт намаз укылып, яшьләр дингә тартылсын иде дигән фикерләр әйтелде.

Авыл бәйрәмендә халык рәхәтләнеп ял итте, ничә еллар күрешмәгән авылдашларны, сыйныфташларны очратып, кайберләрнең күзләреннән яшь бөртекләре тәгәрәде. Автор һәм башкаручы Нияз Җәләлов үзенең җырлары белән сөендерде. Концерт программасын Чүпрәле мәдәният сарае һәвәскәрләре дәвам итте.

«Киләчәк еллар уңышлы, имин еллар булсын. Алдагы гомерләрдә бушка сарыф ителгән корбаннар булмасын иде. Барыбыз да сау-сәламәт, бәхетле булып, шат күңел белән матур тормышта яшик!» диеп алып баручы Тәслимә Замалетдинова бәйрәмне тәмамлады.

Бүгенгесе көндә авыл мәчете ишан Әхмәтсафа Биккулов исемен йөртә. Бу гамәл ишанның нәсел тармаклары һәм авыл халкы күңеленә бик хуш килде.

Файдаланылган чыганаклар:

1. Тагиров И. Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век) // Казань: Татар. кн. изд-во, 1999. – С. 261-270.

2. Татарский энциклопедический словарь // Казань: Институт тат. энциклопедии, 1999. – 535, с. 401.

3. Воспоминания С. М. Биккуловой по воспоминаниям своего отца и родни старшего поколения (2015 г.).

4. Алиуллин Ш. «Иске Задур авылы җыены» (2018 ел).

5. Кашапов Р. Мөселман руханиларына каршы репрессияләр // Шура. – 2018. – № 19. – 150-158 б.

6. Субаев Р. Чүпрәле: узган еллар, үткән юллар // Чүпрәле: 2010. – 319-323 б.

*Минзаһит Гимадеев,*

*Чүпрәле районы тарихын өйрәнүче һәвәскәр краевед,*

*КамАЗның атказанган хезмәткәре*

# Әш-шәех Зәйнуллаһ хәзрәтнең вафаты

*«Вакыт» тарафыннан нәшер ителгән тәрҗемәи хәл.*

Иннәлилләһи вә иннәиләйһи раҗигун!

28 нче гыйнвар тарихи илә Троицкийдан язылган бер мәктүптә: «Әш-шәехүл мөхтәрәм Зәйнуллаһ хәзрәт ике көннән бирле кәефсезләнеп тора. Картлык зәгыйфьлеге дә бар… уйламаган эшләр булырга мөмкин. Хәерле булса иде» дип язылган тәэсифле[1] хәбәр алынган иде. Уфада Оренбург мәхкәмәи шәргыясе даирәсеннән алынган бер мәктүптә һәм Зәйнуллаһ хәзрәтнең авыруы хәбәре барлыгы һәм шуннан элек кенә имамлыктан истигъфа кылып мәхкәмәи шәргыягә мәгъруда җибәргәнлеге зекер ителгән иде.

2 нче февральдә Зәйнуллаһ хәзрәтнең олуг мәхдүме имам вә мөдәррис Габдрахман әфәнде Расулев имзасы илә идәрәмезгә ошбу тәэсифле телеграм алынды:

«Әш-шәех Зәйнуллаһ хәзрәт бу көн (2 нче февральдә) вафасыз дөньядан дәр гокбага[2] күчте».

Мәрхүм Зәйнуллаһ хәзрәт дахили[3] Русиядә шәехлек наме[4] илә мәшһүр затларның иң олуг вә нөфүзлеләреннән[5] иде. Гасырымыз Русиядә Зәйнуллаһ хәзрәт кадәр мәшһүр вә нөфүзле бер зат күрмәгәндер диелсә, мөбаләга[6] булмас, шуның белән бергә Зәйнуллаһ хәзрәт бөек бер мәдрәсә тәэсис[7] итеп, заманында күп имам, мөдәррис вә хәлифәләр җитештергән олуг бер дини галимдер. Троицкийдагы Зәйнуллаһ хәзрәт мәдрәсәсе ошбу

1 Тәэсиф – күңелсез.
2 Гокба – Ахирәт.
3 Дахили – монда: дәүләт.
4 Нам – исем, ат.
5 Нөфүз – сүз үтемлелек, авторитет.
6 Мөбаләга – арттыру.
7 Тәэсис – төзү, оештыру.

көнгә кадәр дахли Русиядәге олуг мәдрәсәләрнең иң мәшһүр вә атаклыларыннандыр.

Зәйнуллаһ хәзрәт мәдрәсәсендә укып чыккан вә анда гыйльми һәм әхлакый тәрбия алган затлар бер Оренбург вилаятендә генә түгел, Русиянең башка вилаятләрендә дә күптер. Һәммә дә үз әкъраннары[1] арасында нөфүзле бер урын тотмактадырлар. Шунлыктан Зәйнуллаһ хәзрәтне әтрафының «рухани коралы» дип аталса ярыйдыр. Заманында аның сүзе һәркемгә закон-шәригать иде. Ысул җәдидәнең ихтилафлы заманларында аның бу хакта биргән фәтвасы бик күп гыйлем вә мәдәният дошманнарының авызларын япты.

Зәйнуллаһ хәзрәт хакыйкый бер тарикать иясе һәм самими гыйлем мөхибе[2] булганлыктан, аның хезмәте һәрвакыт самимият вә тугрылык белән мөмтаз[3] булмыштыр. Мәрхүм тарикать ияләреннән булган хәлдә дөньяга киң карый вә һәм төрле мәсләк һәм фикер ияләренә, дәрәҗәләренә карап, хөрмәт вә ихтирам итә иде. Ысул кадим заманында бу ысулда бөек бер мәдрәсә тәрбия кылып, бөтен әтрафны үз нөфүзе астында тоткан хәлдә ысул җәдидә тарала башлагач, моңа һәм каршылык күрсәтмәде. Билгакес[4], үз әтрафында тәртип вә низам белән укытуның рәваҗ[5] вә тәрракыясенә ярдәм итте. Ниһаять, үз мәдрәсәсен «Расүлия»не олуг мәхдүме Габдрахман әфәнде Расули илә яшь хәлфәләренең идарәсенә тапшырып, заманасына муафикъ ысул вә низамәгә куюга камил мөсагадә[6] бирде.

---

1 Әкъран – яшьтәш, тиңдәш.

2 Мөхибе – яратучы, сөюче.

3 Мөмтаз – башкаларга караганда өстенрәк булган.

4 Билгакес – киресенчә.

5 Рәваҗ – таралу.

6 Мөсагадә – мөмкинлек бирү, ярдәм итү.

Гомумән, Зәйнуллаһ хәзрәт, башкалар кебек үзенең нөфүз вә игътибарына сүи истигъмаль[1] кылмады. Бер нәүгъ[2] ишан вә мөдәррислек наме илә казанган нөфүз игътибарларындан файдаланып гыйлем вә мәдәният хадимләренә[3] каршы сәгаять[4] итү, дошманнар хәзерләү кеби ваклыклар белән чуалмады. Вөҗданы ни кушса, шуны ачыктан-ачыкка сөйләде вә язып таратты. Бәгъзан әтрафында җыелган бер такым[5] риякәр[6] халыкның сүзләренә ышанып, бәгъзе хаталар кылды исәдә, бу да кинә[7] башкаларда булган кебек «кара эч» белән эшләнмәде. «Мәзәлләт әкдам» кабиленнән[8] бер хата дәрәҗәсеннән үтмәде. Шунлыктан шәех хәзрәтләре ахыр гомеренә кадәр искеләр арасында да, яңалар арасында да үзенең нөфүз вә игътибарын югалтмады. Ахыр гомеренә кадәр һәм кем аны олуг бер шәех, могтәбәр бер галим санап хөрмәт вә ихтирам кылдылар.

Мәрхүм бу сәнә үзенең хәяте кыскарганлыгын хис кылган кебек, мәдрәсәсенең истикъбален[9] тәэмин өчен бөек бер вакыфнамә ясаткан иде. Троицкийда мәдрәсәи «Расүлия» намы илә мәшһүр бу мәдрәсәгә вакыф йорт алыр өчен үз тарафыннан 19 мең сум иганә кылды. Мәхласлары[10] тарафыннан һәм байтак иганә кылынды. Барлыгы 60 мең сум кадәр акча җыелды. Бу акчага Троицкийда берсе 70 мең, икенчесе 16 мең сумлык ике зур йорт алынды. Тагын да зур гына бер микъдар иганә җыелуы өмид ителәдер. Бу хәлдә Зәйнуллаһ хәзрәт үзе сәламәт чагында мәдрәсәсенең истикъбален бер кадәр тәэмин итеп килгән буладыр.

---

1 Сүи истигъмаль – урынсыз куллану.

2 Нәүгъ – төр.

3 Хадим – хезмәткәр.

4 Сәгаять – ризасызлык, канәгатьсезлек.

5 Такым – монда: төркем.

6 Риякәр – икейөзле.

7 Кинә – яшертен дошманлык; ачу тоту.

8 Кабил – төр.

9 Истикъбаль – киләчәк.

10 Мәхлас – ихлас, саф күңелле (кеше).

Шулай ук вафатына кадәр үз милкендә булган китапларының һәммәсен гомум файдасына вакыф итеп моны һәм тәсаддык[1] иттереп, 4 кешедән гыйбарәт бер һәйәт[2] кулына тапшырып китмештер. Бу китапханә файдасына хәзер дә 4600 сум вакыф җыелган. Аның да өч мең 500 сумы Зәйнуллаһ хәзрәтнең үзеннән, бер мең сумы Казанның Сөләйман әфәнде Аитовтан, ике йөз Галим хаҗи Агишевтан бирелмештер.

Мәрхүм Зәйнуллаһ хәзрәтнең кыскача тәрҗемәи хәле моннан гыйбарәт: Зәйнуллаһ хәзрәт 1833 сәнә миладиядә Оренбург вилаяте Троицкий өязе Таңгатар волосте Шәрип авылында дөньяга килгән. Атасы Хәбибуллаһ бине Расүл исемендәдер. Беренче тәхсиле[3] Верхнеурал өязендә Ягъкуб хәзрәт мәдрәсәсендә булмыштыр. Андан Троицкийга барып, дамелла Әхмәд бине Халид Әл-Мөнгари хәзрәтләрендә тәхсил итмеш вә шунда хәтме көтеп[4] кылып, хәлифә булмыштыр. 1858дә Верхнеурал өязе Акгуҗа (Аккуҗа) авылына имам булган. Шуннан хаҗга барган. Истанбулда Көмүшханәви хәзрәтләреннән шәехлеккә иҗазәт алып кайткан вә мөрид тәрбияли башлаган. Зәйнуллаһ хәзрәтнең иҗазәте Нәкышбәнди тарикатенең Халиди шөгъбәсенә[5] мәнсүбдер[6]. Бу тарикатьтә зикер хафи[7] булса да, Зәйнуллаһ хәзрәтнең шәкертләре бик еш мәҗзүб[8] булып хилкаләрен[9] «Һаи-Һу!» белән гөрләтмешләр. Бер тарафтан казакъ арасына чыккан хәлфәләр, икенче тарафтан Зәйнуллаһ хәзрәттә укыган вә бик аз бер заман эчендә мәшһүр булып әтрафта бөек игътибар казанган Зәйнуллаһ хәзрәт мөридләренең бу хәлләре аның игътибар

---

1 Тәсаддык – садака бирү.

2 Һәйәт – комиссия, комитет.

3 Тәхсил – гыйлем алу.

4 Хәтме көтеб – укуны (мәктәпне) тәмамлау.

5 Шөгъбә – бүлем, тармак.

6 Мәнсүб – караган.

7 Зикер хафи – яшерен, күңелдән генә әйтелгән зикер.

8 Мәҗзүб – тартылган, ияргән, илһамланган.

9 Хилка – түгәрәк, утырган кешеләр түгәрәге.

вә шөһрәтен күтәрә алмаган бәгъзе шәехләргә корал булган. Билхасса[1] Эстәрле хәзрәтләре моннан бик нык файдаланганнар. «Зәйнуллаһ ишан яңа мәзһәб чыгара» дип хөкүмәткә сигает[2] кылганлар.

Зәйнуллаһ хәзрәт 1873тә Оренбург губернаторы Крыжановский тарафыннан Вологда вилаятенә Николаевский шәһәренә сөргенгә җибәрелгән. Анда өч ел торган. Аннан, хәзрәтнең мәхласлары сорап Костромага күчерткәннәр. Ниһаять, 1881дә Зәйнуллаһ хәзрәт хөкүмәтнең рөхсәте илә иленә кайтарылган (Зәйнуллаһ хәзрәтнең бу дәвере халык арасында бик мәшһүр һәм бик күп төрле харика[3] вә кәраматләр белән мәгруфдер[4]. Акгуҗага кайткач, Зәйнуллаһ хәзрәт тәкрар[5] хаҗга барган. Хаҗдан кайткач (1884тә) Троицкий халкы яңа мәхәллә ачып, аны үзләренә имамлыкка чакырып алганнар. Зәйнуллаһ хәзрәт бу мәхәлләгә имам булуы илә бу көндә «Расүлия» намы илә мәшһүр олуг бер мәдрәсә тәэсис итеп шәкертләр укыта һәм киң микъдарда мөридләр тәрбия кыла башлаган.

Бу арада Зәйнуллаһ хәзрәтнең иң бөек хезмәтләреннән берсе аның Казахстанга мелла, мөгаллим һәм хәлфәләр хәзерләп бирүе вә мөридләр васитасы[6] илә анда гыйлем, дин вә мәдәниятkә мәйдан хәзерләведер. Зәйнуллаһ хәзрәт, заманында Казахстан өчен мәсәлсез[7] бер җәрраг[8] булды. Бер тарафтан казакъ шәкертләре һәм мөридләре васитасы илә Казахстанга дин вә мәдәният таралуга гаять бөек бер хезмәт кылды. Зәйнуллаһ

[1] Билхасса – атап, төбәп, махсус рәвештә.
[2] Сигает – шикаять.
[3] Харика – гадәттән тыш әйбер, вакыйга.
[4] Мәгруф – билгеле.
[5] Тәкрар – кабат.
[6] Васита – арадаш.
[7] Мәсәл – мисал (ягъни монда – тиңдәшсез).
[8] Җәрраг – нур, ут.

хәзрәтнең чирек гасырлык бу хезмәте бөтен Ислам дөньясы тарафыннан тәкъдиргә[1] лаектыр.

Зәйнуллаһ хәзрәт вафатына кадәр Троицкийда имам һәм мөдәррис булып торды. Соңгы елларда картлык сәбәпле, дәрескә керә алмаса да, мөрид тәрбиясе дәвам итә иде. Ниһаять икенче февральдә вафат хәбәре килде. Җәнабе Хакк Үзенең җәннәтендә кылып, калганларына сабыр җәмил[2] бирсен. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун!

Зәйнуллаһ хәзрәтнең артында берничә углы һәм берничә кызы калды. Болардан Габдрахман әфәнде Троицкийда үз мәхәлләсендә имам һәм мөдәрристер.

Зәйнуллаһ хәзрәтнең берничә матбуг[3] әсәрләре дә бар. Болар гыйльми җәһәттән бөек бер әһәмияткә мәлик[4] булмасалар да, үз заманында сөелеп укылды һәм тиешле вазифаларын үтәделәр. Болар арасында Зәйнуллаһ хәзрәтнең Троицкий голәмәсе илә берлектә ысул җәдидәнең дәреслегенә биргән фәтвасы илә страхованиеның җәвазы[5] хакындагы фәтвасы иҗтимагый җәһәттән дә вакытында хили[6] зур бер урын тоттылар. Тәкрар вә тәкрар буларак «Троицкий голәмәсе вә ысул җәдидә» исемле рисалә «Вакыт» идарәсе тарафыннан нәшер кылынды.

2171 нчы номер. 4 нче февраль. 1917 нче ел.

*«Шәех Зәйнуллаһ. Хәзрәтнең тәрҗемәи хәле»*
*китабыннан күчерелде, «Вакыт» матбагасы, 1917 ел.*
*Китапны тулысынча darul-kutub.com*
*сайтында укырга мөмкин.*

1 Тәкъдир – тану, бәя бирү.
2 Җәмил – матур, күркәм.
3 Матбуг – басылган.
4 Мәлик – ия.
5 Җәваз – эшләргә ярау, дөрес булу.
6 Хили – байтак, яхшы.

# Тәрбия

*1912 елда Оренбург шәһәренең «Вакыт» матбагасында чыккан «Усуль тәгълим вә тәрбиядән фән тәдрис» китабыннан кайбер текстларны тәкъдим итәбез. Китапны төзүче – «Хөсәения» мәдрәсәсендә гөлүм табигыя вә риадыя (математика) вә усуль тәгълим вә тәрбия мөгаллиме Габдуллаһ Шәнаси. Китап тулысынча darul-kutub.com сайтында урнаштырылган.*

# Безне Яратучы

Мөгаллим – (29 номерлы шәкерткә) Углым! Ошбу алдыңдагы өстәлне күрәсеңме? Моны кем ясады икән?

Шәкерт – Балта остасы ясаган, әфәндем.

М. – Ярый, углым. Берсе сезгә килеп: «Бу өстәл үз-үзеннән ясалды: соңра үзе бу сыйныфка килде», – дип әйтсә, ышанырсызмы?

Ш. – Юк, ышанмам.

М. – Ни өчен ышанмыйсыз? 25![1]

Ш. – Ничек ышаныйм, өстәл үзеннән-үзе ясалырмы?

М. – Алай булгач ничек ясалыр?

Ш. – Балта остасы ясар, әфәндем.

М. – Ярый, углым, бу өстәлне бер ясаучы булган кебек, бу ишекне дә бер ясаучы бармы, юкмы? 30!

Ш. – Бар, әфәндем.

М. – Кем соң?

Ш. – Янә балта остасы.

М. – Ошбу күргән рәсемләрегез үз-үзләреннән генә бар булганнармы?

Ш. – Юк, боларны бер ясаучы бар.

[1] Сөальләрдән соң күрсәтелгән номерлар шәкертләрнең номерларыдыр. Моннан аңлашыла ки, мөгаллим бер шәкерттән генә сорамый, һәркайсыннан сорыйдыр.

М. – Алай булгач, тирә-ягыбыздагы нәрсәләрнең һич берсе үзүзеннән булмаганнар, барысын да бер ясаучы бар түгелме, углым? Безне, башка адәмнәрне дә бер ясаучы вә бер яратучы юкмы соң? 40!

Ш. – Бар, әфәндем.

М. – Ярый, кем ул?

Ш. – Аллаһы Тәгалә.

М. – Афәрин, углым! Аллаһы Тәгалә ялгыз безне генә яратканмы? Хайваннарны кем яраткан?

Ш. – Аллаһы…

М. – Йә, бу без өстендә яшәгән җирне, ташларны, агачларны, диңгезләрне, елгаларны, күкләрне … вә башка бөтен нәрсәләрне яратучы кем?

Ш. – Янә Аллаһы Тәгалә.

М. – Ярый, «яратмак» ни дигән сүз?

Ш. – Ясамак дигән сүз.

М. – Әйе, углым. Ләкин нинди ясау икәнен беләмсезме? Һич юктан ясау. Бу санаган нәрсәләремезнең һич берсе электән юк иде. Җәнабе Аллаһы боларны һич юктан ясады, яратты… Берсе сезгә мәсәлән: «Адәмнәр бу дөньяга үз –үзләреннән чыктылар», – дисә, ышанырсызмы? 41?

Ш. – Юк, әфәндем!

М. – Йә, ни дип әйтерсез?

Ш. – Аллаһы яратты, дип әйтербез.

М. – Аллаһы Тәгаләнең безгә зур-зур яхшылыклары бармы? 34!

Ш. – Әлбәттә бар.

М. – Әгәр яңгырлар яумаса, игеннәр үсәр идеме?

Ш. – Юк, үсмәс иде.

М. – Ярый, алай булгач яңгырларны яудыручы, игенләрне үстерүче безгә икмәк яратучы кем, углым?

Ш. – Аллаһы Тәгалә, әфәндем.

М. – Йә, сез сөйләгез (37) без ашта ни ите ашыйбыз?

Ш. – Куй ите, сыер ите.

М. – Тагын?

Ш. – Тавык ите.

М. – Тагын?

Ш. – Күркә ите.

М. – Ярый, углым, боларның барысын да яратучы кем?

Ш. – Янә Аллаһы Тәгалә.

М. – (Мөгаллим бу мәүдугны бераз тагын кичектергәч) Алай булгач, ашаганыбызны, эчкәнебезне, кигәнебезне вә бөтен нәрсәләрне кем яратты?

Ш. – Аллаһы Тәгалә яратты.

М. – Без ни аркасында яшибез?

Ш. – Бу нәрсәләр аркасында яшибез?

М. – Ул хәлдә Аллаһы Тәгалә безгә иткән бу кадәр яхшылыкларына каршы шөкерана кылыра бурычлыбызмы?

Ш. – Әйе, әфәндем.

М. – Ялгыз шөкерана кылу гына җитәме? Аллаһы ни кушса, аны эшләмикме? 28!

Ш. – Эшлик, эшләргә бурычлыбыз.

М. – Әгәр дә «шул эшне эшләмәгез» дисә..?

Ш. – Аны эшләмәскә кирәк.

М. – Ярый, углым. Аллаһы Тәгаләнең ни эшләгәнебезне теләгәнен вә ни эшләгәнебезне яратмаганлыгын кайдан белик? Аллаһы Тәгалә тарафыннан берсе килеп безгә: «Аллаһы Тәгалә ошбу эшләрне ярата, аларны эшләгез; менә бу эшләрне бер дә яратмый, алардан сакланыгыз вә аларны эшләмәгез», – дип әйтергә тиеш түгелме?

Ш. – Әйе, әфәндем, әйтергә тиеш.

М. – Әгәр дә Аллаһы Тәгалә тарафыннан берсе килеп, безгә сөйләмәсә, хәбәр бирмәсә, без Аллаһы ни теләгәнне белә алырбызмы?

Ш. – Юк, белә алмабыз.

М. – Аллаһы тарафыннан килеп тә, безгә Аның теләгән вә теләмәгән нәрсәләрен белдергән кемсәгә ни диләр, беләсезме?

Ш. (тик торыр)

М. – Аңа «пәйгамбәр» дип әйтәләр, углым.

Ш. – Хәлфә әфәнде, пәйгамбәр ничек була ул?

М. – Углым, пәйгамбәр дә безнең кебек бер кешедер. Ул да ашый, эчә, утыра, йөри, аның да авызы, борыны, күзе, колагы бар. Ялгыз Аллаһының бик сөйкемле бер колы булганлыгы өчен Җәнабе Аллаһы аңа: «Әйдә бар да, яраткан адәмләргә, колларыма Минем сөеп вә сөймәгән нәрсәләремне өйрәт», – дип боерган. Пәйгамбәр дә килеп безгә: «Менә сезне юктан бар иткән, сезнең өчен бу кадәр яхшы вә матур нәрсәләр яраткан Аллаһы Тәгалә ошбу нәрсәләрне куша, боларны эшләгез; бу нәрсәләрне теләми вә сөйми, аларны эшләмәгез», – дигән. Аңладыгызмы?

М. – Углым (29) син, безнең пәйгамбәребез кем, беләсеңме?

Ш. – Хәзрәти Мөхәммәд.

М. – Афәрин, углым!

***

Ошбу рәвешчә дәвам итеп, Пәйгамбәребез хакында мәгълүмат биргәч, Коръәни Кәрим вә дин Ислам хакында мәгълүмат биреп, дәресне тәмам итәдер. Китапны озайтмау нияте илә ошбу кадәрлесе дә тиешле фикерне бирә алыр дип, дәрес беткәнче язмадык.

## Татар теле укытуның әһәмияте

Ибтидаи[1] мәктәпләремездә ана теле булган татарчаның тәгълим ителүе бик әһәмиятледер. Бу дәрес тәхсыйлнең[2] башлангычы, шәкертнең тәрракый коралыдыр. Инсан үз фикерен саф вә дөрес итеп аңлата алу илә генә чын кеше булыр. Бу максудка ирешү дә ана телен уку илә генә мөмкиндер.

Тел өйрәтүнең тәрбия фикриягә дә зур ярдәме бар: ни кадәр күп кәлимә беленсә, фикер дә шул кадәр киң булыр. Танылган сүзләргә яңадан ни кадәр сүзләр кушылса, фикердә мәҗһүл[3] дөньясын шулкадәр кечерәйткән булыр. Аннан башка ни кадәр күп тәгъбирләр[4] беленсә, шул нисбәттә фикерләрне ачык вә кыска итеп ифадә[5] итү мөмкин булыр. Хөласа[6]: җөмләләр тәркибе[7] сарыф вә нәхү кагыйдәләренә муафик булуы хөкемнәрне вә кыясларны рәткә салачак, мантыйк илә турыдан-турыга мөнәсәбәттә тотачактыр. Ана телен өйрәтү дигәч тә, ялгыз бер көтү сүз өйрәтү дигән сүз түгел, бәлки ул телнең кәлимә вә тәгъбирләрен истигъмәл[8] итә белү вә алар ярдәме илә фикерне тәрбия итү вә үстерүдер (...)

1 Ибтидаи – башлангыч.
2 Тәхсыйл – гыйлем алу.
3 Мәҗһүл – билгесез, мәгълүм булмаган.
4 Тәгъбир – бер мәгънә белдергән фраза.
5 Ифадә – аңлату.
6 Хөласа – нәтиҗә, йомгак, «озын сүзнең кыскасы».
7 Тәркиб – кушымта.
8 Истигъмәл – куллану ,файдалану.

# Мәүлид Ән-Нәби

# Мәүлид укыган өчен акча түләү рөхсәт ителәме?

Мәүлидне укыган өчен акча түләү һәм алу килешү рәвешендә эшләнеп, башкарган эш өчен түләү (акча алу) булып торса, бу дөрес түгел, чөнки гыйбадәтне акча алу максаты белән кылырга ярамый.

Әмма бүләк бирү яки кабул итү рөхсәт ителә. Мисал өчен, Кәгъб бине Зөһәйр радыяллаһу ганһе Расүлуллаһ галәйһиссәламгә аны мактап иҗат иткән касыйдәсен укыган. Расүлуллаһка бу бик тәэсир иткән. Шагыйрьгә берәр нәрсә бүләк итәргә теләсә дә, Пәйгамбәребезнең үзе белән бер-ни булмый, шуннан соң ул Кәгъбкә үзенең хиркасын (чапан сыман өске кием) салып бүләк иткән. Шуңа күрә бу касыйдәне «Касыйдә-и бурда» дип атаганнар. Бүгенге көндә Расүлуллаһ галәйһиссәламнең бу хиркасы Истанбулның Топкапы музеенда саклана.

Күрүебезчә, Расүлуллаһ галәйһиссәлам аңа касыйдә багышлаган һәм башкарган шагыйрьне бүләкле. Моннан Пәйгамбәребезне олыларга, шулай ук моның өчен бүләкләр тәкъдим итәргә яки алырга рөхсәт ителүен аңлыйбыз. Әлбәттә, бүләкләр чын күңелдән бирелергә тиеш.

*«Учение заблудших групп и сект и преступления, совершаемые их последователями под предлогом защиты единобожия» китабыннан*

# Мәүлид кичәсе

Мәүлид кичәсе Мөхәммәд галәйһиссәламнең туган кичәседер ки. Тарих Гайсәвинең 570 елында, 27 нче апрельдә, тарих һиҗридән 53 ел әүвәл, рабигыль-әүвәл аеның 12 кичендә, дүшәмбе көненә каршы, Мәккә шәһәрендә вакыйг булмыштыр. Ул зат шәриф туган кичә дә дөньяда бик күп гаҗәеп эшләр вакыйг булмыштыр:

1) Мәккә шәһәрендә Кәгъбә эчендә ул заманда 360 кадәр пот сурәтләре бар иде, Мөхәммәд галәйһиссәлам туган кичәдә шул потларның һәркаюсы йөз түбән аудылар. Иртәгесендә бу вакыйганы күргәч, бөтен Мәккә халкы гаҗәпләнеп, бу хәл нинди бер вакыйгага ишарә икән, диеп шомланмышлар.

2) Янә шул кичтә Мәккә шәһәре өстендә олуг бер нур җәелеп күренмештер.

3) Иран йортында Истахр шәһәрендә утка табынучы фарсыларның мең елдан бирле һич сүнмичә янып килгән, үзләренчә изге утлары шул кичтә һич берзаман сәбәпсез сүнеп китмештер.

4) Мәдайин[1] исемле шәһәрдә Иранлыларның падишаһы Хөсрәү Нәүширванның сарайлары тетрәп, ундүрт соффә[2] вә балконнары җимерелмештер. Бу кичә әһле Ислам өчен олуг вә мөбарәк кичәдер. Күп мөселман йортларында бу кичәне бәйрәм итеп, мәҗлес илә Мөхәммәд галәйһиссәламнең тарихына мөзакәра[3] кылып утырмак вә салават укымак гадәт булмыштыр.

---

1 Мәдайин шәһәре Багдад шәһәренең мәшрикъ тарафында 25 чакрым чамасы җирдә иде. Хәзердә харап булмыштыр. Нәүширван сараеның әсәрләре хәзердә дә бардыр.

2 Соффә – колонна.

3 Мөзакәрә – фикер алышу, сөйләшеп утыру.

## Вафат көне

Вафат көне Мөхәммәд галәйһиссәламнең бу дөньядан ахирәт сәфәренә күчкән көнедер ки. Тарих Гайсәвинең 631 елында 8 нче июнендә вә тарих һиҗринең 11 нче елында, рабигыль-әүвәлнең 12 нче көнендә, дүшәмбе көнне вафат булмыштыр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам мәзкүрилнең[1] 29 нчы сафәрендә әҗәл авыруы илә авырый башлады. Авыру булса да, берничә көн мәсҗедкә барып, имам торды. Сәхабәләргә вәгазьләр сөйләде. Вәгазь арасында үзенең әҗәле якынлашканын аңлатты. Сәхабәләр илә бәхилләште. Сәхабәләр кайгырышып бик елаштылар. Вафатына ун көн калганда, авыруы куәтләнү сәбәпле, мәсҗедкә чыга алмады. Аның урынына мәсҗедтә хәзрәти Әбү Бәкер имам булды. Сәхабәләр бик кайгыга баттылар. 12 нче рабигыль-әүвәлдә, дүшәмбе көн иртә намазына мәсҗедкә чыкмыш иде, сәхабәләр хәзрәти Әбү Бәкергә оеп намаз укымакта иделәр.

Мөхәммәд галәйһиссәлам үзе дә Әбү Бәкер радыяллаһу ганһегә оеп иртә намазын укыды. Намаздан соң хәзрәти Расүлнең мәсҗедкә чыкканын күреп, шаять сәламәтләнәчәк икән, диеп ,сәхабәләр бик сөенештеләр. Ләкин бу шатлык бик озакка бармады, чөнки өйлә вакытында хәзрәти Расүл үзенең өендә дөньядан китте. Аллаһы Тәгалә һәр каюмызга шәфәгатен насыйп әйләсен, әмин. «Аллаһуммә салли галә Мүхәммәд вә галә әәли Мүхәммәд вә сәллим». Ошбу рабигыль-әүвәлнең 12 нче көнендә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең вафат булганын хәтерләп, дөньяда һичкем мәңге калмаганын уйлап гыйбрәтләнмәк вә күп салават әйтмәк, Коръән укымак тиешледер.

*Әхмәдһади Максудиның «Һиләл»*
*(«Әхкәме шәргыя» мәҗмүгасының 6 нчы җөзэдер)*
*китабыннан, Казан, Харитонов матбагасы, 1905 ел*

---

[1] Мәзкүр – югарыда әйтелгән (бу очракта – ел).

# Нәсыйхәт

# Никахлар күкләрдә укыла

«Гаилә» сүзе гарәп телендә үзара сөйләшү, киңәшү дигәнне генә түгел, ә калкан дигән төшенчәне дә аңлата. Димәк, гаилә – безне бар нәрсәдән саклый торган калкан. Ә гаиләнең башы – никах. Без балаларны никахка әзерләргә, дөрес тәрбия бирергә тиеш.

## Сериаллар карый-карый, әниләр дә бозылды

Статистикага күз салсак, хәзерге парларның яртысы диярлек бер ел да тормыйча аерылыша. Ни сәбәпле? Чөнки әти-әни – никах турында иң соңыннан белүче кешеләр. Кызыбыз да, улыбыз да үз парын инде сайлаган. Безне таныштыралар да, ай-вайлап никахка әзерләнеп, чабыша башлыйбыз. Ә бит гореф-гадәт башкача! Кыз үстерүчеләр – егетләрне, ир бала үстерүчеләр кызлы гаиләләрне алдан ук күзләп яшәргә тиеш. Нәсел-нәсәбен, әти-әнисен, улын яисә кызын өйрәнеп, «менә бит, нинди күркәм пар булыр иде» дип, балабызның күзләрен бераз дөрес якка борырга тиеш идек. Әлбәттә, күрмичә өйләнү дә дөрес түгел. Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә дә бер сәхабә килеп: «Өйләнергә телим», – ди. «Син кызны күрдеңме соң?» – дип сорый Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм. «Юк, күрмәдем», – ди тегесе. «Бар, кара!» – ди Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм. Тик әти-әни дә баласына начар вариант сайламас, үзеннән артык яраткан баласына начар тормыш теләмәс. Гашыйк кеше: «Яратам!» – дип кенә тәкърарлый, күздә – пәрдә, колаклар ишетми. Ә әти-әнигә исә булачак кияү яисә килен – чит кеше. Ул аңа ачык күз белән карый. Холык-фигылен белешә, нәсел-нәсәбен тикшерә.

Вә ләкин, бүген никахны боза торган тагын бер нәрсә бар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Никахны укыганда без аның тигезлеген карарга тиешбез», – ди. Ягъни, егет белән кыз социаль, матди хәле, белеме, гаилә дәрәҗәләре – бөтен яктан бер-берсенә пар

килергә тиеш. Хәзер сериаллар карый-карый, әти-әниләр дә бозылды. Кызларын бай егеткә бирергә, егетләренә бай кыз табарга хыялланучылар да күп. «Әй, бу безнең шикелле хәерче бит инде, үзебезнең дә берни юк, сез дә шул хәерчелектән чыкмассыз», – дип фикер йөртәләр. Бәлки шул хәерче белән Аллаһы Тәгалә ризыкларын күбәйтеп, сез кызыккан бай егеттән дә бай дәүләтле булып яшәп китәрләр? Әти-әниләр балаларының ниятен бозмасын иде. Балаларыбыз бәхетле булсын, дип теләгез. Байлык кына бәхет китерә алмый. Әлеге тигезлек сакланмагач, аның үз проблемалары чыгарга мөмкин бит.

Балаларыбызны зур шәһәргә укырга җибәрәбез дә, кайда йөри, нәрсә ашый, нәрсә эшли – белмибез. Әйе, айга бер тапкыр килгәч, безгә бик матур сәхнә корып, спектакль күрсәтәләр анысы. Шуңа канәгать булып китәбез. Әмма әти-әнигә баласы өчен бу дөньяда да, Ахирәттә тә җавап бирәсе бар.

Хәзер никахны мәчеттә уздыру гадәте китте. Мәчеткә туганнар, дуслар, якыннар җыела, ә әниләре юк. Әниләр өйдә табын әзерли! Кайчак шалтыратып орышам үзләрен: «Балаңны үстереп, олы юлга озаткан мизгелдә ниндидер табын балаң никахыннан мөһимрәкмени? Әнинең догасы кабул була бит». Никахта никадәр күбрәк туганнар-якыннар дога кылса, шулкадәр хәерлерәк.

## Бүләк бирешү мәхәббәтне арттыра

Никахны катлауландыра торган тагын бер күренеш бар бүген. Кызларыбыз, егетләребез утыз-утыз биш яшькә хәтле гаилә кормыйча яши. Матди максатларны беренче урынга чыгару бу. Башта торырга фатиры, йөрергә машинасы, эше, дәрәҗәсе булсын, диләр. Тик алары булгач, гаиләнең хаҗәте калмый инде. Ул – формалашкан шәхес, рухи яктан үскән, финанс ягы нык. Нигә әле үзе тапкан малы белән чит егет яисә кыз белән бүлешергә тиеш ди! Әлбәттә, ул булачак парына да зур таләпләр куя. Шул

ук вакытта йөрәккә дә кертергә курка, үз-үзен саклау инстинкты эшли. Чөнки тормышны күрә: рәнҗетелгән хатыннар, исерек ирләр, ятим балалар турында мәгълүматы күп. Менә шуңа да, балагыз гаилә корырга теләк белдерә, яхшы гаиләдә үскән кешене сайлаган икән – каршы килмәгез. Расүлебез галәйһиссәлам хәдисләрендә әгәр яхшы кеше кызыбызны килеп сораганда каршы килсәң – Аллаһы Тәгаләнең ләгънәте дә булырга мөмкин, дип әйтә. Кем белә, бәлки шул ләгънәт аркасында кызыбыз утыз биш яшенә җитәр, онык та сөя алмабыз…

Яшьли өйләнешкән гаилә ешрак әти-әни җилкәсендә була, әлбәттә. Бу очракта да әти-әниләрнең акыллы гамәлләре барысын җайлап җибәрә ала. Кайбер бай дәүләтле гаиләләрне беләм. Балаларына никах укыттылар да, аларга фатир бүләк иттеләр. Тик бу фатирда обой да, люстра да, башка җиһазлар да юк. Өстәл белән карават кына тора. «Ник болай эшләдегез?» – дим әти кешегә. «Без беренчел ярдәмне, нигезен бирдек. Калганын эшләп тапсыннар. Кысылмыйбыз, нинди кәнәфи, нинди тәлинкә кирәк – рәхәтләнеп үзләре булдырсын. Алай кадерлерәк була ул. Әгәр хәзер бөтенесен әзерләп бирсәк, бер мәшәкатьләре дә калмаса – торырлармы икән?» – ди. Менә шулай икең бергә бер калактан башласаң, тормыш хәерлерәктер ул. «Генерал хатыны булыр өчен, курсантка кияүгә чык», – диюләре дә бу очракта бик туры килә.

Никах шартларының тагын берсе – ике як та мөселман булу. Катнаш никахлар бик күп очрый. Гаилә бит ул бер дәүләт. Бер дәүләттә ике канун, ике конституция була алмый. Югыйсә ул инкыйлабка китерә. Катнаш гаиләдә иң беренче инкыйлаб бәби тугач була. Нинди исем кушарга? Ничек кушарга? Мәчеткә барыргамы, әллә башка җиргәме? Бәби кайсы конституциягә буйсынырга тиеш? Инкыйлаблар дәүләтне җимергән сыман, гаиләләрне дә таркатырга мөмкин. Картайгач, берең бер зиратта, икенчең икенче зиратта ятуы да авыр хәл бит. Шуңа күрә, гаиләдә башта ук бер канун булдыру хәерлерәк.

Никах ул гомердә бер була торган бәйрәм. Әти-әнигә әйтмичә, качып укыту динебезгә туры килә торган әйбер түгел. Дөньяда бернәрсәне дә яшереп калып булмый. «Алдаган икән, безне санга сукмаган икән», – дип рәнҗи күрмәсеннәр. Егет икән, егет булсын! Бирмиләр икән кызны, йөрергә, бүләкләр бирергә, әти-әниләр күңеленә юлны табарга кирәк. Өйләнешкәч тә беркая китми бит алар, әле сезнең балаларны тәрбияләячәкләр. Шуңа күрә, аларның йөрәгенә юлны башта ук эзләгез.

Никахның янә бер шарты – шаһитлар. Алар, дөньялыкта да, Ахирәттә дә әлеге никах булды, дип әйтерләр. Мин гел шаяртып, шаһитларның кулында таяк булырга тиеш, дим. Әгәр бу гаиләдә кирәкмәгән тавыш чыга икән, килеп тәртип салып, тыныч күңел белән китәр өчен кирәк ул.

Кыз булачак иреннән бүләк сорарга тиеш. Борынгы китапларны карасак, анда берничә сыер, зур акчалар турында сүз бара. Бүген исә кызларыбыз чиста күңелле, «бер балдак, бер алка бирсә дә, риза», диләр. Дини нәзарәте, казыйларыбыз, бүген әлеге мәһер бәясен бераз күтәрергә кирәк, дип тәкъдим итә. Егет кызның кадерен, дәрәҗәсен белсен өчен кирәк ул. Әйтик, юк кына сәбәп аркасында өч тапкыр «талагын» әйтә дә, шуның белән вәссәләм. Әгәр ул мәһер итеп фатирын биргән булса, егет башкача фикерли. «Талак әйтсәм, фатирым да китә бит», дип кабаттан уйланыр, бәлки.

Хөрмәтле ир-атлар, сезгә зур нәсыйхәт: гаилә тормышыгызның беренче елын онытмагыз. Кавышкан чаклар, никахны көткән минутларны истә тотыгыз. Ешрак бүләкләр бирегез. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Бер-берегезгә бүләкләр бирегез, бүләк бирешү мәхәббәтне арттыра», – дип әйтә.

## Никах яңарту – араларны якынайта

Никах яңарту – күркәм гореф-гадәт ул. Йә ялгыш сулга күз төшә, йә ямьсез сүзләр әйткәләшәсең – тормыш бит. Әгәр йөрәккә шик кергән

икән – никахны яңартыгыз. Аның икенче ягы да бар. Никах яңартканнан соң парлар яңадан ширбәт аендагы кебек бер-берсенә якынаеп китә. Яшь вакытта ничек бер-берсе артыннан йөргәннәр, ничек кавышканнар – шуларны искә алу өчен, бераз мөнәсәбәтләргә кунган тузаннан арыну өчен кирәк бу. Телиләр икән, шаһитлары да булсын, мәһере дә булсын. Бу очракта мәһер төп шарт итеп куелмаса да, хатын-кызның күңелен күтәрә торган әйбер булсын ул. Бәлки инде ун еллап иренең бер бүләк тә, бер чәчәк тә биргәне юктыр. Тик талаклар белән бәйле кавышуны никах яңарту белән бутарга ярамый. «Талак» дигән сүзне онытырга кирәк!

Гаиләгә җиңел карый шул кеше. Юк кына тавыш чыкса, кыз елап әнисенә шалтырата. Әнисе: «Кызым, кайт», – ди. Менә шушы «кайт» дигән сүз гаиләне юкка чыгара да инде. Никах вакытында әниләргә мөрәҗәгать итәм: «Ишектә кыңгырау шалтырый, ачсагыз – кызыгыз үзе генә басып тора. Өйгә кертерсезме?» – дип сорыйм. «Кызым, кертмим», – ди. Егет ягыннан да сорыйм. Хәзер егетләр дә кызлар кебек бит, авырлыктан качу ягын карый. «Алдың икән, гомер буе яшәгез», – дип, икенче әни дә күз яше белән җавап бирә. Балаларны да шулай тәрбияләргә кирәк! Үз өстенә җаваплылык алган икән – гомергә яшәргә булсын!

## Бала хакынамы?

Бала мәсьәләсенә килгәндә дә, ирләребез ир булып кала белсен иде. Әгәр аерылышу булган, бала әнисе белән калган икән – канун буенча хезмәт хакымнан фәлән процент алимент түлим, дип мактанып йөрисе юк. Диндә процент дигән нәрсә юк. Диндә ата һәм бала бар. Әгәр ул синең балаң икән, бергә торасызмы, юкмы – аерма юк. Әти кеше баласын тулаем рәвештә тәэмин итәргә тиеш. Балаң ач икән, кияргә киеме юк икән – бу синең гөнаһ.

Бала хакына гаиләне саклау дөрес түгел, диючеләр дә бар. Тик психологларның фикерен дә истә тоту кирәк. Алар ни ди? Тулы гаиләдә

үсмәгән баланың үзенә дә гаиләсен саклау авыр булачак. Күреп үсмәгән ул, аны гаилә төшенчәсенә өйрәтмәгәннәр. Бала хакын хаклау дип карaганда, әйе, гаиләне саклау дөрес. Ләкин инде бер-берсе белән һич аңлашу таба алмаган ир белән хатын өчен бу психологик яктан авыр. Әгәр сүзләре үтсә, ата-ана яшь гаиләгә ярдәм кулы сузарга тиеш. «Үзем беләм, ник мине өйрәтәсең, ни беләсең соң син?» – диюче балалар да күп бит. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Ахырзаман алдыннан хатын-кыз үзенә патша табыр», – ди. Чын, хәзерге балаларны патша урынына күрәбез, ә алар ата-анасына кол дип карый. Сүзебез үтәрлек итеп тәрбияләсәк иде. Авыр вакытларда аларны вәгазьләсәк, бәлки гаиләләр таркалмас, дус, тату гына яшәп китәрләр иде.

Гаиләләргә тагын бер киңәшем: берәр хәзрәт белән дус булыгыз. Рухи яктан остазыгыз булсын ул. Күңелегезгә якын, сүзеннән шифа табардай кеше кирәк. Авыр чакларда киңәшкә, нәсыйхәт алырга алар янына барыгыз. Сулга йөри, дип гайбәт ирештерделәрме, ике арада аңлашу бетеп киттеме – кыенлык туу белән үзеңә ябылырга ярамый. Сезгә яхшылык теләүчеләр күп. Әти-әниегез, туганнар, дусларыгыз, бәлки никах укыган, балага исем кушкан хәзрәтләр дә җылы сүз белән ярдәм итә алыр. Күңелегез ышанган кешегә генә ачылыгыз. Ышанычсыз бәндәләрдән зыян килмәсен.

## Мин – үземчә, син үзеңчә

Гаиләдә «мин үземчә, син үзеңчә» дигән нәрсә булмаска тиеш. Дин ягыннан ул ярамый да. Әйе, ир-ат табучы, тәэмин итүче. Тик бөтен өйне карау, өйгә җан өрү – хатын җилкәсендә. Хәтта кибеткә кереп ипи алганда да хатының белән киңәшләшеп алу тиешле. Мондый вак нәрсәләрне дә сөйләшеп алыгыз. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйтә бит, өч очракта алдарга ярый – шуның бер очрагы хатынга. Мөнәсәбәтләрне җайлап җибәрү өчен, хатыныңның күңелен күтәрү өчен. Әйтик, ире, кибеткә ба-

рабыз, дип сөйләшеп тә, вакыты булмый эштән соңарып кайтты, ди. Бер шоколад булса да ал инде. Гәрчә көне буе эштән баш күтәрергә вакыт булмаса да: «И матурым, шушы шоколадны юллап йөрдем сиңа», – диген. Хатыннарыгызның күңелен төшермәгез. Аларның күңелен Ходай бик нечкә итеп яраткан.

Төп нәсыйхәт шул: арагызга гайбәт кертмәгез. Урамда, эштә, дуслар арасында сөйләнелгән чүпне өйгә алып кайтуның кирәге юк. Ә өйдә булган – урамга чыкмасын. Пешергән ашыңны ирең ашамаса, елап әниеңә шалтыраттың, ди. Ярты сәгатьтән дуслашып, кочаклашып йоклап ятарсыз, ә әни кеше ут йотачак. Төне буе керфек тә какмаска мөмкин. Гаиләдән яхшы хәбәрләр генә чыксын. Җәмгыять ачулы, көнче, күз тидерүләр бар. Шуңа күрә гаиләләрегезне дога, намаз белән саклагыз.

## Әти-әнисен онытып җибәрмә

Ир бала әнисенә нинди мөнәсәбәттә булса, хатынына да шундый булыр, ди халык. Килешәм. Бу – кагыйдә. Һәрхәлдә, йөзнең туксаны шулай эшлидер. Әле алай гына да түгел, үзенә хатын сайлаганда да әнисенә охшатып сайларга тырыша ул. Мәчеткә бер пар килде. Хатыны зарлана: «Хәзрәт, ирем үз әти-әнисенә игътибарны күбрәк бирә, минекеләргә алай ук түгел», – ди. Дөрес, никахларда, ике якны да тигез күрегез, дибез. Тик дин ягыннан бу бераз дөрес түгел. Исламда үз әти-әниең беренче урында. Расүлебез галәйһиссәламгә сорау бирәләр: «Мин кемне күбрәк яратырга тиеш бу дөньяда?» Җавап бирә: «Әнине», – ди. Аннан соң? «Әнине». Аннан соң? «Әнине». Аннан соң? «Әтине».

Гаилә кору белән үз әти-әниеңне оныту – зур гөнаһ. Җәннәт безнең әти-әниләр аяк астында. Шуңа күрә, ирегез яисә хатыныгыз сезнең әти-әниегезне үзенекеннән артык ярата алмый, тиеш тә түгел. Монда тигезлек саклау хатын өстендә. Хатын ул – муен. Ул җайлап кына башны дөрес якка борырга тиеш. Әгәр ир өйләнгәч, үз әти-әнисен онытып җибәрә

икән, җайлагыз, алып кайтыгыз аны нигезенә. Шунда бәрәкәте дә булыр, кайнанагыз да сезне кызы кебек күрер.

Әти-әниләргә дә әйтәсе килгән сүз бар. Үзегезнең яшь вакытыгызны онытмагыз. Сезгә дә әти-әниләрегез өйрәткән, аңлаткандыр, тик яшьлек белән колак салынмый бит. Сез дә үз вакытында үзегезчә эшләгәнсездер. Балаларыгыз да сезнең кебек үк. Әгәр алар үзләренчә эшләргә омтыла икән, артык бәйләнмәгез, үзегезне искә алыгыз. Яшьләргә: «Ярар, дияргә өйрәнегез», – дим. Татар халкы «ярар» дигән сүз белән күп хәлләрне җайлап куя. Әти-әниегезнең дә йөрәге бозылмас.

## Ир ясаучы да, чүпкә әйләндерүче дә – хатын-кыз

Тигез хокуклы булам дип, ир һәм хатыннар буталып бетте. Хатыннар асфальт сала, ирләр диванда ята. Исламда андый әйбер юк. Динебез гаиләнең башы – ир-ат, ди. Чын хатын-кыз аждаһаны тотып-бәйләп куярга, аннан, ир-ат аждаһаның башын гына чаба, дип, иренең кулына кылычны тоттырырга тиеш. Ирне ир-ат итә белергә кирәк. Ирнең дәрәҗәсен төшерергә ярамый. «Мин күбрәк акча эшлим, мин синсез дә яши алам», – дисәң, гаилә җимерелә. «Бер кадак та кага белми бит ул», – дип сөйләп йөрсәң, ирең мескен була да кала инде. «Иң яхшысы минем ирем, кулыннан килмәгәне юк, нәрсәгә тотынса, шуны башкарып чыга», – дип мактарга кирәк. Эшли белмәсә дә! Ирне нинди дәрәҗәгә җиткерәсез – аның сәбәбе «муен»да. Ир ясаучы да, аны чүпкә әйләндерүче дә сез үзегез. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең иң якын сәхабәсе Әбү Бәкер авызында таш йөртә торган була. Аннан нигә болай эшләве турында сорыйлар. Ул болай аңлата: «Әлеге ташны авыздан төкергәнче бер-ике мизгел вакыт була. Ачуны чыгарган кешегә җавап бирергәме-юкмы – шул арада мин уйлыйм». Безгә күп вакыт менә шул җитеп бетми. Биш минут кагыйдәсен гел истә тотыгыз. Ирең эштән акчасыз кайтты икән, ямьсез сүзләр белән ябырылганчы, утыртып ашатыгыз. Менә шул биш минут сабыр итсәгез,

тавыш чыкмас. Ходай әҗерен бирер. Шулай ук хатынығызның ашы тозлы булган икән, шунда ук ачу белән бәрелмәгез: биш минут сабыр итегез. Биш минут, әлбәттә, шартлыча әйтелгән. Иң беренче ачулы сүз әйтелми калсын. Имин гаиләнең асылы шул.

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*«Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

# Юмартлык һәм саранлыкның Коръән һәм Сөннәттәге хөкемнәре

**Юмартлык – Аллаһы Тәгаләнең сыйфатыдыр**

Аллаһы Тәгаләнең бер исеме – Әл-Кәриимү, бик юмарт. «Җәзалау, үч алу кулында булган хәлдә Ул юмартлыгы белән гафу итүче, колларының эшләгән гөнаһларына карамыйча, аларга нигъмәтләр насыйп итүче.» Аеруча, Әр-Рахмәәнү (Шәфкатьле), Әр-Рахиимү (Мәрхәмәтле), Әл-Вәһһәәбү (Бирүче), Әл-Ләтыыйфү (Җиңеләйтүче), Әт-Тәүүәәбү (Кичерүче), Әл-Гафүүру (үтә Мәрхәмәтле гафу итүче), Әл-Гәфүү (Гафу итүче), Әр-Рааүфу (иксез-чиксез Мәрхәмәтле) һәм Әл-Һәәдии (туры юлга Күндерүче) кебек Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең күркәм исемнәре дә теге яки бу яктан Аның чиксез Юмартлыгын раслый.

Коръәни Кәримдә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә болай дип әйтә:

**«Укы! Раббың синең чиксез юмартлык иясе».**

«Галәк», 96:3

**«(Инсаннар) ял итсен, дип Аллаһы төнне, (яктылык) күрсеннәр дип, көнне яратты. Шөбһәсездер ки, Аллаһы – инсаннарга карата юмартлык ияседер. Ләкин инсаннарның күбесе шөкер итми».**

«Мөэмин», 40:61

**«Әй, иманлы бәндәләр, арагызда диненнән язган кеше булса, белеп торсын: Аллаһы үзе сөйгән, Аллаһыны сөйгән мөэминнәргә кече күңелле; кяферләргә карата кырыс бер кавем китерәчәктер. Алар Аллаһы юлында җиһад итәрләр вә һичбер куркытучылардан курыкмаслар. Бу Аллаһының Үзе теләгәненә биргән юмартлыгы. Аллаһының ярлыкавы вә гыйлеме киңдер».**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:54

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Шөбһәсез, Аллаһы Тәгалә чистадыр һәм чисталыкны сөядер. Аллаһы кәримдер һәм юмартлыкны яратадыр». (Тирмизи, Әдәп, 41/ 2799)

«Шуны онытмаска кирәк: Аллаһы Тәгалә ул – «Ганиййун-Кәримдер» (Юмарт хуҗа). Әгәр теләсә, безне туендырган кебек, бөтен мохтаҗларны да туендырыр. Ләкин бу дөнья – имтихан урыныдыр. Аллаһы Тәгалә безне сыный, мохтаҗларның булуын онытмыйча, аларга ярдәм итүебезне тели. Бу Аллаһының хикмәтләреннәндер».

**Юмартлыкның фазыйләтләре**

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә болай ди:

**«Аллаһыга вә аның Расүленә иман китерегез. Мираска калдырылган малларыгызны (Аллаһы юлында) сарыф итегез (хәерсадака-зәкят бирегез). Иман китереп, (Аллаһы ризалыгы өчен мал) сарыф иткән кешеләргә бөек әҗер хәзерләнгән».**

«Әл-Хәдид / Тимер», 57:7

Димәк, юмартлык нәтиҗәсендә күп әҗер-савап алып була. Кыямәт көнендә дә биргән садака-малларыбыз безне эсседән коткара торган күләгә булыр, ин шә Аллаһ:

**«Үзләре дә фәкыйрь булуга карамастан, соңгы ризыкларын мохтаҗларга, ятимгә, әсир кешеләргә бирер. Алар хәерчеләргә:**

**– Без сезне Аллаһы ризалыгын алыр өчен ашатабыз, сездән бер түләү дә, рәхмәт әйтүегезне дә көтмибез. Чыннан да, без читен һәм хәтәр бер көннең газабыннан куркабыз, – дип әйтерләр. Менә шуның аркасында Аллаһы ул көнне аларны афәттән коткарыр, йөзләренә нур өстәр, күңелләренә куаныч бирер».**

«Инсан / Кеше», 76:8-11

**«Әй, иман китергән бәндәләрем, Без сезгә биргән ризыкларны Ахирәт көне килеп җиткәнче үк (Хак юлында) сарыф итегез (сада-**

**ка бирегез, ятимнәргә булышыгыз, зәкят бирегез, хаҗ гыйбадәте кылыгыз). Ул Көн килеп җиткәч кенә алыш-биреш тә, әшнәлек тә, шәфәгать тә булмаячак. Кяферләр – золым итүчеләрнең үзедер».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:254

Билгеле булганча, юмартлык нәтиҗәсендә мал-мөлкәт кимеми, ә киресенчә, аңа тагын да артык бәрәкәт иңә. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә әйтә:

**«...Күпме хәер бирсәгез, Аллаһы аның бәрабәренә сезгә нигъмәт бирер. Ризыкландыручыларның иң хәерлесе – Аллаһы».**

«Сәба», 34:39

**«... Хәтта үзләре кыен хәлдә (ач) булсалар да, алар (мохтаҗларның, мөһаҗирләрнең) ихтыяҗын алга куяр. Кем нәфесен (малга хирыслыгын) тыя белә, шул морадына ирешкәннәрдән булыр».**

«Хәшер / Сөреп Чыгару», 59:9

Юмартлык җәннәткә илтә торган сәбәп. Әлеге факт күп хәдис-шәрифләрдә расланган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Кыямәт көнне дүрт төркем кешеләр: галимнәр, хәләл акчага хаҗга барганнар, Аллаһы юлында шәһит булганнар һәм хәләл акчалары белән кешеләргә юмартлык кылганнар хисапсыз-кыенлыксыз җәннәт ишегенә барырлар. Аларның кайсылары беренче булып җәннәткә керү мәсьәләсен Аллаһы Җәбраил галәйһиссәламгә тапшыра. Җәбраил галәйһиссәлам аларның өч гөрүһларына сорау бирә: «Сез Аллаһы юлында шәһит китү, хаҗ кылу һәм ярдәмчел булуның саваплы, зур мәртәбәле икәнлеген ничек белдегез?» – дип сорады. Алар: «Без галимнәрдән ишеттек», – диделәр. «Алай булса, галимнәрнең беренче булып җәннәткә керүләре гадел булыр. Аларга тиешле хөрмәт күрсәтегез, алардан алдан җәннәткә керү әдәпсезлек булыр», – дип Җәбраил галәйһиссәлам карар итә. Әмма галимнәр: «Аллаһыбыз безнең тәннәребезне яратканда без бернинди гыйлемгә ия түгел идек. Ул гыйлемнәрне юмартлык кылучы-

лар ярдәме сәбәпле үзләштерә алдык. Инде аларның тырышлыклары заяга калмасын, юмартлык кылучылар бездән алда җәннәткә керсеннәр», – диделәр. Шунда Аллаһы Тәгалә фәрештәләргә җәннәт ишекләрен ачарга куша һәм беренче булып юмартлар керә, аннан соң галимнәр, соңыннан исә башкалар».

Күрәбез ки, юмартлык кылу, гаҗиз һәм мохтаҗларга мәрхәмәт кылу нихәтле әҗерле гамәл икәнен».

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай ук: «Юмартлык – тамыры җәннәттә булган агачтыр. Кем аның (юмартлыкның) тармагына ябышса, тармак аны тамырга, ягъни җәннәткә китерер. Саранлык – тамыры җәһәннәмдә булган агачтыр. Кем аның тармагына ябышса, тармак аны тамырга, ягъни җәһәннәмгә китерер», – дип әйтә.

«Бел, әгәр дә кеше байлыкка ия булмаса, ул талымсыз булырга, комсызлык күрсәтмәскә тиеш. Әгәр байлыгы булса, ул башкалар турында күбрәк уйласын, юмартлык күрсәтсен, саранлыктан саклансын. Чөнки юмартлык пәйгамбәрләрнең сыйфатларыннан, һәм бу – котылуның бер нигезе. Юмартлык турында сөйләгән хәдисләр бик күп. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дөреслектә, кешеләрне кунак итү, һәрбер кешегә сәлам бирү, яхшы сүзләр әйтү – гафу итүнең сәбәпләре» (Табарани).

Габдуллаһ бине Җәгъфәр: «Яхшылык кылуга саранланма. Әгәр дә син яхшылыкны күркәм кешеләргә кылсаң, димәк, алар аңа лаек. Әгәр дә түбән кешеләргә кылсаң, димәк, син моңа лаек», – дигән.

Юмарт кешенең гыйбадәте, аз булса да, саран кешенең күп кылган гыйбадәтеннән өстенрәк булган кебек, юмарт җәһил дә комсыз галимнән өстенрәк: «Аллаһы Тәгалә юмарт кешене көн-төн гыйбадәттә булган саран кешедән күбрәк яратыр» (Тирмизи). «Аллаһы каршында юмарт бер надан саран галимнән өстенрәк, чөнки саранлык иң авыр чирдер» (Әд-Дәракутни).

Юмарт кешенең иманы нык, саран кешенеке исә зәгыйфь: «Юмартлык иманның сәламәт булуыннан килер, иманы нык кеше җәһәннәмгә кермәс. Саранлык шик-шөбһәдән туар, иманы шөбһәле кеше җәннәткә кермәс» (Дәйләми).

«Юмарт Аллаһыга, кешеләргә, җәннәткә якын, җәһәннәмнән ерактыр» (Тирмизи).

«Юмарт бул, Аллаһы Тәгалә дә сиңа карата юмарт булыр. Шуны яхшы бел: саранлык көферлектәндер, көферлекнең урыны исә җәһәннәм» (Дәйләми).

«Юмарт кяферне җәһәннәмгә атканда Аллаһы Тәгалә җәһәннәмне саклап торучы фәрештәләрнең башлыгы Мәликкә боерыр: «Дөньядагы юмартлыгы өчен аңа иң җиңел газап бир» (Дәйләми).

«Юмарт булган һәм аз зарланганнар – бу өммәтнең иң дәрәҗәлеләре» (Табарани).

Хәдис-шәрифләрдә шулай ук юмарт кешенең малы бәрәкәтле булуы, садаканың малны киметмәве һәм мосафирның үзеннән соң кырык көнлек бәрәкәт калдыруы хакында әйтелә.

Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдин үзенең «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Шәйтан белән очрашуы» китабында шундый әңгәмә китерә:

«– Өммәтем садака биргән вакытларында нинди хәлдә буласың?

– Садака бирүче кеше кулына пычкы алып, мине икегә бүлгән кебек буламын.

– Нигә бу хәлгә керәсең, әй, начарлыкның атасы?

– Чөнки садакада дүрт төрле өстенлек бар. Беренчесе, Аллаһы Тәгалә садака бирүче кешенең малына бәрәкәт иңдерә. Икенчесе, тормышында, кешеләр каршысында аны сөекле итә. Өченчесе, биргән садакасы аның белән җәһәннәм арасында пәрдәгә әйләнә. Дүртенчесе, биргән садака хөрмәтенә аның юлыннан бәла-казаларны юк итә».

# Ришвәт зәхмәте

Һәрбер тарихи чорда яшәүче җәмгыять өчен «ришвәт» мәсьәләсе борчый торган, актуаль мәсьәләләрнең берсе булып саналган. Әлеге күренешнең безнең бүгенге тормышыбызга, шул исәптән мөселманнар яшәешенә дә хас булуы – аның гамәли хөкемен ачыклауны, ислам канун-нары күзлегеннән карап аңлатма бирелүне таләп итә. Ришвәтнең тискәре күренеш булуын күпләр белә, мәгълүмат чараларыннан «фәлән кеше ришвәт белән тотылган, тегесен кулга алганнар икән» дигән хәбәрләрне укып яки ишетеп, аларны сүгә, гаепли, әмма кайчакта үзләре дә, аны-моны абайламыйча, шушы харам эштә катнашып ала.

Нәрсә соң ул «ришвәт»? Иң элек шуны әйтергә кирәктер: ришвәт ул – ислам динендә катгый тыелган харам гамәл. Шушы төшенчәнең аңлатмасына, сүзнең лексик мәгънәсенә килгәндә, «ришвәт» – ул үз шәхси мәсьәләңне хәл итү максаты белән нинди дә булса вазифаи затка (должностное лицо) акча яки кыйммәтле бүләк бирү; яисә эш урының белән бәйле вәкаләтләреңне баю, законсыз табыш алу максатында нәфесләнеп файдалану (коррупция). Шәригать буенча ришвәтне алу да, бирү дә гөнаһлы булып санала. Бу хакта Коръән аятьләрендә дә, хәдисләрдә дә әйтелә. Мәсәлән, «Бәкара» сүрәсенең 188 аятендә болай диелә (мәгънәсе): **«... үз малыгызны хөкемдарларны сатып алыр өчен файдаланмагыз – ришвәт бирмәгез».** Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәламнең хәдисләрендә дә ришвәтнең тыелганлыгы турында хәбәрләр күп очрый. Әйтик, бер хәдистә болай диелә: «Аллаһы Тәгалә ришвәт бирүчене дә, алучыны да, бу эштә арадашчы булып йөрүчене дә ләгънәт кыла».

Димәк, бу гамәлнең  харамлыгы ачык вә билгеле булса да, ни кызганыч, бүген шактый күп кешенең тормышы балачактан гына түгел – туганнан бирле (кайбер очракларда туганчы ук) ришвәттән башланырга мөмкин: яхшы балалар тудыру йортына урнашам, дип яки табиблар

үземне һәм баламны яхшырак карасыннар дип, хатын-кызларның медперсонал кесәсенә «күчтәнәч» тыгулары хәзер беркем өчен дә сер түгел. Балалар бакчасына урнаштыру да еш кына шуның мөдиренә саллы «бүләк» бирү аша оештырыла, һәм әйтергә кирәк, шәһәрләрдә баласын бакчага «акча төртеп» урнаштыру аркасында чираты инде килеп җиткән ата-аналарны «урын юк» дип кире боралар. Шуның белән ришвәтчеләр Аллаһы күрсәтмәсенә дә каршы килә, кеше өлешенә кереп, аның хокукларын да боза.

Медицина һәм мәктәпкәчә тәрбия бирү оешмаларыннан тыш ришвәтчелек күренеше бүген хокук саклау органнары, югары белем бирү системасы, башка кайбер дәүләт учреждениеләре эшчәнлегенә дә хас. Әлбәттә, илебездә коррупциягә каршы чаралар алып барыла, җинаять кылучыларга карата кырыс хөкем карарлары чыгарыла. Шулай да җаваплы хезмәт башкаручы кешеләрнең аларга бирелгән хакимлек вәкаләтләрен үз мәнфәгатьләрен кайгырту максатында хирысланып файдаланулары дәвам итә һәм моның шулай булуына халык күпмедер дәрәҗәдә үзе дә гаепле, дип әйтергә кирәк.

Кайберәүләр: «Без бит бу түрәне сатып алу нияте белән түгел, ә аның безгә ярдәм күрсәтеп, ихлас булышканы өчен бүләк бирдек», – диләр. Дөрестән дә, әгәр җаваплы вазифа башкаручы түрә үз хезмәте өчен бернинди шарт куймый, берни таләп итми, ә аның хезмәтеннән файдаланган кеше эш башкарылганнан соң (алдан түгел!) рәхмәт йөзеннән аңа күчтәнәч бирә икән, аның бу гамәле ришвәтчелеккә керми. Түрәнең дә бу очракта күчтәнәчне (бүләкне) кабул итеп алуы гөнаһ булып саналмый. Хастаханәдән, балалар тудыру йортыннан чыкканда табибка, шәфкать туташларына сөенечне уртаклашып, рәхмәт белдереп акча яки күчтәнәч бирүне дә ришвәт дип атап булмыйдыр (әгәр медперсонал алдан бу хакта кисәтеп: «Кайтып киткәндә фәлән сум бирәсе», – дип шарт куймаган булса). Шуңа күрә нинди дә булса вазифа башкаручы кешегә акча яки

бүләк биргәндә бирүченең нияте, асыл-теләге исәпкә алынырга тиеш. Һәрхәлдә, әгәр акча яки бүләк вазифаи затның таләбе буенча бирелә икән, бу һичшиксез ришвәт була (хәтта сүз кечкенә сумма турында барса да). Әлеге таләп (шарт) өченче зат аркылы белдерелгәндә дә, бирелә торган акча (бүләк) ришвәт хөкемендә була.

Галимнәр белдергәнчә, мөселманнарга үз алдыңа ниндидер максат куеп, урындагы кешеләргә акча бирү тыела. Биредә югары постлар биләүче түрәләр турында гына сүз бармый: хәтта ресторанда официантка бирелгән вак акча «ул башкаларга караганда миңа яхшырак хезмәт күрсәтсен яисә сыйфатлырак ризык китерсен» дигән ният белән бирелсә, аңа бирелгән 5 сум да ришвәт булып саналачак. Әгәр шушы акча официантка аннан берни өмет итмичә хәер (чаевой) нияте белән бирелсә, бу, ин шә Аллаһ, садака була. Шуңа карамастан, ресторан хезмәткәренең бурычы – барлык клиентларга (хәер биргәннәргә дә, бирмәгәннәргә дә) бертигез яхшы хезмәт күрсәтү. Әлеге кагыйдә барлык оешмаларга, шул исәптән, әйтик, хастаханәләргә дә кагыла.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәктер, кайбер аерым очракларда ришвәтчелек гамәлендә бер як, ягъни алган кеше генә гаепле булып санала. Әгәр, мәсәлән, кеше гомеренә куркыныч янап, табиб, авыру өчен хәтәр һәм катлаулы хәлдән файдаланып, аннан акча таләп итсә, авыру, гомерен саклап калу нияте белән, соралган акчаны бирсә дә, гөнаһлы булмый, ә менә алучы харамлашкан була.

Инде билгеләп үтелгәнчә, ришвәтчелек тормышыбызның төрле өлкәләре белән бәйле. Ничек кенә сәер яңгыраса да, кызганычка, хәзер дин өлкәсе дә кагыйдәдән чыгарма түгел. Әйе-әйе, кайбер очракларда имам-абыстайлар да «коррупционер» исеменә лаек булырга мөмкин. Мәгълүм булганча, динебездә исем кушу, никах укыту, мәет юу һәм кәфенләү кебек йолаларны башкару өчен бернинди түләү каралмаган, ягъни «шул йола өчен фәлән сум түлисе» дип мәчетнең Уставында да, ниндидер дини

чыганакларда да берни әйтелми. Әлбәттә, мәет юу, салкынмы, эссеме, яңгырмы, буранмы булуга карамастан, аны җирләү, гомумән, соңгы юлга озату процессында катнашу – шактый авыр хезмәт, шуңа күрә халыкның, моны аңлап, дин әһелләренә садака рәвешендә акча яки сөлге-күлмәк бирүен шелтәсез, гадәти гамәл дип кабул итәргә кирәктер. Әмма кайбер мәхәлләләрдә мулла яки абыстай шушы хезмәтләре өчен генә түгел, хәтта Коръән укыганнары өчен дә «ставка» билгеләп, халыктан билгеле бер күләмдә акча сорый. Бу, әлбәттә, шәригатькә каршы килә торган, алай гына да түгел – бернинди әдәп-әхлак кысаларына сыймый торган, дин әһеле дәрәҗәсен төшерә торган кырын гамәлдер. Әгәр дин әһеле үз вазифасыннан файдаланып, матди хәлен яхшырту нияте белән, дини гыйлеме булмаган, үзенең бакыйлыкка күчкән туганына багышлап Коръән укытып, дога кылдыртырга теләгән кешегә «фәлән сум миңа түләрсең» дип шарт куя икән, әлбәттә, ришвәтче хөкемендә булыр. Әмма бернинди шарт куймыйча, берни таләп итмичә укыганнан соң теге кеше аңа садака итеп акча бирсә, монысы ришвәт булмый. Икенче мәсьәлә – шушы садаканы дөрес урнаштыру. Әйтик, имам ярыйсы яхшы пенсия ала, әле, мәсәлән, табышлы умарталыгы бар, ди, һәм шул ук вакытта ул җитәкләгән мәчетнең уты-газына түләрлек акча җитеп бетмәсә – әлбәттә, мондый очракта аның шушы садака акчасын үзенә алуы бер дә дөрес эш түгел. Имам мохтаҗ булган очракта да, барлык садака акчалары (шул исәптән аштан кергәннәре дә) мәчет кассасына тапшырылырга тиеш, чөнки мәхәллә имамы җәмәгать эшен башкара, ә инде кергән акчадан, барлык ихтыяҗларны исәпкә алганнан соң, шул имамга хезмәт хакы түләнсен. Ислам динендә гади кешеләргә дә караклык гамәле кылганы өчен дә шактый кырыс җәза каралган, ә инде әлеге гамәл имам яки башка мәчет әһеле тарафыннан кылынса, бу тагын да авыррак җинаять булып санала.

Дин әһелләренең ришвәтчелек кылу очракларыннан зиратта җир биргән өчен акча алуны (ул район башкарма комитеты яки авыл советы

карары белән билгеләнмәгән булса), шулай ук никах уку тиеш булмаган очракта бу йоланы акчага башкаруны (әйтик, хатын-кызның гыйддә вакыты чыкмаган килеш яисә татар-мөслимә кызы белән христиан егетенә никах уку һ.б.) мисал итеп китерергә мөмкин. Дин өлкәсендә эшләүчеләр шундый хәлләрдән, һичшиксез сакланырга тиеш.

Шулай итеп, ришвәтчелек гамәле, тормышыбызның кайсы өлкәсендә кылынуына карамастан, ул – бик хәтәр һәм зарарлы гамәлдер. Ришвәтнең (коррупция) тыелуы, ислам шәригатендә риба яки аракы сату кебек гамәлләр белән беррәттән җитди җинаять булып саналуы нәрсә белән бәйле соң? Мөселман галимнәре аңлатуынча, ришвәтчелек җәмгыятьнең бозылып таркалуына китерә, чөнки коррупция нәтиҗәсендә гадел булмаган карарлар кабул ителә, гадел булганнарына исә юл ябыла, лаек булмаган кешеләргә мөмкинлекләр булдырылганда, лаеклылар читкә этәрелә, шул сәбәпле коньюктура өстенлек алып, җәмгыятьтә җаваплылык рухы җуела бара. Адәм баласы Аллаһы кануннарын санга сукмыйча, «акча гына булсын: нәрсә телим – шуны эшлим» дигән фикергә нигезләнеп яши башлый икән, һичшиксез, һәлак булачак. Тормыш моны инде бик күп тапкыр раслады.

*Ришат хәзрәт Курамшин,*
*Кукмара мәдрәсәсе мөдире*

# Әдәби сәхифә

# Уңышка ирешү сере

Искәндәр абый өстәл янына утырып, тәмләп кенә чәй эчәргә җыенган мәлдә, ишегалдында күрше егете Рөстәмнең хәвефле тавышы ишетелде:

– Абый! Абый! Чык әле тизрәк, абый! Харап булды бит, ә, харап булды-ы!..

– Теләр-теләмәс кенә урыныннан кузгалып, Искәндәр абый аш бүлмәсенең ачык тәрәзәсеннән башын чыгарды да, чәеннән бүлдергән күршесенә ачулы караш ташлап, канәгатьсез мыгырдап куйды:

– Йә, нәрсә булды тагын?

Кабаланып йөгергәннән тыны беткән егет нәкъ тәрәзә каршысында туктап тирән сулыш алды да, кулы белән урам якка ишарәләп, коты чыккан кыяфәттә бер киртәгә, бер күрше абыйсына текәлеп:

– Анда... коеда... анда сезнең кәҗәгез коега егылып төшкән, Искәндәр абый! – диде.

– Вәйт сиңа мә! – дип әллә ни исе китмәгәндәй сөйләнеп куйган абзыйның хатыны Рауза апа шомлы хәбәрне ишетүгә илерә үк башлады:

– Үлә-әм! Кайсысы-ы? Исәнме-е?!

Аннары тәрәзә янында аптырашлы халәттә басып торган иренә дәште:

– Күр әле моны, ә? Ник басып торасың!? Әллә йөрәгең дә җонланганмы?! Йөгер әйдә тизрәк!

Әмма Искәндәр абый бернинди хис-эмоцияне чагылдырмаган кызыл йөзен хатынына таба борып, кыска гына ике җөмлә әйтү белән чикләнде:

– Син, әйдә, кысылма! Юкса, кысылып калуың бар...

Язмыш шаяруы дигәндәй, Искәндәр абыйларның кәҗәсе мал табибы Фәнзилнең капка алдындагы иске коесына егылып төшә. Ишегалларында яңа кое казытканнан соң, урамдагысы ташландык хәлгә килгән

була. Ни чылбыры, хәтта куласасы да булмаган шул иске коены күргәч, Искәндәр абый «хым» дип кенә әйтеп куя да уйга чума.

– Нишләтәсең инде аны хәзер? – диде ветеринар, кулларын як-якка җәеп. – Кәҗә бит ул болан кебек нәзек һәм бик куркак хайван, инде егылып төшкәнче үк җан биргәндер…

Әмма кое төбеннән кызганыч тавышлы «Мә-ә-ә!» дигән аваз ишетелгәч, җыелган күрше-күлән моның болай түгеллегенә инанды. Ветврач исә институтта алган белемнәрен «җигеп», үз сүзендә торуын дәвам итте:

– Моның  кадәр биеклектән егылып төшкән малның рәте калмый инде аның! Имгәнгәндер, аяклары сынгандыр… Кыскасы… Миңа бу кое барыбер кирәкми: кәҗәсе-ние белән бергә күмеп куйыйк та – шуның белән вәссәләм!

Шушы гадәти булмаган тәкъдимне ишеткәч, кәҗә хуҗасы беравык нәрсә әйтергә белмичә аптырап басып торды: әүвәл бимазаланудан хафага калган карчыгы Раузаны исенә төшереп, кәҗәне ничек тә чыгарасы иде дип уйлап куйса, соңыннан малкайны интектереп, аны чиләнеп чыгарганны күз алдына китергәч, Фәнзил фикере ничектер дөресрәк тоела башлады. Ә инде табиб: «Гаеп миндә дә бар – ыстрахуфканың бер өлешен бирермен» дип вәгъдә иткәч, Искәндәр абый аның белән ризалашмыйча булмас дигән катгый нәтиҗәгә килде.

Килешенде – бетте-китте: янәшәдәге чүп үләне каплаган иске балчык өемен актарып, Рөстәм белән Фәнзил ике көрәкләп коены күмә башлагач, нечкә күңелләләр «аһ» итте.

– Ужжыыс… – диеште кызлар, күзләрен түгәрәкләп һәм авызларын кул белән каплап. Әмма хәлнең бик киеренке булуына карамастан, чагыштырмача тыныч торган адәмнәрдән аермалы буларак, өстәгеләр нәрсә эшли башлаганын абайлаган кәҗә ачыргаланып акырырга тотынды. Аның «М-мә-ә-ә!» дигән авазы бу мизгелдә күпләргә «Күм-мәәә!!! Күм-

мәәә!!!» дип ишетелде. Ләкин нишләмәк кирәк – мәсьәлә хәл ителгән: күмәсе тәк күмәсе.

Озак вакыт узмый – бахыр малкай кычкырудан туктый, дөнья тынычланып киткәндәй була. Бераздан Рөстәм белән Фәнзилгә катырак бәгырьле күрше егетләре дә ярдәмгә килгәч, эш тизләтелә, ә инде коеның яртысыннан күбрәге күмелгәч, Фәнзил, эшне туктатып, башын аска иеп эчкә карап ала да... нәрсәгәдер бик шаккатып, гаҗәпләнүеннән сызгырып куя. Шуннан соң башкалар да кызыксынып аска карый, һәм коега атылган балчык өстендә аягында басып торган канәгать кыяфәтле исән-имин кәҗәне күргәч, үзләре дә сизмәстән шулай ук сызгырып җибәрәләр.

– Вәйт иты да-а! – дип гаҗәпсенеп әйтеп куя хәйран калган Искәндәр абый.

Хәлнең хикмәте нәрсәдә булуын аңлап алган егетләр коега тагын берничә көрәк балчык ата, кәҗә исә өстенә атылган балчыкны селкеп төшерә дә, аяклары белән төйгечләп, тыгызлап куя. Моны күргән авыл агай-энеләре түзми һәм «Сүбехәәнәллаһ – мәә шәәллаһ!» – дип тел шартлатып, коега балчык атуларын дәвам итә. Кәҗә дә тырышып үз эшен башкара. Шулай итеп, озак вакыт та үтми, кое ахырына кадәр күмелеп килгәндә, Искәндәр абыйларның газиз малкайлары өскә чыга. Янәшәдәге тактага сикереп төшкән кәҗәне авыл халкы кул чабып каршы ала.

Шушы искитәрлек кызык вакыйга күпләр өчен зур гыйбрәт була. Авыл имамы Җомга намазында бу хәлне искә төшереп, шундый аңлатма бирә:

– Һәр кешенең тормышында проблемалар булмыйча калмый. Авырлыклар, бәла-казалар рәвешендәге «балчык» өстебезгә гел коелып тора. Әмма шуны аңлау мөһим: безгә килгән һәр авырлык ул – уңышка ирешү өчен бер адым, чөнки шушы авырлыкларны «селкеп төшерү» нәтиҗәсендә этәрелеп алга таба кузгалып китәр өчен үзенчәлекле бер «мәйданчык» барлыкка килә. Тормыш юлыннан атлаганда һәркем Фәнзилнең коесы

кебек тирән караңгы чокырга да егылып төшәргә мөмкин. Шул вакытта өстебезгә коелган, бик куркыныч тоелган кыенлыклар «балчыгын» өстән каккалап, тыгызлап куярга һәм шулай итеп, әкрен генә булса да өскә күтәрелергә кирәк. Искәндәрләрнең кәҗәсе нәкъ шулай эшләп, сезгә бик яхшы сабак биргәнен онытасы түгел, җәмәгать, онытасы түгел…

*Ришат хәзрәт Курамшин,*

*Кукмара мәдрәсәсе мөдире*